
PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА **АЗАТ ХАТЫН**



2017 **ФЕВРАЛЬ № 2**

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398



ӘТИСЕЗ ИР БАЛА

ата тәрбиясеннән башка булмый

ТЕАТРГА... НОРВЕГИЯГӘ

безнекеләр котыпта

АЛСУ ФАЗЛЫЕВА СЫЙЛЫЙ:

Мароккоча пешкән бәрән ите

Равилә ШӘЙДУЛЛИНА:

«КИҢЛЕК ҺӘМ БИЕКЛЕКЛӘР ЯРАТАМ МИН!»



PRESSA.RU



И-и ямьле туган ягым!

И-и ямьле туган ягым!
И-и ямьле туган ягым!



Раилә ХӘЯЛИЕВА.
Кайбыч районы.

«Кайбыч имәне» сүтезмәсе күптән инде халык теленә кереп, заманча итеп әйткәндә, безнең «бренд»-ка әверелде. Германия һәм Швеция галимнәре Кайбыч урман хуҗалыгы белән ныклы элемтәдә тора. «Россия имәнлекләре» проекты да Кайбычта тормышка ашырылырга тиеш. Пётр I нең Казан ягына сәяхәте вакытында данлы имән урманын күреп, горурлык белән: «Это моё – это государево», – дип әйтүе мәгълүм. Су юлы белән Петербургка агызылган хисапсыз Кайбыч имәненнән йорт күтәреп торучы субай да, диңгез гизүче кораб та ясалган. Хәтта бүгенге көндә бөтен дөнья туристлары таптый торган Эрмитаж һәм башка күркәм сарайларның паркеты да – ни гаҗәп! – Кайбыч имәннәреннән!

Гали ХУҖИ

Кайбыч урманнары

*Такташ сөйгән Тамбов урманнарын,
Җан азыгы алган алардан.
Һәм җырлары аша алар даны
Әкияттәге кебек таралган.*

*Ә мин сезгә гашыйк гомерем буе,
Урманнары туган ягымның.
Төшләремә кереп шаулыйсыз сез,
Сезне тагын өзелеп сагындым.*

*Бердәй газиз миңа һәрберегез,
Күрми торсам – җаным ачына.
Язлар саен сезнең һәрберегез,
Өметләрем кебек ачыла.*

*Үкендермәс мине үткән гомерем,
Сезне шулай сагынып яшәсәм;
Язлар саен сезнең имәннәрнең
Бер яфрагы булып яшәрсәм.*

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2017

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Фото: Рамиль Гали

Директор-баш мљхђррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Равилә Шәйдуллина
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 14.02.2017 ел.
Заказ А-343.
Тираж 5755.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в ПАО «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU



Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов 1957 елның 1 мартында Татарстанда, Балык Бистәсе районының Яңа Арыш авылында туган. Россиякүләм танылган дәүләт эшлеклесе, күренекле сәясәтче, дөнья күләмендә билгеле шәхес.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның гомер бәйрәме уңаеннан хатын-кызлар аңаниләр әйтергә тели икән?

БУ СҮЗЛӘР —



Ләйлә ФАЗЛЫЕВА

Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе

Рөстәм Нургали улы миңа «энергия» сүзе белән тәңгәл тоела. Бу сүз нindидер тылсым белән җитез җил тизләген, яктылыкны, су көчен, кодрәтен, яшендәй реакцияне үзенә сеңдерә.
Минемчә, кешеләрне ярату, туган җирнең гореф-гадәтләренә һәм традицияләренә хөрмәт аны шундый әйбәт энергия белән баета. Чөнки ул туган җиренә малайларча гашыйк, бөтен җанын-тәнен шушы җиргә багышлаган. Аның энергиясе иҗади һәм позитив: һәр кылган эше уңай нәтиҗәләр бирә. Һәм... аның чын күңелдән эчкерсез елмаюы тагын... Бу елмаю тынычландыра, иртәгәсе көн өчен һәрчак ышаныч тудыра!



Сәрия САБУРСКАЯ

Татарстанда кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил

Президентыбыз башкарган эшләр һәркайсыбызның күз алдында. Бирәдә арттырып та, киметеп тә сөйләп булмый. Көнне төнгә ялгап эшләүче бик эшлекле җитәкче ул, Президент шундый булганга күрә аның кул астында эшләүчеләргә дә тырышырга туры килә. Булдыклы гына түгел, бик игътибарлы, кайгыртучан да кеше әле ул. Башкалардан да шуны таләп итә.
Яшел Үзәндә хакимияттә эшләгән чагым. Рөстәм Нургали улы ул вакытта финанс министры иде. Безнең Балалар йортына килде. Игътибар белән барын да карап, барысы белән дә танышып чыкты һәм икенче көнне үк ятимнәргә күп итеп уенчыклар җибәрде. Нык гаҗәпләнгән идем шул чагында. Олы җанлы, чиста күңелле кеше ул.



Айгөл ГАРИПОВА

КФУ каршындагы Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче гимназиянең инглиз теле укытучысы

Һәр көнем Рөстәм Нургали улының «Хәерле иртә»се белән башлана. Зур җитәкчеләр, гадәттә, күргәннәрен фотога төшереп, интернетка «элеп» матавыкланмый. Ә без менә Президентыбызның кая барганын, нәрсә күргәнен һәрдаим белеп торабыз. Аның интернет сәхифәләре аша Татарстаныбызның ничек яшәгәнен дә тоеп була. Ул фотоларга карап, гап-гади кешеләрнең гап-гади шатлыкларына да сөенәсең, завод-фабрикаларга да «керәсең», чит илләрдә «булып кайтасың», хәтта боз өстендә балык та «тотасың». Мин, укытучы буларак, аның тырышлыгын, өлгерлеген, спорт сөюен укучыларыма да үрнәк итеп сөйлим. Укучылар да хөрмәт итә аны, моны аларның: «Безнең Президент», – дип, горурланып әйтүләреннән беләм.



Минсинә һәм Ленар ЛАТЫЙПОВЛАР

Биектау районы, Дөбьяз авылының фермерлары

Соңгы елларда авыл хуҗалыгын үстерүгә зур игътибар бирелә. Әлбәттә инде, бирәдә Президентыбыз Рөстәм Миңнехановның өлеше зур. Фермерларга хуҗалыкларын киңәйтү өчен грантлар уйнатыла, субсидияләр бирелә. Без дә грант буенча откан 3 миллион 400 мең сум акчага таналар алдык. Президентыбызга рәхмәттән башка сүзебез юк.



АНЫҢ ХАКЫНДА



Талия
МИҢНУЛЛИНА
Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе

Президент командасында эшләп, Рөстәм Нургали улыннан көн саен нәрсәгә булса да өйрәнәм, аның яңадан-яңа сыйфатларына сокланам. Нык дисциплина, югары дипломатия, искиткеч сизгерлек, теләсә кем белән уртак тел таба белү осталыгы, үзен гел җаваплы хис итү, һәрвакыт иң югары нәтиҗәгә омтылу... Ә моның өчен нык сәламәтлеккә ия булу кирәк! Шуның өчен дә безнең команда Президентыбызга нык сәламәтлек тели. Илбашыбызның уңышлары тагын да артсын өчен, без барысын да эшләргә әзер! Шулай ук гаилә иминлеге телибез аңа: якыннар – һәрвакыт ышанычлы терәк, алар сине күбрәк аңлый, уңышларыңа ихласрак сөенә...



Аида
ГАРИФУЛЛИНА
Россия опера җырчысы, Татарстан Республикасының атказанган артисты, Вена операсы солисты

Язмыш миңа Ватанымнан еракта яшәп тә, яраткан эшем белән шөгыльләнү мөмкинлеген биргән. Венада яшим, операда җырлыйм, дөнья буйлап гастрольләрдә йөрим. Һәм һәрчак үземне Татарстан илчесе итеп хис итәм. Кайда гына барып чыксам да, республикам белән кызыксынуларын, аның уңышларыннан хәбәрдар булуларын күрәм! Талантлы халкыбыз иҗат иткән җырларны ничек сокланып, яратып тыңлауларын тоям! Мин моның белән горурланам!
Рөстәм Нургалиевич, без, иҗат кешеләре, һәрдаим Сезнең ярдәмне, кайгыртуны тоеп торабыз.
Рәхмәт Сезгә!



Зилә
МИРГАЛИЕВА
Канада татарлары җәмгыяте рәисе

Безнең Монреальдәге җәмгыятебезгә Рөстәм Нургали улы күп бәхетле мизгелләр бүләк итте. Канадага эш визиты белән килгән вакытта безнең белән очрашу өчен дә вакыт тапты. «Татар теле буенча халыкара олимпиада»да Гран-при яулаган кызыбыз Камилә Хәмәдиярованы шәхсән үзе бүләкләве дә безнең күңелләрдә якты истәлек булып сакланыр. Рөстәм Нургали улы безгә бик якын кеше – теләкләребезгә, уңышларыбызга, проблемаларыбызга беркайчан битараф калмый. Ерак илләргә таралган халкыбызны туплый, аралашу өчен яңадан-яңа мөмкинлекләр таба. Без – бергә. Бердәмлек безгә эшләү көче бирә, яшәү дәрте өсти, яңа уңышларга өнди.
Монреальдә яшәүче татарлар исеменнән Сезне тагын кунакка чакырып калабыз.



Фәнүзә
КАДЫЙРОВА
«Арктик-Университет» командасы һәм кызлар арасында хоккей буенча Россия җыелма командасы уенчысы:

Казан – спорт башкаласы, дип әйтәбез икән, монда үзе дә спорт белән кызыксынучы Президентыбызның өлеше бик зур. Ә минем өчен Рөстәм Нургали улының бозга чыгып хоккей уйнавын күрү – аеруча зур куаныч. Кем белә, бәлки, кайчан да булса бергә уйнарга да насыйп булыр әле. Һәрчак шулай яшь, спортчылардай җитез, игътибарлы, куйган максатларына ирешүчән булсын иде дип телим. Һәм киләчәктә Казаныбызда да хатын-кызлар арасында профессиональ хоккей командасы булдыруга ирешсен иде. Рәхәтләнеп үзебезгә кайтып уйнар идек.

PRESSA.RU





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА



12

ГАДИЛЛЕККӘ ГИМН
А. Юнысова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





8

МАМАДЫШ ӘТИЛӘРЕ
М. Авзалова



22

КӘБЕСТӘ АШМЫ, ТҮГЕЛМЕ...
Ә. Самат



16

«МИНЕКЕЛӘР...»
Г. Сафиуллина

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ



26

БЕР ӘНИНЕҢ ӨЧ КЫЗЫ
Г. Хәсәншина



ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



32

ЧАТНАГАН ЧӘРКӘ
С. Шәмси

ЯШӘЕШ 



38

АНДА, БОЛЫТЛАР АРТЫНДА...
Л. Гәрәева



52

ТЕАТРГА – ТРОМСЕГА!
С. Гаффарова

ШУЛАЙ УК: 

20 РӘХМӘТ СИҢА...
Г. Хәсәншина

44 ЯЛГЫЗ МИН, БЕРҮЗЕМ...
Л. Фаршатова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

60



БЕР КИЧТӘ ТЕГЕЛГӘН СВИТШОТ

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

ЗАЛИМНӘРГӘ ҖӘЗА ЙОМШАРА. ЗАМАН КЕМНЕҢ ЗАМАНЫ

МИН НИНДИ ӘНИ: ЯХШЫМЫ, НАЧАРМЫ?..

КАФ ТАУ АРТЫНДА НИЛӘР БАР? МИН АЧКАН ДӨНЬЯ

РАЯЗ ФАСИХОВТАН БӘЙРӘМЧӘ ИРТӘНГЕ ЧӘЙ.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Узган ел әтием белән әнием үзләренең «Энҗе туй»ларын билгеләп үтте. Шушы 35 ел эчендә алар безне – дүрт балаларын үстереп, җаебыз чыккан саен кайтып сыенырлык йорт җиткерделәр, тулы, матур тормыш булдырдылар.

Әнием Нурания исемле. Әлеге вакытта ул авылыбыз тарихын өйрәнеп, китап яза. Кулымнан килеп, мөмкинлегем булса, мин дә китап язар идем. Әнием турында булыр иде ул. Күңелемдә аның исеме дә бар – «Безнең әни». Тыштылыгына әнинең 1994 елда «Киленбикә» конкурсында җиңеп, «Сөембикә» журналында басылып чыккан иң матур фотосын куяр идем. Бик матур ак калфактан, чәшке туннан ул анда – чын ханбикә инде! Күңелемдәге ул китапның бүлекләре дә әзер. Беренче бүлеге әниемнең Мамадыш районы, Үсәли авылында үткән балачагына багышланыр иде. Аның әле кечкенә вакытында ук язылган көндәлекләреннән өзекләр дә кертер идем. Гафу ит инде, әнием, минем аларны яшереп кенә укыганым булгалады шул: «Татар теле укытучыбыз КДУның татар филологиясе бүлегенә керү имтиханнары турында сөйләде. Имтиханнарга әзерләнәм. Иң зур хыялым – укытучы булу».

Китабымның икенче бүлеге, һичшиксез, әниемнең университетта укыган елларына багышланыр иде. «Студент елларым, кайда сез?» дип атар идем мин аны. Үкенечлерәк яңгырый, әмма әнинең яшьлек еллары турында хатирәләрен тыңласаң, аларны кайтарырга теләү – табигый, ул бармаган шәһәр, эшләмәгән эш, күрмәгән һәйкәл калмагандыр да. Әниемнең тырышлыгын университет профессорлары да күрә, аны аспирантурада калырга үгетлиләр. Юк, әнинең максаты ул түгел бит, профессор абыйлар! Аның укытучы буласы килә.

Кичәге студентны юллама белән үзенең Үсәлиеннән ерак булмаган Олы Нырсыга (Теләче районы) укытучы итеп җибәрләр. Шуңа да китабымның өченче бүлеген «Укытучы» дип атар идем мин. Нырсы мәктәбендә эшләп килгән «Бөреләр» иҗат түгәрәге, «Нырсуар» хоры – болар бар да әниемнең тынгысызлыгы нәтиҗәсе. Юк, әнием, яшьлегең эзсез узмаган синең! Без – синең кызларың ул эзләрдән кабат үттек, икебез син укыган факультетка укырга кереп, син йөргән хорга йөрдек. Теләчедән Нурисә булам, дип әйтүгә, хор җитәкчесе Ирнис абый Рәхимуллин, шунда ук сине искә төшерде: «Теләчедән Нурания кызымы әллә?» Күр син, 30 ел буена онытмаган!

Киләсе бүлек нәкъ менә «Җырчы Нурания» дип аталыр иде. Матур җырлаучылар күп, ләкин мин әниемне, һич курыкмыйча, профессиональ җырчы дип әйтер идем. Аның «Җырлыйк әле» телевизион тапшыруында районыбыз данын яклап катнашуы, республикабыз ветераннарының «Балкыш» сәнгать фестивальләрендә катнашып, лауреат исемен алулары, быел фестивальнең гала-концертында катнашып, «Вокал-соло» номинациясендә җиңү яулавы – сүзләремә дәлил.

«Нурания – җиңүче!» – күңелемдәге китапның тагын бер бүлеге шулай аталачак. Үзалдына нинди генә максат куйса да, ирешми калмый ул. Язмамның башында «Киленбикә» конкурсында җиңү яулавын әйтеп киткән идем инде. Әнигә ул чагында нибарысы 33 яшь булган.

Еллар уза, ә бәйгеләр исемлеге арта бара... 2016 елгы «Ел хатын-кызы» конкурсында әнием «Өченче буын героинясы» исеменә лаек булды. Җитди конкурс, зур җиңү бу. Монда инде кичәге яки үткән атнадагы җиңүләрең белән генә катнашып булмый. Нәкъ менә әнием кебек батыр йөрәкле, куркусыз җанлы кеше булырга тиешсең. Әнием шундый минем дип, авыз тутырып әйтә алам. Ул авыл советы рәисе булып эшләгәндә, авылыбызга газ, су керә, юллар төзекләндерелә.

Әниемнең бүген дә бер буш вакыты юк: тавыклар да асрый ул, бал кортлары да, инде өстәмә җир алып, үзен яшелчәчелектә дә сынап карамакчы...

Китабымның алдагы бүлеге иң зурысы булырдыр. Әниемнең уңышларын яздым, инде аны хатын-кыз буларак чагылдыра торган иң мөһим сыйфатларын барлыйсым калды. Бу бүлектә мин аны Ана, Ир хатыны буларак ачармын. Әгәр дә янәшәсендә әтиебез булмаса, әнинең үзенә генә бу уңышларга ирешү бик кыен булыр иде бит. Әти аңа чын мәгънәсендә таяныч, терәк булды. Бик зур рәхмәт сиңа, әти. Әнине гашыйк иткәнең, гомер буена яратканың өчен рәхмәт.

Нурисә ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА.
Теләче районы, Олы Нырсы.



Җәйге алсу таңнар тагын да алсуланып, һавалардан бал тамган чакта җыеп, чемләп киптерелгән җиләкләрне кулыма алсам, хәтер сукмакларым мине җиләкле болынга, әнкәемнең яшь чагына алып китә.

Печәнне җыеп, кибәннәргә куеп кайтышлый, әни кулында һәрчак җиләк булыр иде. Мин – нәни кызчыкны, җылы кочагына кысып коча да: «Кызым, менә сиңа болыннардан бүләк. Кызылларын гына җыйдым, бәбкәм», – ди.

Әнкәм Гыйләҗева Фидания Шарияздан кызы, 1929 елның 24 ноябрендә Чистай районы, Каргалы авылында туа. Мәктәптән соң Казан университетына укырга керә. 1955 елда аны Әлмәт районы Яңа Кәшер авылына укытырга җибәрәләр. Монда ул безнең әтине очрата. 1969 елда алар Түбән Кама шәһәренә күченә, әнкәй лаеклы ялга чыкканчы мәктәптә татар теле укытты.

Ул бар гомерен балаларга биргән, хезмәтендә зур үрләр яулаган олы шәхес. Аның «Хезмәт ветераны» дигән мактаулы исеме бар, «Хезмәттәге фидакарьлек өчен» медале белән бүләкләнгән. Әткәй белән алар өч бала тәрбияләп үстерделәр. Авылда бала үстерүе җиңел булмагандыр, алтмышынчы елларда хатын-кыз баласына ике ай тулуга эшкә чыгарга тиеш була бит. Әти завуч иде, мәктәптән кайтып та кермәде. Гаиләнең бөтен мәшәкате әни җилкәсендә булды. Аңа йокы тими торган иде. Ике-өч сәгать йокы йокымыни? План төзү, иртәгәге дәрескә әзерләнү, берничә өем дәфтәр тикшерү, җитмәсә, кош-корты, безне сәламәт итеп үстерүдә үзеннән өлеш керткән тиктормас кәҗәбез дә бар.

Әнинең гел башы авырта иде, бу минем күңелемдә зур борчу тудыра, аңа әйтмичә генә, эчемнән кайгырам, озак яшәсә ярар иде, дип телим.

60 нчы елларда Яңа Кәшердә әни бердәнбер лектор иде. Аның камил хәтере, зирәк акылы, фикер йөртүе бүген дә сокландыра. Мәктәпнең 50 еллыгына кайткач, укучылары әниемә өрфия шәл бүләк иттеләр. Аңа рәхмәт әйтеп, бергә утырткан каеннарны искә алдылар. Аларның: «Фидания апа, Сез безне бер дә ачуланмый идегез», – дип әйтүләре – әнкәмнең асыл укытучы булуына бер дәлил.

Аларны гынамы соң, безне дә ачуланганы булмады аның. Киресенчә, күп шуклыкларыбызны әтигә әйтми иде. «Ана камчысы мамыктан», ди халык мәкале. «Баланың бармагы авыртыр, ананың – йөрәге» дигәне дә бар. Алтынчы класста укыганда турниктан егылып төшеп, өч көн буе әнкәм кочагында ятып кына савыкканым бүген дә истә.

Ул сугышның ачысын да, ачлыкялангачлыгын да кичергән кеше. Әтисе, минем бабам, үз теләге белән сугышка киткән. Әбием көне буе эштә, йорт эшләре дә, шук энекәшләрен карап-тәрбияләү дә әни өстендә. «Әниебезнең эштән кайтуын түземсезлек белән көтә идек. Эштән кайтыр иде дә, безне кочагына сыендырыр иде», – дип искә алганда, күзләренә яшь тула аның.

Әнием университетның татар теле факультетын тәмамлаган. Ул чорда бер атналык итеп бирелгән икмәкне кайтышлый ук ашап бетерә икән. Өйдән алып килгән онны (майдыр, сөттер ише башка ризык юк) суда туглап, боламык ясап, шуның белән җан асрый. Берсендә Казан тирәсендәге бер авылга бәрәңге алышырга барган. Эшләгән өчен аңа бер капчык бәрәңге биргәннәр. Бәрәңге капчыгын вагон эченә кертеп куеп булмый, әни аны тамбурга гына куя. Билетка да акчасы юк, тикшерүчеләр керсә, вагоннан чыгып кача икән дә, тикшерүчеләр чыгып киткәч, кире тамбурдагы капчыгы өстенә барып утыра икән.

Берзаман кышкы каникулда авылына кайтырга чыккан. Аягында бер бай кызыннан күчкән фетр итек. Авылга берничә чакрым калгач, автобуслары ватылган боларның. Халык җәяүләп киткән. Бәхетсезгә, әнинең итек башы тишелеп чыккан. Шул тишек итек белән көч-хәл кайтып җиткән. Әнә шулай тормыш михнәтләрен җиңә-җиңә, көчле рухлы булып үсеп җитә ул.

«Әни куены туннан җылырак», ди халык. Әниле булудан да зуррак бәхет бар микән ул?

Рушания ГЫЙЛӘҖЕВА.

Кем ничектер, мин үзем бик тә радио тыңларга яратам. Иллә дә җырчылар күп хәзер. Җырлар да күп. Вакыт-вакыт әллә нинди әкәмәтләре ишетелә.

Кайберләренең сүзләре бөтенләй дә күңелгә тия. Мәсәлән, миңа Илсөя Бәдретдинованың җырлаганы моңарчы бик ошый иде. Аның тавышы да матур, җырының сүзләре дә мәгънәле була. Тик бер көнне яраткан җырчым үтә дә сәер бер җыр җырлап, аптырашка калдырды. Ул җырның исеме хәтеремдә түгел, «Мин Путинны телим» дигән сүзләре генә колагымда яңгырап тора. Бу җыр илебездәге демографик хәлгә бик зур йогынты ясар инде. Илсөя ханым шушы җырын җырлаганда, аның өчен оялып утырдым. Тарихта мондый җыр җырлаучылар элек тә булган икән ул. Гитлерны да теләүчеләр күп булган, имеш. Яраткан журналым аша Илсөя ханымга мөрәҗәгать итеп: «Илсөя сеңлем! Бу җырыңны җырламачы, зинһар! Син бит барлык татар хатын-кызлары исеменнән җырлыйсың. Безнең татар хатын-кызлары инсафлы, хисләрен дөньяга чәчеп йөрмәүләре белән аерылып тора», – дип әйтәсем килә. Җырлыйм дисәң, башка яхшы җырларың күп бит синең.

Габдулла ЛАТЫЙПОВ.
Бөгелмә шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU











МАМАДЫШ ӘТИЛӘРЕ



Мәдинә АВЗАЛОВА

НӘРСӘГӘ ГЕНӘ ӨЙРӘТМИ АЛАР БАЛАЛАРНЫ: УЧАК ТЕРГЕЗЕРГӘ ДӘ, ПАРАШЮТТАН СИКЕРЕРГӘ ДӘ, БАЛЫК ТОТАРГА ДА... Ә ИҢ МӨҺИМЕ – СОЛДАТ БУЛЫРГА, ВАТАННЫ ЯРАТЫРГА...

Гомеребез гел үзебез ясаган хаталарны төзәтеп уза икән безнең. Болай дип әйтмәс идем, мисаллары күз алдында: әйтик, әле кайчан гына бала туулар кими, илдә демографик кризис дип борчылган идек. Бу проблемадан чыгу юлын да таптык. Балалар арта башлады. Шундый кискен артып китте ки, хәтта инде хөкүмәтебез, матди кызыксындыру чараларыннан баш тартырга микән әллә, дип тә уйлана калды. Ләкин бала табып кына гаилә проблемасын хәл итеп булса икән ул?! Әгәр дә без бүгенге көндә өйләнешкән һәр дүртенче гаилә таркала, һәр дүртенче гаиләдә туган бала әтисез кала, дип әйтәбез икән, димәк, бусы инде үзебез тудырган проблеманың тагын да саллырагы,

җитдирәге. Әтисез баланың, бигрәк тә ир баланың үсә-үсә кай якка каерылуын беләбез. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте биргән мәгълүматларга караганда, яшүсмерләр арасында да җинаятьләр шактый. Фактларга һәм саннарга килгәндә, хәл бер дә тынычланырлык түгел. Кайсы сукбайлыкта, кайсы шикле төркемнәрдә йөргән ул малайларга әти сүзе, ә кайчак бәлкем, әти чыбыгы җитмәгәнен әйтү кирәк микән?!

Педагоглар да шул турыда сөйләп тора. Әйе, мәктәпләрдә дә, балалар бакчаларында да хатын-кызлар эшли. Ир затыннан булган педагоглар юк дәрәҗәдә. Шулай итеп, безнең киләчәк, ягъни балаларыбыз тулысы белән хатын-кыз кулында. Ирләр кая киткән соң? Ә алар акча эшли, вакытлары юк яисә эштән арып кайталар... Мең төрле сылтау, мең төрле сәбәп... Әтисез үскән бала икеләтә бәхетсез: ул аны күрми дә, белми дә. Ә бит сагына ул аны, әтисе булмауга кимсенә.

Тамчы да тама торгач, ташны бер тишә, диләр бит. Балага әти тәрбиясеннән башка булмый дип, туктаусыз кабатлый торгач, бу катлаулы мәсьәләне дә хәл итү юлы табылды.

Без һәрвакыт бергә

Мамадыш шәһәренең Әтиләр советы рәисе Айрат Шакиров белән шул юлның бормалы сукмаклары буйлап атлыйбыз. Ул сөйли, мин тыңлыйм. Могҗиза, бер уйласаң. Күз алдыма аркаларына биштәр асып, походка чыккан кыз һәм малайлар, учак янында эчкерсез сөйләшүләр, балык тоту күренешләре килеп баса. «Бервакыт җәен балыгы тоттык. Зур! Шатлыкларыннан малайлар ни эшләргә белмәде», – дип дәвам итә сүзен Айрат. – Без бит аларны учак ничек янганын карап утырырга чакырмыйбыз. Ә учакны ничек кабызырга, балыкны ни рәвешле каптырырга кирәклеген өйрәтәбез. Походка чыгабыз икән, бала аннан нинди дә булса яңалык – сабак алып кайтырга тиеш».

Игелекле эшләре белән республикага танылган Мамадыш әтиләренең хәрәкәте кинәттән, тиктомалдан барлыкка килмәгән. Кайсы десантчылар, кайсы «Гвардия» гаскәрләрендә хезмәт итеп кайткан Айрат иптәшләре белән аңарчы да – районда Әтиләр советы эшли башлаганчы ук – малайлар өчен «Яшь десантчылар» клубы оештырып җибәргән булган.

– Кайда урнашкан соң ул? – дип кызыксынабыз. – Безнең десантчы малайларны күрәсе килә.

– Шунда барабыз ич инде, – ди Айрат Шакиров. Без зур бина каршына килеп туктыйбыз. «Академик Камил Вәлиев исемендәге 2 нче номерлы лицей» – республикага танылган иң шәп урта уку йортларының берсе. Иң кызыклы башлангычлар, проектлар шушыннан канат очыра. Танылган рус философының сүзләре искә төшеп куя: «Россиянең бөтен киләчәге – мәктәптә!» Шигарьгә әйләнгән әлеге сүзләрне, әйтерсең, шушы лицейны күзаллап әйткәннәр. Бер бина эчендә, уку кабинетларыннан тыш, ике спорт залы, ике музей, әлеге дә баягы «Яшь десантчылар клубы», концерт залы, электрон мәгълүмати ресурслар үзәгенә әйләнгән яхшы китапханәсе, заманча җиһазландырылган технология бүлмәләре... Әйтерсең, мәктәп түгел, иҗат йорты! Бу коллектив ирешкән уңышларның барысын санап чыга башласаңмы?! Лицейның ЮНЕСКО мәктәбе статусында йөрүен әйтү генә дә җитә. Ул алдынгы фикерләрне гамәлгә ашыру буенча Бөтенроссия сынау мәйданчыгы да. Лицейда 8 хоккей сыйныфы гына бар! Биредә тәрбияләнүчеләр ел саен «Алтын алка» республика ярышларында җиңүче булалар. Болары сүз уңаеннан гына. Бүген сүзебез уку бинасының киңлекты, чиста коридорлары буйлап арлы-бирле йөргән малайлар язмышы өчен үзләрен дә җаваплы санаган асыл ир-егетләр хакында. Хәер, бу данлыклы лицейның директоры Салават Гыймранов үзе дә запастагы офицер булып чыкты. Хәзер мәктәпләрдә ир-ат укытучыларны табуы кыен, дигәннәре мамадышларга кагылмый. Биредә дә күп алар. Кечкенә генә бүлмә янында



Татарстанның Премьер-министры урынбасары, Татарстан «Әтиләр берлеге» иҗтимагый оешмасының җитәкчесе Васил ШӘЙХРАЗЫЕВ.

– Гомер-гомергә гаиләне әти кеше тоткан, бала тәрбияләүдә төп рольне әти кеше уйнаган дисәм, яңалык әйтмәм. Ләкин соңгы вакытта әтиләрнең, гаилә башлыгы буларак, абруе кимегәннән-кими бара. Без бүген гаиләләрне өч төркемгә бүләргә мәҗбүр: беренчесе – гаиләдә әти кешенең дәрәҗәсе зур; икенчесе – дәрәҗәсе юк; өченчесе – әтисез гаилә. Тулы булмаган гаилә ул – җәмгыятебезнең җитди проблемасы. Атасыз үскән бала, бигрәк тә кайчан да бер үзе әти буласы ир бала, әти тәрбиясеннән мәхрүм калып, күп нәрсәне югалта. Шуңа да безнең максат – иң элек шундый балалар белән эшләү, аларда тәвәккәллек, кыюлык, кыскасы, ирләр холкы тәрбияләү. Һәм, әлбәттә инде, гаиләнең дәрәҗәсен үстерү, әти авторитетын күтәрү. Уздырылган һәр чара шуңа юнәлгән. Аерылышуларны кисәтү өчен дә бик мөһим бу. Баласы өчен җан атып торган, җаваплылык тойган әтиләр гаиләне таркатмас өчен барын да эшли.

Татарстанда «Әтиләр берлеге» иҗтимагый оешмасы 2009 елда беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев инициативасы белән барлыкка килде. Бездә бу эш системалы алып барыла. Хәзер һәр районда (ә алар безнең – 45) Әтиләр советы эшли. Түбән Кама, Чаллы, Мамадыш, Менделеев районнарындагы советларның эш тәҗрибәсе башка төбәкләр өчен үрнәк булып тора. Аларның кирәклеген халык та аңлады. Балаларын ялгыз тәрбияләүче әтиләр дә күп бит хәзер. Мондый хәлдә калучыларга психологлар, социологлар ярдәмгә килә.

Безнең республика, илдә беренчеләрдән булып, Әтиләр советларын оештыруга грант бүлеп биргән иде. Былтыр исә Татарстан Президенты нәтиҗәле эшләгән Советларга 1 миллион сум акча бүлеп бирде. Номинация буенча җиңүчеләргә 250 шәр мең сум акча тапшырылды. Әтиләр советлары «Батырлык дәресләре», «Гаиләдә әти роле», «Әти көне» ише төрле чаралар үткәрәләр. Ватанны яратырга әтидән башка кем өйрәтсен тагын?!

PRESSA.RU



■ Салават Гыймранов: «Алар булмаса, тагын кем малайлардан, бигрәк тә әтисез үскән малайлардан чын ир-егетләр тәрбияләр, ватанны, әниләрне, балаларны сакларлык-якларлык кыю-тәвәккәл солдатлар әзерләр?!»

десантчылар киемендәге бер малай кайнаша. Нишли дисәң, уенчык автоматлар сайлый икән. Малай гына димә, ул анда-санда таралышкан малайларга бер генә әйтте, шундук бер сафка тезелешеп бастылар.

«Баласын үзе тәрбияләп үстергән кешедә генә ата хакы бар».

«Суворовчы булам»

Шул арада Айрат безне 11 яшьлек Булат Уразбаев белән таныштыра да, аны бер читтә көтеп торган егетләр арасына кереп югала. Ә Булат белән без стена буендагы эскәмиягә килеп утырабыз. «Айрат абыең сине бик мактый, молодец, булдыра ул», – ди. Ничек таныштыгыз, ничек «ВДВэшник» булдың?» – дим. «Ул мине үзе эзләп тапты. Клубка үзе чакырды», – ди малай. «Сөенденме соң?» «О-о, ничек сөенмисең, ул бит чын десантчы, армиядә десантчылар гаскәрендә хезмәт иткән. Аны монда бөтен кеше хөрмәт итә». «Ә син?» «Мин дә», – ди малай, моңсуланып китеп.

Булатны 90 яшьлек әбисе тәрбияли икән. Ул әнисенең дә, әтисенең дә кайда икәнлеген белми. Сорагач, җилкәсен генә сикертә, күзләренә сагыш йөгерә. «Мин өч мәртәбә парашюттан сикердем, Калашников автоматын 40 секундта җыям», – ди ул горурлык белән. «Десантчы буласың, алайса» – дим, малайны үсендереп. «Юк, мин киләсе елга Казанга – суворовчылар училищесына барам», – ди ул, олыларча фикерле башлап.

– Әйе, әбисе Валентина Павловна белән яши, – ди Айрат, Булат әйткәннәрне җөпләп.

– Ә мин аның белән татарча сөйләштем, – дим, гаҗәпләнә калып.

– Татар телен өйрәнәләр бит алар, күбесе шундый биредә...

Лицей гөж килеп тора. Концертлар залында нәни десантчылар тамаша күрсәтергә әзерләнә. Ә Булат безгә укытучы абыйсы алып килгән парашютчылар киемен киеп күрсәтә. Сүз дә юк, янәшәдә утны-суны кичкән мондый кыю ир-егетләр булганда, армиягә бармыйм дип торучы булмас. Әнә бит, ике егетнең берсе: «Десантчы булам», – дип тора.

– Әтиләр советының эшли башлавына да әле бер еллап кына, – ди киләчәккә планнары белән уртаклаша башлап Айрат. – Без аны сүз өчен оештырмадык. Чын мәгънәсендә эшләү өчен... Кәгазьдә генә түгел ул безнең. Әтиләр оешмасының кирәклегенә инанабыз. Җәмгыятьтә әтиләр роле, әтиләр урыны дип әйтимме, көннән-көн төссезләнә, кими бара. Алар бала тәрбияләүдән читләшә. Нәтиҗәдә, йә бала әтисез, йә бар килеш тә аны күрмичә үсә. Без әтисез балаларга әтисе күрсәтергә тиешле игътибар – тәрбия бирергә тырышабыз. Әлбәттә, әтине алыштыра алмыйбыз. Ә менә ир-егет итеп үстерергә булышабыз.

Ул гаиләсен ташлап киткән бер әти белән булган сөйләшүне исенә төшереп ала: «Аның да улын алып, сәяхәт кылган идек. Шуны белгәнме, әллә Әтиләр советының әтисез балалар белән эшләвен ишеткәнме, шалтырата бу миңа, нигә әле син минем малайны тегендә-монда йөртәсең. Аның бит әтисе бар, ди. Ә мин әйттем, алимент түләп кенә әти вазыйфасы үтәлми ул. Балага акча түгел, әти җилкәсе кирәк, дидем».

Гаиләдән бер киткәч, баласы белән аралашып торган әтиләр бик сирәк. Алименттан качып йөрүчеләр дә җитәрлек. Кечкенәдән әни белән генә үскән бала ир кешенең теге яки бу хәлдә үзен ничек тотарга тиешлеген белми. Авырлыкта югалып калу, ни эшләргә белмәү аны ир-егет булып өлгергәч тә эзәрлекли. Ниһаять, моның җитди проблема булуын аңладык. Без кемнәр тәрбиялибез, илне идарә итүгә иртәгәсен кемнәр килер? Җитди мәсьәлә бу. Мамадыш шәһәрендәге Әтиләр советында – төрле һөнәр ияләре, төрле милләт һәм дини конфессия вәкилләре. Ләкин аларның һәркайсының әйтер сүзе, тормыш тәҗрибәсе бар. Бүгенге көндә шәһәрнең биш мәктәбендә шундый советлар эшли. Һәрберсенең үз планы, үз программасы. Һәм аларның һәркайсы гаилә институтын, рухи-әхлакый традицияләрне һәм гаилә мөнәсәбәтләрен ныгытуга, авыр хәлдә калган гаиләләргә ярдәм күрсәтүгә, бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән.

«Безнең өчен чит бала дигән төшенчә юк», – ди ул. Шулайдыр. Әле бая гына да – без лицейда йөргән арада – Айрат абыйлары яныннан бала-чага өзелмәде. Кайсы олыларча кул биреп исәнләшеп китә, кайсы кочаклап ук ала. «Монысы минем малай», – дип елмая улын күрүгә Айрат. «Бишле» алдыңмы, Азамат?» – дибез, без дә елмаеп. «Берне генә түгел, өч «бишле» алдым», – ди бәләкәй малай, үзенә бер горурлык белән.

«Безгә аның белән рәхәт»

– Азамат бүген өч «бишле» алган, – дим ишектән керешли. Без Айрат Шакировның хатыны Гөлия янында. Шулай дигәч, ул көлеп җибәрә.

– Гел шулай без, – дип сөйләп китә ул, – кайтып керүгә үк: «Бишле» алдым, бер гол суктым», – дип мактанабыз. Без көлешеп куябыз. – Хоккейга йөри, бик яратып йөри. Бер көнне яңа алган хоккей таягын сындырып кайткан: «Каты итеп суккан идем, сынды», – ди. Борчылган, еламый гына. Тынычландырдым үзен. «Аның өчен борчылма, тагын алырбыз», – дидем. Азамат 3 нче, ә төпчекләре Салават 1 нче сыйныфта укый. Балалар гел әтилә-

ре янында. Әтиләре белән, башка малайларны да ияртеп, балыкка йөриләр, хоккей уйныйлар, бүтән район хоккейчылары белән үткәрелгән ярышларда катнашалар, җәй көннәрендә туризм белән шөгыльләнәләр. Казанга оештырылган «Әти белән музейга» экскурсиясен сөйләп бетерә алмыйлар. Күп инде, күп саный китсәң...

Айрат аларны үзеннән бер дә калдырмый. «Үлемсез полк» турында ишеткәнсездер? Әтиләре, ике малайны да алып, башкалар белән бергә шул акциядә катнашты. Малайлар әтиләреннән күрә, аныңча булырга тырыша. Безнең гаиләдә тавышны күтәреп тә сөйләшмиләр. Тыныч, рәхәт безгә шундый әти белән. Айрат ул – десантчы. Шуңа малайларга хәрби-патриотик тәрбия җитәрлек безнең. Мондый тәрбия алган балалар тәртипсез үсмиләр.

Гөлия иминият компаниясендә менеджер булып эшли. Ире турында яратып, горурланып сөйли. Айрат 9 нчы сыйныфтан соң техникумга керә. Аны тәмамлагач, Алабугадагы педагогика институтының технология бүлеген тәмамлый. Аннары армия, аннан соң хокук саклау органнарында хөкемгә тартылган балигъ булмаган балалар белән эшләү... Бүген ул мөмкинлекләре чикле булган балалар өчен коррекцион мәктәптә технология дәресләре алып бара... һәм үзенә йөкләнгән иң мөһим бурычларның берсе – әти назына, әти тәрбиясенә мохтаҗ балалар белән тау кадәрле эшләр майтара.

Айратның әтисе балык тотарга төшкән җирдә суга батып үлә. Айратка әле ул чагында 10 яшьләр тирәсе генә була. Әтине югалту ачысының ни икәнен ул бик яхшы белә. «Улларым булса, аларга ир кеше белергә тиешле бөтен нәрсәне өйрәтәчәкмен, дип хыяллана идем», – ди ул. Һәм сүзендә тора да.

Десантчыларга һәйкәл

Җиңү паркында һәлак булган десантчыларга куелган һәйкәлне без дә күрдек. Монысын да Әтиләр советы белән берлектә башкарылган эш дип фаразларга кирәк. Быел Әфганстаннан совет гаскәрләрен



■ Гөлия Шакирова: «Без Айрат белән һәр эшне киңәшләшеп эшлибез. Шул чараларга кагылышлысын да...»

чыгаруга 38 ел тулу уңаеннан төрле хәрби-спорт чаралары уздыру көтелә. Азга гына да дилбегәне ычкындырып тору юк. Барысы алдан планлаштырылган, алдан уйланылган. Әйткәнемчә, кәгазьдә генә түгел алар, чынбарлыкта. Мәктәпләрдәге Әтиләр советлары оештырган әлеге чаралар Айрат Шакировтан башка узмый да. Шуңа ул бөтен җаваплылыкны тоеп әйтә ала: әйе, эшлиләр, берәү дә күз буяп маташмый. Ә кемгә кирәк ул аннары андый советлар, берлекләр...

– Айратның күп вакыты чит балалар янында үтә. Моңа ничек карыйсың? – дим.

– Әлбәттә, уңай, – ди, соравыма гаҗәпләнгәндәй булып Гөлия. – Мин генә димим, совет составына кергән бизнесменнарның, хокук саклау органнары хезмәткәрләренең, педагогларның хатыннары да шулай карый. Балалар гына түгел, үзләре дә канәгать бит башкарган эшләреннән. Моңа башкача тагын ничек карарга мөмкин? Әйтә алмыйм...

«Өч дөнья чемпионы үстердек»

Мөмкинлекләре чикле балалар өчен коррекцион мәктәп директоры Мансур Вәлиев шулай ди. Мондагы бихисап кубоклар төрле сорауларга этәрә. Ничек кенә димә, биредә укучы балаларның физик мөмкинлекләре дә чикләнгән бит. Алар белән дә шөгыльләнәләр, димәк. Директор да шуны сөйләп тора: «Безнең мәктәптә дә Әтиләр советы булачак», – ди. Чөнки беренчедән, аның файдасы күз алдында. Икенчедән, шәһәрнең Әтиләр советы рәисе үзе монда эшләсен дә! Ничек бу эшләрдән читтә каласың инде?

Балалар – безнең киләчәк, дигәнебез купшы сүзләр генә түгел. Бүген нинди тәрбия бирәбез, иртәгәсе көнебез шундый булыр.

Алар инвалид балалар арасында үткәрелә торган бер генә ярышлардан да калмыйлар. Кайда гына булмаганнар, нинди генә призлы урыннар алмаганнар инде. «Гер күтәрү буенча өч Дөнья чемпион үстердек», – дип дәвам итә сүзен директор. Биредә укучы балалар Айрат абыйлары белән бергә уку бүлмәләренә ремонтны да үзләре ясый, кулдан эшләнгән берсеннән-берсе матур уенчыклар, сәнгать әсәрләре турында әйтеп тә торасы юк. Айрат Шакировның эшләре мавыгу гына түгел, чын йөрәктән. Бәлкем, шуңадыр ул җитәкләгән совет республикада алдынгылардан санала. Конкурста җиңеп, 100 мең грант отуларына да гаҗәпләнерлек түгел. Күрсәтерлек, мактанырлык, тәҗрибә буларак кулланырлык бетмәс-төкәнмәс эшләре бар аларның.

PRESSA.RU



РАВИЛӘ ШАМИЛ КЫЗЫ ШӘЙДУЛЛИНА. БУ ХАНЫМНЫ «АРАБЫЗДАН БЕРЕБЕЗ» ДИП БӘЯЛӘҮ ДӨРЕС ҮК ТҮГЕЛДЕР.

Чөнки без түгел бит, ул – «Россиянең иң шәп аш-су остасы», «Иң шәп гаилә бизнесын оештыручы», «Татарстанның иң уңышлы эшмәкәре», 2015 елның «Ел хатынкызы», Татарстанның атказанган сәүдә хезмәткәре»... Тик, шушы кадәр аерымлык сыйфатлары булуга карамастан, ул «арабыздан беребез» булып кала. Гадилеге, тыйнаклыгы белән.

Асия ЮНЫСОВА

ГАДИЛЕККӘ ГИМН

Шагыйрь Равил Фәйзуллин «Гадиләргә гимн» поэмасын болай дип башлап китә: «Тудыручылар! / Туендыручылар! / Киендерүчеләр! / Гыйлем иңдерүчеләр! / Арагызда бөекләр бармы?

Без шуларның берсен таптык дип уйлыйм.

8 нче сыйныфны Теләче районындагы Алан мәктәбендә тәмамлаган Равилә бөеклеккә илтә торган юлның әтисе Шамил белән әнисе Нурания сайлаганыннан атлап китәргә ниятли. Алар икесе дә укытучылар. Тик... югары белемгә илтә торган юлламаны – урта белем турындагы аттестатны алу өчен керәшен авылына йөреп, урыс мәктәбендә укыйсы... Мулла бабаларының фаҗигале тарихыннан хәбәрдар кызның күңеле карыша. Ул, балалыгы белән, русча укуны бабалары тоткан дингә хыянәт итү кебек аңлый. Өйдәгеләргә күрше авыл Янсуарга барып, керәшен өендә яшәп укырга теләмәвенең асыл сәбәбен әйтеп тормый. «Кышка да кайтып тормам, дип, сырмасын, букчасын, песи-копилкага җыелган 5 сум ун тиен акчасын ала да Казанга чыгып китә – Кулинария училищесына шәһәрдә пропискаң булмаса да кабул итәләр икән. Шулай итеп, Моратовларның математик булыр бу дип үстергән башлы кызлары аш-су остасы булырга ният итә. Гаҗәбенә ниләр диясе? Кыз баланың тормыш шөгыле итеп казан-таба тирәсен сайлавына үзләре дә көненә әллә ничә тапкыр учак үрләткән, савыт-саба шалтыраткан якыннары риза түгел! Равиләнең бу ниятен дөнья күргән, заманнарның төрлесен кичергән бабай гына хуплый: «Аллаһы Тәгалә яраткан кешемне ризык янына куярмын», – дип әйткән. Моннан да олы фатиха булырмы? Юк, тагын бер кыйммәтле киңәш белән коралландырган икән әле ул оныгын: «Кешегә авыр сүз әйтмә. Иртәгә әйтермен, дип тыелып кал».

Әллә укытучы һөнәренә гашыйк Равиләнең үзенә бик ансат булгандыр дисезме? Булыр ул укытучы, булыр. (Кулинария училищесы белән параллель рәвештә кичке мәктәптә урта белем алу тарихы үзе бер хикәятлек. Ул мәктәп тарихында унике битле дәфтәр тутырып,

шигъри гариза язып, укыйсы килү теләгеген исбатлаган бала бүтән булмагандыр.) Ә менә шагыйрәлек кадәресе... Хәер, гомер булса, карарбыз әле. Хәзергә...

«Табигать тажы – Кешенең / чын затын саклаучылар, / олы җанлы, киң күңелле, тугры сүзле, садә җаннар...» (Р. Фәйзуллин)

Өч еллык уку тәмам. Уку белән практиканы чиратлаштырып, практика көннәрендә ике көнлекне ашап куюу җаен табып кына җан асраган кичәге студент кызларны төрле туклану урыннарына таратканнар. Хәзер менә үзләренә, җиң сызганып, учак янына басасы. Җитен комбинаты ашханәсендә бригадир безнең Равилә. 50 шәр литрлы 15 казан кайнап тора. Кайсыдыр хәерсезе калган ашны, тоткасыз чиләккә салып, комфорка өстенә куйган. Дәрманлы бригадирның, каударланып, чиләкне ут өстеннән алып читкәрәк күчермәкче булып талпынуы белән, майлы идәндә аягы таеп китеп, шаулап торган кайнар ашны өстенә каплавы арасында бер мизгел. Һәм бу мизгел яшь гомергә дә нокта куйган... куясы... мизгел!.. Ачыргаланып кычкырган аваздан цехтагы станоклар туктап кала: харап булды бала! Өч ай дәвамында җитен комбинатының изоляторында (хастаханәгә илтергә шүрли хуҗалар – эштәге һәлакәт өчен закон бик каты) барган гомер өчен аяусыз көрәшне мин фәкать кинода күргән кебек кенә яза алам.

Беренче кадр: алгы яктан маңгаенннан алып аяк йөзенә кадәр тәненең 67 проценты пешкән кыз ята. Киемен ит кисә торган пычаклар белән телеп төшергәннәр. Сызлану кадәресен тасвирлар өчен сүзләрем юк. Бармак битен үтүккә пешергәне булган кеше болай да аңлар. Шәрә ята бит әле. Чи җәрәхәт өстенә җәймә дә ябарга ярамый. Сызланудан битәр үсмерлектән чыгып килүче саф кыз өчен шәрә ятуы хурлык. Тик хурланып торырлык әмәл юк – дарулар йоклата. Бер заман, дарулардан айнып китеп, күзләрен ачса, янына доктор килгән. Бик өлкән яшьтәге бу могҗиза иясен комбинатның директоры эзләп тапкан. «Кызым, тереләсең киләме?» Пәри төсле булып каласы булса, килми кызның терелəсе. «Юк, нинди булсаң, шул хәлеңә кайтарам мин сине. Тик түзем бул. Кутырларың кычытса да, кашыма, кубарма. Мин сине борынгы ысул белән, халык табиблары гына белгән чаралар белән дәвалармын. Ә син йокла гына». Гап-гади зеленка була бугай ул дару. Кыз, ямь-яшел булып ятканын гына хәтерли. Өшегәнгәдер дә инде, төшенә һаман куе кызыл тышлы бишмәт керә. Хәер, ул бишмәт бары бер кич кенә чөйдә анык булып эленеп торды. Чыбык очы тутиенең кызы, Равиләнең Казан урамында сырмадан йөргәнен күреп, үзенчә аны жәлләп, бүләк иткән иде аны. Иртәгәсен, училищега бишмәт киеп барам, дип, сөенеп уянган кыз чөйнең буш икәнен күрә. «Үзе кияр», – диде тутәе. Бишмәт кенә түгел, иң затлы туннар алып кияр әле Равилә. Хәләл маңгай тирен түгеп тапкан байлыгыннан өлеш чыгарып, бик күп нәүмизләрне, юксылларны бәхетле итәр, аның ярдәмен күреп сөенгән меңнәрнең шатлыгына үзе дә сөенер. Әмма теге бишмәт гомер буе күз алдыннан китмәс. Гомер генә булсын, терелсен генә. Терелүләре генә... Доктор «Яшел бакасы» янына көн дә килә. Сулы куыкларны берәм-берәм тишә, «Бакасының» кабырчыкларын эскәк белән чүпли, аннан зеленкалы таягы белән кызны койма буягандай итеп буйый. Ул арада кыз тагын һушын югалтып, дөньялардан кичә... Тәүге тапкыр кызга көзгене «Яшел бака» алсу «Дуңгыз баласына» әйләнгәч кенә китерделәр. Ул көнне Равилә сөенечтән елады.

Икенче кадр. Бераз рәтләнә төшкән Равилә җиңел такта сорап ала. Өйдәгеләр кыздан хат-хәбәр көтә булыр. «Мин монда үлеп ятам», – дип язарга да ярамас. Кызының «авызы-борыны җимерелгән» хәрефләрен күргәч, әти кеше хафага кала: «Бу кыз хатын трамвайда барганда язганмы, әллә салган баштан укмы?»

Өченче кадр. Караватында яткан кыз саташа бугай. Янына доктор бабай килгән: «Кызым, кызым! Елама! Терелтәм, дидем бит инде. Кияүгә чыгасың киләме соң синең? Элеккедән дә матуррак булырсың. Тик пешүдән куркып калырсың инде. Берәр бүтән һөнәр кирәк булыр сиңа». Сызланып саташканда кемнеңдер берсенең сүзләре, авырту пәрдәсен ертып, колагына кереп калган иде: «Мантымас, югалтырбыз, ахры, бу баланы». Аһ, белмиләр болар кызның холкын. «Булмас, булдыра алмас», дигән саен булдыра торган холык аңарда.

«Җиңүчеләр, җиңелүчеләр, / ризык кадерен белүчеләр, / көне-төне чабучылар, дөнья малы табучылар...» (Р. Фәйзуллин)

Дүртенче кадр калган икән әле. Яшәү өчен көрәшеп яткан кыз баланы һаман да бер төш кереп йөдәтә. Имеш, бик шәп аргамак матур итеп юртып килә дә Равиләне үзе белән китәргә өнди. Аргамакның кушаматы кызга шундый таныш кебек. Аннары, терелгәч инде, авылга бер кайтуында төшен юратып караган иде, бабае аргамакны шундук таныды. Бу синең Кокандтагы Гыйниятулла абзаң Хәбибулла бабаңа биреп җибәргән Кукан булырга тиеш. И-и бахыр, ул мал начарлыкка өндәмәс. Бу якларга кайтып үзе генә хур булды. Аргамакны сукага җигеп елаттылар. Синең төшеңә килеп керүендә бер хикмәт бар, кызым. Аргамакка менү начарга юралмас. Дан-шөһрәт күререң юрыйк без моны.

Аргамак хикмәте яши-яши беленде. Халыкны туендыручы сыйфатында шактый еллар эшләгәч, тарих сәгатендә 90 нчы еллар дәвере суккач, бизнес кына түгел, ил-көн дә аңлаешсызга әйләнгәч, Равилә Шамил кызы язмышына шушы Кукан килеп керде.

Равилә Шәйдуллина производство башлыгы булып эшләгән «Пиццерия», тамак туйдыру урыныннан битәр, университет студентларының, галим-голәмәнең, язучышагыйрь халкының очрашу урынына әйләнеп киткән иде. Теге эшмәкәрлек өчен болганчык, бизнес өчен аңлаешсыз елларда «Пиццерия» дә аукционга куела. Яшьлек егәре сарыф ителгән бу туклану ноктасын әрәм итмисе, ят кулларга бирмисе иде бит. Ә кызыгучылар, тәмгысын сузучылар күп, чөнки урыны бик шәп! Көрәшкә Равилә Шәйдуллина да кереп китә. Куш йөрәкле,

PRESSA.RU





■ «Бөек ресторатор булачак Мурат оныгым. Ул инде 6 яшеннән үзе ипи сала. Хыялы – Парижга барып, кондитерлыкка уку».

ике башлы булгандыр инде. Югыйсә ике бала анасына «бандит стрелкалары»н кичереп, үлчәүгә «җаныңмы, малыңмы» куелган шартларда «Пиццерия»гә кул селтәсә дә ярагандыр. «Җиңеп чыктым бит. Әйбәт кенә эшләп киттек», – ди ул узган елларга борылып карап. Ә бит ул еллар арасында дефолты белән тешләрен ыржайтып торган 1998 ел да бар! Ул дефолттан төп клиентурасы студентлар булган кафе фәкать Равилә ханымның стратег таланты белән генә исән калгандыр. «Доллар алты тапкыр кыйбатланды, әмма пицца бәяләре шул калды. Аның каруы, арзанлы кафе турындагы хәбәр монда йөрүчеләр санын да өчләтә ишәйтте». «Пиццерия»нең ул вакыттагы эшчәнлегенең асылы – хәйриячелек! Үзе арзан, үзе туклыклы, студентларны көне буе тук йөртергә сәләтле, татар пәрәмәче белән итальян пиццасы бергә кушылган, эчлеге тавык ите белән йомыркадан гыйбарәт пиццаның рецепты шул чагында уйлап табылган. Бөтен ризык запасы, акча маясы тотылып бетсә, бетә, әмма «Пиццерия», кризистан клиентлар туплап, җиңүче булып чыга. Инде киңәергә вакыт.

Шул ният белән 2007 елда «Кукан» пәйда була. Нигдидер интеллектуаль кафе иде ул «Кукан». Ризыклары да үзе арзан, үзе ләззәтле, үзе милли... Ерак мәмләкәттән килгән кунакны алып керү өчен дә үтә рәхәт урын. Мондагы җанны ял иттерә торган тынлык! Тәмам европача булу өчен монда, җитмәсә дә, шул журнал – яңа газеталар гына җитмәгәндер. Якындагы «Ленин бакчасы» җәй айларында гомумән дә «Кукан» утарына әйләнә кебек иде. Парижның бер аулак почмагы диярсең. Мин үзем дә елга ике мәртәбә – Җәлилгә чәчәк салган көндә һәм Тукай янындагы шигъри митингтан соң анда дус-ишләр белән сыйланып – кайнар пицца ашап китүне ритуалга әйләндергән идем. Итальян таверналарын хәтерләткән «Кукан» кафесы Европача романтикасы белән җәлеп итә иде. Бер керүемдә, күзлегемне киеп, рамлап диварга эленгән «Грамота»ны укыйсы иттем. «Кукан кафе һәм Кукан аргамак тарихы язылган иде анда. Танышасы иде бит үзе белән.

Ун елдан соң таныштык. Сөйләшеп сүзләр бетмәде. Инде мин сезгә «Пиццерия»не дефолттан алып чыккан, студент халкын тук иткән хикмәтле тарихны да бәян итә алам. Еллар узгач ярый торгандыр инде, әйеме? Менә болай ул. Халыкны тукландыру өлкәсендә әйбәт кенә эшләп киткән Равилә өс-башын караганнан соң, кесә төбендә утырып калган акчасына ул заманда әле арзан йөргән долларларны алып бара. Банкка да салмый (ярый әле салмаган, банклары белән бергә «янып» беткән булыр иде). Ул аларны үз банкына – өч литрлы пыяла банкага салып, алмагач төбенә күмеп куя да оныта. Дефолт җиткәч, маясын ачып караса, банка капкачы кырыеннан су саркып кергән. Ул көнне авылдагы ишек алды чирәменә җәеп, печән урынына яшел долларлар киптерәләр. Менә шул долларлар «Пиццерия»не коткара да инде.

Хикмәтле ханым булып чыкты бу Равилә Шәйдуллина. Аңарда эшнең «тамырына» карый белү сәләте бар. Бу очракта сүзем «Пиццерия»нең подвалына карый белгәнгә күрә барлыкка килгән «Ностальгия» кафесы хакында. Әгәренки Равилә ханым асфальт ваткан чагында бер чите ачылган тәрәзәне абайлап, шул тәрәзәдән эчкә шуышып кереп, борынгы утын сараена юлыкмаган булса, «Пиццерия» астында ук күн диваннар куелган, алтын шәмдәлләр белән бизәлгән затлы ресторан пәйда булыр иде микән. Бу мәйдан өчен җир кишәрлеге дә юллап йөрелмәгән ләбаса. Ә ул дуслар очраша торган урын сыйфатында эшләп тора. Бу җәннәт урыныннан 270 «КАМАЗ» машинасы чүп чыгарылганын белмибез дә бит. Фәкать матурлыкка гына сокланабыз. Гыйнвар аенда тагын бер могҗизаи зал «Дворянское гнездо» рестораны ачылды. Бусы инде зуррак мәҗлесләр өчен. Француз ашчыларыннан ризык пешерү серләрен өйрәнеп кайткан аш-су осталары анда көндезләрен арзан бәягә төшке ашка чакырса, кичләрен кунаклар өчен оркестр уйнап торачак. Лобачевский урамы почмагындагы «көне беткән» борынгы йортны «Ностальгия» яисә «Дворянское гнездо» рестораны итеп

күрү өчен Равилә ханым кебек хыялый булырга кирәктер. Аның хыялыннан башкаларга да өлеш чыга. Хәзер инде ул ярым җимерек йортта, җылы сусыз яшәгән кешеләр яхшы фатирларга күчеп беткән. Өске каттагы буш бүлмәләр рәтен Равилә ханым кунакханә итеп күрә. Әлегә кунакханә ачу тантанасы хыялда көтеп тора.

«Эш кешесенең маңгаендагы тире кибеп беткәнче үк аның хезмәте өчен түләргә кирәк». (Әби сүзләре)

Ресторан сүзе купшы яңгырап, бәйрәм вәгъдә итеп тора кебек. Равилә Шамил кызы янәшәсендә йөзләп кеше өчен бу бәйрәм артында олы хезмәт тора. «Ярты халык үземнекеләр, – ди ул. – Шуңа күрә «әни», «туган апа», «кодагый апа» дип эндәшүләргә аптырап калмагыз. Ел саен авылымнан яңа кызларны алып килеп, эшле итәм. Эшнең һәркайсы дәрәҗәле, дим мин аларга». «Мин үзем дә эштән курыкмыйм. Тавыклар да асрыйм. Бервакыт бакча артындагы чокырда шул тавыкларыма дип, яшь әрекмән урып йөрим. Күрәм: шәп машина килеп туктады. Шоферы, боҗрасы бармагына elenгән ачкычын уйната-уйната, минем янга килә. Ак яулык чөйгән, кызыл эчле галуш кигән әбигә бер тын карап торды бу. Аннары 100 сум акча чыгарып миңа сузды: «Мә, ал әле, әби, шушы акчаны, миннән бер ярдәм булсын. Дога кылырсың», – ди бу. «Рәхмәт, мохтаҗлыгым юк. Догалы мин, биш вакыт намазлы».

Ул изге ниятле кеше бу «әбинең» үзенең нинди зәкят акчалары таратканын белсә иде! Яшь шагыйрьләрнең китапларын чыгарышуларны, онкология чирле балалар хисабына акча күчерүләрне, чарасызларга фатир белән ярдәм итүләрне генә хәйриягә саный Равилә Шәйдуллина. Ә авылдаш әбиләргә еллар дәвамында кайта торган күчтәнәчләр, туган авылы Алан мәчете чыгымнарын күтәрешүләр кадәресе гадәти ярдәмнәр рәтеннән.

«Дөньяның бар читендә / бәхет теләп тирбәтелә / бар бишекләр». (Равил Фәйзуллин)

«Яратам, дип тәүге тапкыр әйткән кешем гомерлек мәхәббәтем, ышанычлы ярым булып чыкты. Бер ул, бер кыз үстердек. Олы балам – Булат – дөнья бәясе егет. Утыз яшемдә чәчемне шушы улым агартты. Алты яшендә минем фаҗигамне кабатлады. Өйдән урамга атылып чыккан сабый өстенә кайнап торган гудрон тулы казан ыргытканнар. Ялгыштыр инде. Әмма баланың битендә ите тешләренә кадәр пешкән, күзе томаланган иде. Тәнен туны саклаган. Ярты сәгать эчендә чәчем ап-ак булды. Хәзер, әнә, үзе өч бала атасы. Безнең зур гаиләнең терәге ул Булат улым. Белеме буенча тарихчы булса да, бергә эшлибез. Тарихы да ярап куя. Яңа ачылган ресторан өчен Болгар чоры ризыкларын барлап йөри әле. «Морзалар пәрәмәче» дигәнен менюга алдык инде. Кызым Айсылу, кемгә охшагандыр, бик чибәр. Шәп шахматчы ул. Дүрт бала анасы димәссең дә аны. Ул – финансист. Безнең өчен бик кирәкле һөнәр. Безнең алты ноктаны берләштергән бизнесның икътисадый лабиринтларын модель кебек сылу киленем Эльмира көйләп тора.

Шулай итеп, җиде онык – алты малай, бер кыз!

Җиденче онык Мәдинәнең исеме бүген үк – Энҗе бөртеге! Мине Дәү әнинең оныклары турында сөйләгәндә ишетеп калган бер җөмләсе әсир итте. «Авылга кайтканда гел музыка тыңлыйлар болар. Зират турыннан үткәндә музыка шып туктый, улларым догада...»

«Риясызлар, җор җаннар, / җырчы, шагыйрь туганнар». (Р. Фәйзуллин)

Равилә Шәйдуллинаның оныклары гына түгел, китаплары да җидәү! Бүгенге көнгә. Кинәт кенә оныклары тиклем татлы шөгыль тапты әле ул. Хәер, нигә кинәт кенә булсын! Ул бит университет белемле татар теле белгече. Эшендә Гомәр Бәширов, Мәһдиев китаплары белән бер кабинетта яши ул. Кафе өстәлләрендә журналлар юк дигән идемме әле? Китапханәнең чып-чыны монда – «Пиццерия» өстендә икән. Аның рестораны подвалга төшсә дә, китаплары югары менгән. Әй андагы китап! Әбугалисина кебек «мәгарәдә» ятарлык. Биек шкафларда – классиклар. Якын киштәләрдә Равилә ханым ярдәме белән китаплары чыккан яшь «классиклар». Өстәл өстендә – үзенекеләр. Җиде онык өчен шигырьләр, әкиятләр яза башлаган каләм хәзер тәмам «азган». Быел гына да Равилә Шәйдуллина-Муратова лирик шигырьләр җыентыгы белән күңел серләрен ачты, аннары («хыял белән Хәтер бергә / җаннар очсын!» – *Р. Ф.*) «Ялантауга ай кунган» исемле проза китабын якташларына тәкъдим итте. Китаплары шундук русчага да тәрҗемә ителеп бара. Документаль диярлек фактларга нигезләнгән проза китабы куллрыннан китап төшкән Алан халкын уятып җибәргәндәй итте. Укыйлар икән бит, үзләрен, авылдашларын танып укыйлар. Чөнки риясыз язылган бу китапта ялган юк. «Минем туган илем – Алан!» Равилә Шамил кызы бу сүзләрне еш әйтә. Китабы белән ул сүзләренең чынлыгын раслаган. «Мин Аланда гына ял итәм. Алан зиратында минем әби-бабам, атам-анам, туганнарым ята. Минем урыным да шунда булыр. Иң тәмле чишмәләр Аланда гына. Быел җәй дустым Миләүшә белән икебез генә белгән Ахирәтләр аланыннан күп итеп җиләк җыйдык». Уразада килеш унҗиде чиләк җиләк җыеп шаккаттырган иде шул.

«Мөмкинме соң мескенләнү... / Кул йолдызга җиткән чорда». (Р. Фәйзуллин)

Равилә ханым шаккаттыра белә ул. Бер көн эчендә җыенып, круизга китеп бара. Аннан кайта да зиратта ерак бабасының каберен эзләп табып, аңа чардуган куеп килә. Әле менә көзге якта Урта диңгез сәяхәтеннән кайтты. Ун катлы йорт кадәрле зур лайнерда океанга чыгу... Бу галибанә күренешне, чиксез киңлекләрне күз алдына китерергә тырышып карыйм. Сорау бирәм: «Югары каста кешеләре генә диңгезләр гизә ала торган ул «Коста»да (лайнерның исеме шулай) ниләр эшләдегез инде? «Белмим, – булды җавап. – Мин яңа китап башладым. Ә океан чыннан да искиткеч. Биек палубадан озак-озак карап тора торган идем. Киңлек, биеклек яратам мин».

PRESSA.RU




Фото: Ксения Богданова

«МИНЕКЕЛӘР...»



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

– МОГҖИЗА КҮРЕРГӘ ӨМЕТЛӘНМӘГЕЗ. БАРЫСЫ ДА КҮПКӘ КАТЛАУЛЫРАК, – ДИП, МИНЕ КИЛГӘНЧЕ ҮК КАТ-КАТ КИСӘТТЕЛӘР.

Читтән караганда бүген инде шактый имин күренгән бу гаиләләрдә иртәгә дә барысы да әйбәт булачак, дип, аларның берсенең дә өзеп кенә әйтә алмавын аңлау авыр түгел. Упкын чиге бит: алга таба адым хәтәр ул, ә башка якка борылып китәргә ихтыяр көче кирәк. Соңгысы исә кешенең үзеннән генә тора.

Әти-әнисе эчкән, социаль яктан ярдәм күбрәк таләп ителгән яки күп балалы булганга күрә мохтаҗлык кичергән 40 гаилә, бөтен район буйлап санаганда, азмы ул, әллә күпме? Нинди күзлектән карыйсың бит. Кайбыч районы җитәкчеләре, мәсәлән, бу санны бик күп дип тапкан. «Иң элек бу гаиләләрдә үсүче балаларны уйладык», – диләр. Районның социаль яклау бүлегендә әлеге гаиләләрнең һәрберсе исәптә. Хөкүмәт билгеләгән барлык акчалата ярдәмне алып торалар. Әмма ул пособие, дотацияләрнең генә аякка басып китү өчен җитмәве берәүгә дә сер түгел. «Нишлик? Аларга тагын ничек ярдәм итә алабыз?» – дип утырып киңәшләшкәч, уртак бер фикергә киленгән: бу гаиләләрдәге проблемаларны ныграк өйрәнү һәм аларны чишү юлларын эзләү өчен кураторлар билгеләргә кирәк. Кайбыч районы җитәкчеләре телендә бик еш яңгырый торган «минекеләр», дигән сүз бөтенләй башка мәгънәне аңлата хәзер. Минекеләр дигәндә, өйдәге җәмәгатьләрен, бала-чагаларын гына күз алдында тотмый алар бүген.

Күмәкләп, ил белән тотынганда, чыннан да «дөньяны үзгәртергә» буламы? Без бүген шул хакта сөйләшәбез.

Альберт Рәхмәтуллин (Кайбыч муниципаль районы берәмлеге башлыгы):

– Бу гаиләләр арасында төрлесе бар: аз керемлеләр, авырулар, эшсезләр... Яшерен-батырын түгел, шулай да эчкечеләр күбрәк. Әлеге кырык гаиләнең 16-17 се безне чынлап торып борчый. Халык хәзер авыл җирендә дә: «Тагын эчкән», – дип, андыйларга читтән генә карап йөри. Ә бит эчкечелек ул – чир, моңардан кешене дәваларга кирәк. Чараның төрлесен күреп карарга кирәк. «Бу бәндә юлдан язган, барыбер бетә инде», – дип, кул кушырып утырырга, битараф булырга ярамый безгә. Иң куркынычы – хатын-кызның шешә белән дусларшуы. Андый гаиләдә тәртип тәмам бетә. Ун ел элек, мәсәлән, Подберезье якларында ир-атлар эчте. Исән калып, айныганнары бүген үзен кулга алды, күпләре вахта белән читкә китеп эшли башлады. Инде өйдә ялгыз калган хатыннар эчүгә сабышты: кайгыны да, шатлыкны да аракы белән юалар. Ни хикмәт, Аллаһы Тәгалә шундыйларга баланы да биреп тора. Безнең районда иң зур проблема – демография мәсьәләсе. Һәр туган сабый өчен бергәләп сөенәбез. Әтисе яки әнисе эчкәндә исә бар авырлык шушы кечкенә кешегә төшә.

«Миңа иң авыр гаиләне бирегез», – дип сорадым. Минекеләр Иске Тәрбит авылында яши. Җиде балалы Николаевлар гаиләсе. Яннарында хәзер дүрт бала калган. Күршеләрендә яшәүче 80 нән узган Анна әбине дә карап торалар. Ире дә, хатыны да фермада эшли. Юк, егылып ятып эчүчеләр түгел. Әмма хәзерге көнгә кадәр газ кертә алмаганнар икән, гаиләдә чыннан да проблема бар дигән сүз. Газ кертү өчен шактый зур чыгымнар кирәк хәзер. «Авыр гаилә» дип, миңа тәкъдим итүләре дә шуңа иде. Үз кесәмнән дә булыштым, Николаевларның үзләреннән дә өлеш кертерергә тырыштык. Безнең төп максат матди ярдәм күрсәтү түгел бит, аларны оялтырга, уйланырга этәрү.

«Исерекләргә булышасыз, – дигән сүз дә ишетәбез. – Гел кемнәндер нидер көтеп кенә утырырга өйрәнмәсләрме?» Әйе, чаманы, чикне саклау бик мөһим монда. «Мәктәпкә әзерләнергә булыш» дигән акция үткәрәбез. Барлык оешмалар, шәхси эшмәкәрләр катнашы белән оештырабыз аны – рәхмәт аларга. Август җитсә, социаль ярдәм бүлеге кызларына шалтыратып: «Безнең балаларны кайчан киендерәсез әле?» – дип сораучылар бар... Тик, кабатлап әйтәм, без беренче чиратта балаларга булышабыз, шундый әти-әнидән туганга алар гаепле түгел.

Эшлисе эшләр байтак, нәтиҗәләр турында сөйләргә иртә әле. Алай да... Унга якын гаиләне айныттык. Алты-җиде гаилә сыерлы булды. Байморза авылында әниләре үлеп ятим калган Чикаловларга газ керде.



■ **Альберт Рәхмәтуллин:** «Үземне көчле кеше санасам да, бала күзләрендә хәсрәт, яшь күргәндә, көчсезгә әйләнәм...»

Чулпан Камалиева (районның социаль яклау бүлеге башлыгы):

– Безнең арада үзенә беркетелгән гаиләгә иң еш йөрүче кеше – Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Фирдүс Әхмәтов. Ул Федоровское авылында яшәүче Поповларда үз кешегә әйләнгәнче бу гаилә белән шактый чиләндек: Чүпрәледәге «Теплый дом» приютына балаларын инде өченче тапкыр илткән идек. Казаннан, иреннән аерылып, кызы белән кайткан ул, авылда тагын ике ир бала тудырган.

Күп балалы гаиләләр Кайбычта – 233, анда 750 бала үсә.

Лена эчә, дигән хәбәр булуга, гадәттә, юлга кузгалабыз – балалар кечкенә бит. Сабый булсалар да, алырга килгәнне беләләр – урамда безнең машина күренүгә, арткы бакча аша чыгып качалар. Гел онытмыйм: берсендә килдек, әниләре исереп йоклап ята. Өйдә ашарга бернәрсә юк! Өстәл өстендә төбендә аз гына кайнатма калган бер литрлы банка тора. Аңа чебен җыелган. Малайларны урамнан тотып, больницага алып кайттык, юындырдык, киендердек. Инде ашатмакчы булабыз. «Кирәкми, без ашаган идек әле», – ди олысы. «Нәрсә ашадыгыз?» – дибез, аптырап. «Пилмән», – ди. Әниләрен шулай яклый алар.

PRESSA.RU

Ана хокукыннан мәхрүм итү дәрәҗәсенә килеп җиткән Ленаны Казанга, наркодиспансерга дәваланырга үзе илтте Фирдүс Шәрипович. «Кодировать» иттерде. Балаларын приюттан үзе барып алып кайтты. Бу гаиләне дөрес юлга бастыруга хатыны Фидая белән икәүләп тотынды алар. Тәрәзәләренә челтәрләр алып килеп элделәр, өс-башларын карадылар. Инде шөкер, елдан артык эчкәне юк Ленаның. Моңарчы фермада сыер сауды, менә хәзер мәктәпкә җыештыручы булып урнашырга йөри. Ире төрмәдә иде, гыйнвар башында чыккан. «Кертмәдем, бергә тора башласак, тагын элеккеге тормыш башлана. Ансыз яшәргә ияләштек инде, ул миңа барыбер таяныч түгел иде», – ди.

Бер генә гаиләнең юкка чыгуына юл кую да ялгыш булыр.

Проблемалары җитәрлек әле. Керемнәре бик аз. Соңгы тапкыр хезмәт хакын ноябрь аенда, өч мең ярым алган идем, ди. Әниләреннән калган йорт та бик тузган, ремонт кирәк. Абыйсы да үз өлешеннән баш тармаган, шуңа күрә йорт Лена исемендә дә түгел. Ә тегесенең ике ел инде хәбәре юк. Эчмәгәч, социаль яклау бүлеге ана капиталын кулланырга рөхсәт итәр, бәлки, шуңа аерым йорт сатып алырга булыр, дип тә хыяллана. Утка, газга түләү буенча бүгенге көндә бурычлары юк – балаларга бирелә торган пособиегә, башка шундый ук гаиләләрдәге кебек, «автоплатеж» хезмәте тоташтырылган: ай саен коммуналь хезмәтләр өчен күпмедер күләмдә акча тотып калына. Әни кешенең үз гаризасы буенча эшләнә бу.

Һәр бәйрәмнән соң, Фирдүс Шәрипович эшкә чыгуга иң элек безгә сугыла: «Кызлар, минеке эчмәгән! Тәртип!» – ди. Бергәләп сөенәбез!

Рәмис Хәялиев (район башлыгы урынбасары):

– Берничә гаиләне сыерлы иттек – андый йортта балалар ач булмый инде. Шуларның берсе – Чүти авылыннан Гөлнара һәм Рәмис Гайнуллиннар. Гөлнара кияүгә 15 яшьтә чыккан, ул бүген җиде бала әнисе. Кечкенәсе – инвалид. (Үгетләп диярлек, шул төпчеген бакчага бирдерттек – бала, әнә, сөйләшә башлаган.) Ире читкә китеп эшләп йөри, аның даими эш урыны булмагач, балаларга пособие ала алмый иде. Гаиләнең эченә кереп, проблеманы өйрәнгәч, бу мәсьәләне дә чишү юлын таптык. Әйткәнемчә, сыерлы да булдылар. Абзарлары юк иде, өянкегә бәйләп булмый – мал башта фермада торды. Әкренләп абзар ясап куйдылар. Инде чиратта – йорт. Аны түбә астына кертәсе, өлгертәсе бар. «Гөбенә» агрофирмасын җитәкләгәндә Альберт Илгизәр улы алып биргән бу өйләреннән дә кысрыграк йортта тордылар моңарчы. Уллары үсеп җитте, хәзер алар кул арасына керер. Тормышын үзгәртергә кеше үзе дә омтылырга тиеш. Ә болай авыл җирлеге башлыгы Алексей Козловның гел күз уңында бу гаилә.

Әйткәнемчә, сыерлы көнең – сыйлы көнең, диләр. Мин үземнекеләргә – Федоровское авылыннан Фәхриевләргә дә: «Сезгә сыер алырга кирәк», – дидем. Натальяның өендә берсеннән-берсе кечкенә биш бала. Сыер турында сүз кузгаткач, башта: «Нәрсәгә ул миңа?» – диде. «Балаларыңа нәрсә ашатмакчы буласың?» – дим. Кечкенәсе бер яшьлек кенә әле... Хөкүмәтнең шундый программасы бар: башмак тана сатып алган кешегә дәүләт 15 мең субсидия бирә, калганын инде үзләре түләп бетерә. Уйлый торгач: «Ярый, без сыер алырга риза», – дип, ире белән икәүләп килделәр. Бик күп документ тутырырга кирәк анда – ике ай чаптык. Аларның да абзарлары юк иде, салдылар. Арткан сөтне саталар да хәзер. Сөт акчасы кергән көнне бәйрәм ясап алгалыйлар. «Балаларыңны алдыртам!» – дим. Бу сүз аны шунда ук айнытып җибәрә – кайчак шулай куркытмый да булмый.

Фатыйма Бикбова (Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары):

Һәр шимбә саен кичен рейдка чыгабыз – хәл белешеп кайту өчен тагын бер мөмкинлек. Ияләштеләр,



■ **Чулпан Камалиева:** «Авыр чакта азрак ярдәм итеп җибәрсәң, кешенең үз-үзенә ышанычы арта».

■ **Фатыйма Бикбова:** «Узган ел ахырында алты гаиләне учеттан төшердек. Моны кайберләренең үзенә дә әйтмибез әлегә.



Кайбычка юллары төшсә, якын кешеләре янына килгән кебек, безгә дә керәләр. Икенче сәбәп тә бар: «Киемнәргә – икенче гомер» дигән акциябез бар безнең. Киемсалымны халык озак кими бит хәзер – социаль яклау бүлегенә китерәләр. Альберт Илгизәр улы моны үзе башлады. Бортас авылыннан Хәбир абый Гайфуллиннар гаиләсе, мәсәлән, өч ай саен килеп тора: тотылган киемне аларга шәһәрдәге балалары җыеп кайтара. Аз керемле гаиләләр өчен бу да зур ярдәм, рәхмәт әйтеп алалар: балаларны ил белән карау гомергомергә булган инде ул.

Минекеләр исә Подберезьедан, Байдуловлар гаиләсе. Ире тракторда эшли, Людмила – өйдә генә, карт әбиләрен карый. Дүрт балалары бар. Ычкынгалый шул... Әмма соңгы вакытта – сирәгрәк. Балаларны да приютка озаткан юк. Безнең сүзләр барыбер колагына керәдер дип уйлыйм. Ул йортта төп проблема – чисталык. Өй җыештыруның, идән юуның ни икәнен белми Людмила. Өйрәтәбез менә... Безнең кызлар, гомумән, күп гаиләләрдә танышуны идән юудан башлый.

Эльвира Камалиева (халыкны эш белән тәэмин итү бүлеге җитәкчесе):

– Минекеләр – Подберезье авылыннан Талановлар гаиләсе. Наташа – ялгыз әни санала, ире белән язылышмаган. Беренче тапкыр аларга барганда дүрт баланың өчесе инде бер ел приютта иде. «Тагын нәрсәгә килдегез?» – дип кычкырып каршы алды Наташа мине. Аннан тынычланды. Безнең төп бурыч – аларны эшкә урнаштыру. Сыер сава ул хәзер. Балаларны алып кайту өчен башта өйне тәртипкә кертергә кирәк иде. Үзе чисталыкны белмәсә дә, кушкач эшли Наташа. Клубта ремонт ясыйлар иде, калган буяуны сорап алып, идәннәрен буяттым. Тәрәзәләренә өйдән иске челтәрләр алып барып элдем – бераз булса да ямь кереп китте.

Беркөнне эшемә Фирдүс абый кергән: «Мин үземнекеләрне приюттан алып кайттым. Синекеләр елап калды – кайтасылары килә. Эшләреңне тизрәк бетер», – ди. Ә Наташаның өе салкын, газ кермәгән, утын ягалар – балалар кайтса авырыр дип, көннәр җылытканны, аннары мәктәптә уку тәмамлаганны көттек. Барып алырга машина бирдем. Дәрес әзерләргә өстәлләре юк иде – эштән өстәл, шкаф илттек. Ире җәен шабашкадан 30 мең акча алып кайтканын белгәч, берәүләрдән тотылган диван алдырдым. Газ плитәләренең ишеге ябылмый иде – шул акчадан плитә алдык. Кайтуга, кечкенәсен балалар бакчасына урнаштырдык. Кайбычка килсә, яныма керми китми Наташа. Кечкенә кызында «шикәр» чире: әле анализлар биреп, тикшеренеп киттеләр – машина белән барып алып, озатып куйдык. Бер яктан җаным тыныч – балалар ач түгел. Колхозның кибете бар – хезмәт хакын азыклата алырга мөмкин. Атлары, бозаулары да бар. Бәрәңге утырталар. Узган яз район кәбестә үсентеләре бирде – аны үстерделәр. Рейдка чыккан саен сугылам үзләренә: күчтәнәч тоттыруга, балалар шунда ук көндәлекләрен күтәреп киләләр. «Начар укысагыз, приютка озаталар», – дип куркыта аларны әниләре. Балалар әниләрен шулкадәр яклый, шаккатасың. Эчеп, йоклаган чагында кергәнем бар: «Әни арыды әле, ял итә», – диләр.

Иң зур нәтиҗә – приютларда Кайбычтан бер бала да юк бүген.

...Үткәннәре турында ничек бар – шулай сөйләгән Лена Попова сүзен кырт кына кисте дә: «Әй, болар хакында искә дә төшерәсем килми инде хәзер», – диде. «Алар инде кабатланмасын», – дип теләдек без. Кабатланмасын!

Ә могҗиза... Кешелеклелек кебек сыйфат та могҗиза кебек тоелган заманда яшибез. Аны бер тойганнар упкыннан читкә атларга көч тапсын иде инде.



■ **Рәмис Хәялиев:** «Попова гаиләсендә бүген тынычлык».

■ **Эльвира Камалиева:** «Алай-болай Наташа эшкә килмәсә, ферма мөдире шунда ук миңа шалтырата: «Синең Таланован юк», – ди...»



ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ

PRESSA.RU



Иң элек бер кыйсса.
Күкнең җиденче катында яшәүче ике фәрештәнең берсе гел болытлар өстенә ятып ял итә, ә икенчесе, көн-төн дими, Җир белән Күк арасында йөреп тора икән. «Бер дә ял күрмисең, нишләп йөрисең соң?» – дип сораган аннан беренче фәрештә. «Мин кешеләрнең: «Аллаһы Тәгаләм, ярдәм итсәнә...» – дигән ялваруларын ташыйм... – дип җавап биргән ул. – Ә син нигә һаман эшсез ятасың да ятасың?»
– Мин ташырга тиешләре: «Аллаһы Тәгаләм, рәхмәт сиңа!» – дип башланырга тиеш шул...
Без бүген рәхмәт әйтергә өйрәнәбез. Ирләребезгә! Бәйрәм уңаеннан елга бер тапкыр күңелләрен күрү генә түгел бу – моннан соң рәхмәтләрне аларга гел кабатлап торачакбыз. «Без алай төчеләнеп ияләшмәгән...» – дияр кемдер. Ә белгечләр: «Телдән әйтү мәҗбүри дә түгел, рәхмәтләрне күңелдән кабатлап йөрү дә җитә», – диләр. «Ни өчен без аларга рәхмәт укырга тиеш әле?! Үзләре безгә әйтсен!» – дип кабынып ук китәр кемдер.
Чү, сабыр! Рәхмәтләр – зирәк хатынның иң зур коралы, ди белгечләр. Күзгә күренми торган коралы...
Ир-атны артык мактап үсендерәм дип уйлаудан курыкмаска кирәк. Аңа тиеш булганыннан 10 тапкыр арттырып рәхмәт әйтәсең икән, сиңа рәхмәт йөзеннән, бераздан ул аны 100 тапкырга арттырып, үзеңне үк сөендерәчәк, диләр.

Гөлнур
ХӘСӘНШИНА

РӘХМӘТ СИҢА...

Бу хакта психолог, хатын-кыз программалары тренеры Зөлфия МАКСУТОВА менә ниләр сөйли:

– Психологиядә «рәхмәтле булу законы» дигән гыйбарә бар. Мин үземә тренингка килгән хатын-кызларның һәркайсына ирләренә 30 рәхмәт язарга кушам. Кемдер аның утызын да бик җиңел яза. Кемдер унга җитә дә туктый. «Башка яза алмыйм. Нәрсә өчен рәхмәт әйтергә соң, белмим», – диләр. (Чынлыкта, гомер иткән кешеңнең 30 яхшылыгын гына табарга була, әлбәттә. Күпләр үзләре рәхмәтсез шул: бирергә түгел, кабул итәргә генә күнеккән. Ир-атка карата гына түгел, бөтен тормышка шундый мөнәсәбәт аларда.)

Яза кызлар рәхмәттән генә торган исемлекне. «Ә аннан соң нәрсә була?» – дип сорыйлар. «Ә аннан соң могҗизалар башлана!» – дим. Һәм чыннан да башлана!

...«Ирем белән үпкәләшеп, өч көн сөйләшми идек инде, – ди кызларның берсе. – Ә миңа «рәхмәтләр»не әзерләргә кирәк – иртәдән бирле уемда шул. Таптым 30 рәхмәтне! Башта бу миңа ватсаптан язды: «Әйдә, Гөмрәгә барып кайтабыз», – дип. Кече хаҗ кылу турында хыялланганымны белә ул! Ә кичен өч улыбызны ияртеп, һәммәсе бергә кайтып керделәр. Дүртесендә дә – чәчәкләр! Үпкәм шунда ук онытылды, дуслаштык...

...Тренингка йөргән хатын-кызлардан берсенең ире галим. «Иремне Франциягә конференциягә чакырдылар, – ди ул. – Бу хакта инде ярты ел элек белә идек. Ярты ел буе аңа: «Франциягә мине дә алып бар әле», – дип ялындым... Рәхмәтләрне яздым, тик ниндидер могҗиза булыр дип ышанмадым. Ә ирем шул көнне кайтты да: «Йә, нәрсә, Франциягә билетлар карыйбызмы?» – диде. Ярый әле урындыкта утырып тора идем...

...Ул кыз миңа тренингка районнан килеп йөрде. Ире шактый кырыс кеше, өйдә аңа бер дә булышмый икән. Аерылышу чигенә җиткәннәр иде иде... Кушкач, үпкәләрне читкә куеп (без тренингта үпкә-рәнҗүләрдән арынырга да өйрәнәбез), иренә рәхмәтләр яза башлады. «Бер нәрсәгә игътибар иттем, – диде ул. – Язып кына бетерәм, «Берәр нәрсә алып кайтырга кирәкмиме?» – дип шалтырата ирем... Гомердә булмаганны!»

Мондый мисаллар шактый миндә. «Рәхмәтле булу законы» ничек эшли соң? Чынлыкта, барысы да бик

гади – могҗизаның эзе дә юк. Физика законнары буенча, безнең һәр уебызның үзенә аерым бер ешлыгы бар. Радиодан билгеле бер дулкынны эзләгән кебек, без үзебез уйлаган кешене «эзләп» табабыз һәм аңа вибрацияләр җибәрәбез. Һәм ул тирбәлешләр, автомат рәвештә, син уйлаган кешенең вибрацияләре белән бер дулкынга көйләнә. Син җибәрәсең, ә ул шул дулкынны кабул итә һәм җавап бирә. «Дулкының» начар уйлардан, ачу-нәфрәттән тора икән, сиңа таба тәгәрәгән «дулкын» да ачу ташлары белән кайтачак. Ә рәхмәттән генә торганда, үзең дә «рәхмәт дулкыны»нда коеначаксың. Иреңә генә түгел, гомумән, бөтен кешегә карата да шулай эшли бу закон.

Ир белән хатын бер-берсенә энергетик канал аша бәйләнгән. Иребезнең кимчелекләренә генә игътибар итәбез икән, ул моны, әлбәттә, сизә һәм аның да күңеле безгә карата начарга гына көйләнә. Кызганыч, без, гомумән, аңарда нигәдер кимчелекләрне ешрак, күбрәк күрәбез шул. Ә өстенлекләрне, уңай якларны «шулай тиеш» дип кенә кабул итәбез. Әйтик, аның тиз генә берәр нәрсә пешереп куюын, командировкадан беркайчан буш кул белән кайтмавын, бәйрәмдә бүләксез калдырмавын... Беренче тапкырда сөенәбез, икенче юлы сөенгән кыяфәт ясыйбыз, ә аннан рәхмәт әйтергә дә онытабыз. Ә күңеле белән ир-ат бездән бу рәхмәтне гел көтә. Хәер, үзебез дә көтәбез бит.

Ә хәзер иң мөһим нәрсәне әйтәм: «рәхмәтле булу законы» рәхмәтләрне бары тик ихлас күңелдән язган очракта гына эшли. Шул чакта гына ул кайтаваз булып кире кайта. Эш тәҗрибәмнән, күзәтүләремнән чыгып әйтәм моны. Тренингка йөрүче бер кыз сөйли: «Дус кызым ире белән ачуланышкан. «Әйдә, утыр да иреңә 30 рәхмәт яз – кичкә үк кайта да, синнән гафу үтенәчәк», – дидем. Дус кызым рәхмәтләрне язды, тик могҗиза булмады... Нигә закон эшләмәде икән?» – ди. «Чөнки чын күңелдән булмаган. Манипуляция өчен генә язганда ул эшләми, бернинди үзгәреш тә булмый», – дидем. «30 рәхмәт»нең кайтавазын тойгач, «ирем тагын менә шуны эшләсен, шуны алсын әле миңа», дип, кызлар кабат рәхмәт язарга утыралар. Яңа күлмәк кию, ялга бару уе белән генә язганда, әйткәнемчә, могҗиза булмый – ихласлык кирәк.

Ирeңә рәхмәтне телдән дә еш әйтергә кирәк. Һәм ул рәхмәт синең үзең аша, сиңа бәйләнеп яңгырарга тиеш. Тренингка йөрүче кызларның берсе сөйли: «Мин «кирәк» дип кабатлый торгач, ниһаять, яңа люстралар алдык. «Алуын алдык, кайчан эләр инде бу боларны?» – дип уйлыйм. Нидер эшләргә авыр кузгала торган иремне, кранны төзәтүен әнә өч айдан бирле сорыйм – исе дә китми. Һаман «иртәгә» ди... Бер көнне кайтсам, люстраларның берсен элеп куйган! Чын күңелдән куандым инде! И-и, мактадым үзен! «Күр, булмә ничек яктырып киткән! Нинди матур булган! Миңа шундый ошый!» – дим. Икенче көнне кайтуыма люстраларның барысы да эленгән иде. Шаккаттым!»

Рәхмәтне кемгәдер түгел, сез үзегезгә әйтәсез.

Шаккатасы юк – иргә «миңа ошый» дигән сүзләр тәэсир иткән. Хатын-кызны куандырырга, бәхетле итәргә ярата ир-ат: «мин бик канәгать», «мин бәхетле» дигән сүзләрне аңа гел әйтеп торырга кирәк. Алар аңа, әйткәнемчә, шунда ук тәэсир итә.

Кызлар кайчак: «Ир-атларга безнең рәхмәтләр кирәкми, аларның моңа исләре дә китми, ишетмиләр дә», – диләр. Ирегезгә рәхмәт әйткәндә, аның йөзендә бер кыл селкенмәсә дә, аптырамагыз – рәхмәтегезне кабул итмәү түгел бу. Беренчедән, рәхмәтләр ишетергә ул ияләшмәгән. Шуңа күрә оялып, югалып кала, «юк, кирәкми», дип баш тарта. Икенчедән, ир-ат хисләрен бик күрсәтми: эчтән генә куана. Иң мөһиме – әйтегез генә, рәхмәтләрегез барыбер аңа барып җитәчәк. Гаиләне алып баруга керткән өлешен бәяләвегез өчен күңелләреннән бик рәхмәтле булачак алар. Үзен бәяләүләрен кем теләми?!

БЕРНИЧӘ КИҢӘШ



Зөлфия МАКСУТОВА

■ Мин, гомумән, һәр хатын-кызга «рәхмәт дәфтәре» булдырырга тәкъдим итәм. Һәм һәр көнне анда берничә рәхмәт язарга: башта, әлбәттә, Аллаһы Тәгаләгә, аннары үзеңә, аннан – якыннарыңа: кайнанаңа, балаларыңа, дус кызларыңа... Күңелдән башкаларга рәхмәтне күбрәк «юллаган» саен, тормышыбызда могҗизалар күбрәк була: муллык килә, безнең өчен яңа мөмкинлекләр ачыла.

■ Тирә-юньдәгеләргә рәхмәтле булу кешегә шундый файдалы – әлеге энергия аның үзенә үк кире кайта. Артып кайта! Ә башкаларга, тормышка карата рәхмәтсез булганда, мондый ресурслар ябыла.

■ Рәхмәтне кабул итә белергә дә кирәк. Кызганыч, без моңа ияләшмәгән. Монысының сәбәбе балачакка барып тоташа: безгә рәхмәтне бик аз әйткәннәр. Шуңа да рәхмәт ишеткән саен: «Юк, юк, кирәкми!» – дип, баш тартырга ашыгабыз.

■ Ялагайлана дип әйтерләр дип куркасы юк, дәфтәргә рәхмәтләрне җитәкчегезгә дә яза аласыз. Үзе бу хакта белмәсә дә, ул аларны барыбер «укыячак».

■ Бик ачу килгәндә, кемдер сине рәнҗеткәндә, үзеңне кулга алып, бераз тынычлангач, аңа рәхмәтләр язсаң, «рәхмәтле булу законы» шунда ук эшли башлый. Рәхмәтнең кайтавазы иң тиз әйләнеп кайткан очрак – шушы.

■ Ирешмәгән уңышлар, тапмаган маллар турында уйлап кайгырганчы, бүгенге көнегез өчен рәхмәтне күбрәк әйтегез.

■ Рәхмәтле булмаган хатын-кызларны ирләре ешрак ташлый.

PRESSA.RU


Фото: Ксения Богданова

КӘБЕСТӘ АШМЫ, ТҮГЕЛМЕ...


Әлфия САМАТ

– КӘБЕСТӘ КОРТКЫЧЛАРЫНА КАРШЫ ТОРУЧЫ БӨҖӘКЛӘР АЛЫП КАЙТЫРГА КУШКАН ИДЕМ БҮГЕН ПАРТКОМ СЕКРЕТАРЕНӘ.

«И-и, Вәфия апа, кәбестә ашмыни инде ул? Икмәк үстерергә кирәк! Иписез яшәп булмый, ә кәбестәсез яшәгәннән кеше үлми. Юк нәрсә белән башны катырма», – диде. Бик кәефем кырылды әле... Кызым, син булса да алып кайтып бир инде шуны. Казанда бар икән ул, менә, адресын биргәннәр иде», – диде бервакыт әни телефоннан шалтыратып.

Безнең әни Вәфия Локманова гомере буена диярлек Актаныш районының Иске Кормаш авылында, ул чагында «Үрнәк» колхозы дип йөртелә иде, яшелчә бакчасы мөдире булып эшләде. Шәбез елгасы буйлап, авыл кешеләренең бәрәңге бакчалары артында гына урнашкан 7-8 гектарлы уйсулыкта элек-электән үк кәбестә үстергәннәр. Әни эшли башлагач, безгә бәләкәй чактан ук шушы бакчадан кайтмыйча, аңа ярдәмләшергә туры килде. Үсентеләрне утыртудан башлап, кәбестә уңышын җыйнап алып бетергәнче, кара көзгә кадәр колхоз бакчасында булдык дисәм дә ярый. Шунлыктан ул эшнең никадәр тынгысыз икәнлеген, кәбестә үсентеләрен яшь бала кебек тәрбияләргә кирәклеген белеп үстек. Урыны килгәнгәдерме, су сиптереп үстермәсәң дә, ишелеп уңа иде ул! Күз керүгә, ап-ак, чиста, тыгыз кәбестәләрне сатып алырга районның кайсы гына авылыннан килмәделәр?! Күрше Башкортстан районнарыннан – Нефтекама, Янаул, Илеш, Камбарка, Бакалы якларыннан кунача килә торганнар иде хәтта. Көзге пычракларда төрле авырлыктагы машиналар ергалаудан авыл урамнары, кәбестә бакчасы тирәләре кеше үтә алмаслык хәлгә килеп кала. Әни, бичара, көндезге ашны да ашый алмыйча, тәмам йончып, караңгы төшкәндә генә кайтып егыла иде.

Һәрбер үсемлекнең корткычлары булган кебек, бервакыт кәбестәгә дә ак күбәләк төште һәм яшь үсемлекләргә зыян сала башлады. Агу сиптерсәң, котылырга мөмкин алардан, әмма әнинең бу ысулны сайларга бер дә күңеле ятмады. Көл, суган сулары ясап сиптереп карады, тагын әллә нинди башка төрле алымнарны да кулланды, ләкин чагыштырмача зур мәйданнар булмаса да, бу бит шәхси хуҗалыктагы бакча гына түгел, гектарлаган кишәрлекне ничек эшкәртеп бетермәк кирәк? Аптыраган үрдәк, арты белән күлгә чума дигәндәй, районга баргач, үсемлекләрне биологик юл белән саклау ысулы турында ишетеп, колхоз идарәсенә киңәш-табышка керүе булган икән әнинең.

...Шулай, туксанынчы еллар башыннан ук, ел саен ак күбәләкләр оча башлауга, мин аңа Казаннан трихограммалар, ягъни корткычлар салган күкәйләрне ашап юк итүче вак кына бөҗәкләрне алып кайтып бирә башладым. Тора-бара, күбәләкләр юкка чыкты, кәбестәләрдән, агусыз, экологик чиста яшелчә культурасы буларак, тагын да мул уңыш үстереп алынды – «Үрнәк» колхозы кассасына бу тармактан шактый табыш керде, ә халыкка сәламәтлеге өчен зыянсыз продукция җитештерелде. Пенсиягә чыккач та, шушы хезмәтеннән озак еллар аерылгысыз иде ул. Дөресрәге, ел саен идарәдәгеләр: «Быелга гына сабыр ит инде», – ди торгач, ун елга якын вакыт узганын да сизмәде.

Инде безнең әни 85 яшенә якынлашып килә. Шулай булса да, бүгенгәчә әлеге шөгылен ташлый алганы юк. Бакчада ике теплицасы бар, бер елны да калмыйча, шунын берсендә, Мәскәүдән төрле сорттагы орлыкларны кайтартып, иртә яздан чәчеп, кәбестә үсентеләре үстерә. Элегрәк аны әти белән икәүләп, район үзәгенә алып барып саталар, йә аерым колхозларга, мәктәпләргә күпләп үстереп бирәләр иде. Соңгы елларда әни үзе сатуга чыкмый инде. Кирәк кеше, күбесенчә, өйдән үзе килеп ала башлады. Шуның өстәвенә, февраль ае керүгә, өйнең тәрәзә төпләре помидор, борыч ише яшелчәләр чәчелгән савытлар белән тула. Кәҗәсе түгел, мәзәге, диләр бит. Район үзәгендә генә түгел, авылларда да аны белмәгән кеше сирәктер. «Заказ биргән кешеләрем бар, ничек аларны мәхрүм итәсең инде, ерак авыллардан киләләр бит алар», – ди. Юкса әни бик күпләрне кәбестә, помидор, кыяр үстерү серләренә өйрәтте, үзләре җир алып фермер хуҗалыгы оештыручылар да булды, инде аңа алмашка килүчеләр дә начар үсенте өлгертмиләр.

Кайчандыр ул эшләгән колхоз бакчасында күрше егете кәбестә үстерү белән шөгыльләнә. Ләкин Актанышның үзендә дә: «Вәфия апа үсентесе бармы?» –

Башка җирдә тагын үстерелгәндерме, белмим, әмма тирә-юньдә Иске Кормаш кәбестәсе ул бренд иде.

дип сорашалар да, булмаса, тезелеп утыручы кәбестә сатучыларны үтеп китеп, 15-20 данә үсемлек өчен Иске Кормашка кадәр килеп җиткәләр. Бәлкем аның иренмичә, бөтен шартын китереп, барча серләрне ачып бирүе, эчкерсез киңәшләре белән игътибарны җәлеп итүе, кирәк булса, хәтта бакчаларына кадәр барып, өйрәтеп-аңлатып кайтуы кешеләрне үзенә тарта торгандыр. Яшелчә сезоны кергәч, өйдәге телефонга да тынгылык бетә, һәркайсына ниндидер киңәш кирәк: нинди сорт кайчан өлгерә, ничек утыртырга, корт төшсә нишләргә? Хәзер мондый сорауларга җавапны интернетыңны ач та кара бит инде! Юк, аларга Кормаш кәбестәчесенең тере җавабы кирәк! Кеше телендә, кәҗә мал түгел, кәбестә аш түгел, дигән әйтем йөрсә дә, кәбестәгә ихтыяҗның бүгенгәчә кимегәне күренми әле!

Әни үзе – яшьтән үк агроном булырга, үсемлекчелек белән шөгыльләнергә хыялланган кеше. Локман бабай гаиләсендәге алты кыз арасында үсеп, 17 яше тулыртулмастан, әллә кайдагы Чирмешән авыл хуҗалыгы мәктәбенә укырга китүен бик хуплап каршы алмасалар да, булдыра алырына ышанганнар аның. Аттан гайре транспорт чарасы юк заманда, башта Агыйдел елгасын кичеп, Нефтекама тимер юлы станциясенә барырга, аннан поезд белән Уфага, Уфадан янә поезд вагоннарында шылтырап, Самара өлкәсендәге Шентала станциясендә төшәргә һәм 24 чакрым юл узып (нәрсә очраса, шуңа утырып, йә җәяүләп!), Чирмешәнгә барып җитәргә кирәк. Күз алдына китерүе дә читен (хәзерге заман баласын шулай укытып булыр иде микән?), ләкин укырга дәрте ташып торган, ихтыяр көче җитешле булган кеше өчен мондый киртәләрне узып чыгу мөмкин, күрәсең.

PRESSA.RU

Иске Богады авылыннан килен булып төшкәч тә, аның зур хуҗалыклы, әмма кулаклыкта гаепләнеп, бар милке таланган хәерче «бай Самат» гаиләсенә әлегүе тагын бер зур сыналу үзәгенә әверелгән. Бабайдан кала килгән зур бакча, ишле мал-туар, кош-корт асрау кәсебе әнигә үзләштергән һөнәрен дәвам итәргә этәргеч биргәндер. Әти гомер буе руль артында: инженер да, механик та, шофер да булды: ерак юлдан кайтып кермәде. Ә әни 23 ел кайнана-кайната белән, ызгышмый-талашмыйча, бер түбә астында яшәүнең авырлыкларын хәзер ул мәзәк итеп сөйли.

Акчага интекми ул: үзенә урын таба алмаганга яраткан хезмәтеннән тәм табып эшли.

Безне – өч кызын үстерү өчен мунчада киез итеген дә басты, әби белән бергә паласын да сукты, түтәлтүтәл итеп чәчүлек суган орлыгын да җитештерде, аны чистартып, саклап, сатарга да йөрде, печәнен дә чапты (соңгы тапкыр бакчадагы печән чүмәләсенә мине менгермичә, үзе «баш очлаганда» әнигә 81 яшь иде), кешедән калышмыйча гектарлап бүлеп бирелгән чөгендеркишер кишәрлекләрендә дә баш күтәрмичә эшләде, колхозның алма бакчасындагы агач-куакларны карап-тәрбияләп, җиләк-җимешен җыйнап алуны да оештырды. «Эш сөяк сындырмый, эшләп үсегез», – дип, безне минут та тик тотмады, һичьюгы, эш юкта эш табып, өелеп торган утын өемнәрен бер яктан икенче якка күчереп өйдерткәненә дә аптырамый идек. Куелган планны үтәгәч, уенга да вакыт калгандыр инде.


Аның яшьлегендәге тыныч холкы, сабырлыгы һәм тәвәккәллеге бүгенгәчә сакланып, һаман да һәркемне сокландырып тора. Хәзер булса, балаларын эшләтеп интектерәләр дигән гаеп тагып, тиешле органнарга хәбәр итәргә дә күп сорамаслар иде. Без әнигә боларның барысы өчен рәхмәтле!

...Файдалы бөҗәкләргә килгәндә, мин үзем онытkан булсам да, аларны куллану тәртибе әнинең һаман да исеннән чыкмаган икән. Гәрчә ул инде байтактан бирле трихограммалар кайтартып аптыратмый, ә бөҗәкләргә каршы көрәшне кулдан гына башкара. Ягъни иртән тору белән, беренче эш итеп, бакчага чыгып китә һәм 20-30 төп кәбестәсенең яфрак асларын берәм-берәм карап, күбәләк салып киткән күкәйләрне кулы белән сытып чыга. Көнгә ике-өч тапкыр да булырга мөмкин бу эш! Суган суын әчетеп яисә утын көленең суын сипкән чаклары да бар иде.

«Фабрикадан кайтарылган әзер бөҗәкләр – трихограммалар, кәгазь капларга салынып, суыткычта сакланырга тиеш, – ди әни. – Кулланыр алдыннан, ягъни ак күбәләкләр оча башлагач, капны өч көн җылыда тотасың. Бөҗәкләр бу вакыт эчендә хәрәкәткә килә башлый. Шушы стадиядәге трихограммаларны артык тыгызламыйча гына чиләккә тутырылган үлән яфракларына җибәрәсең (гектарына 1 грамм чамасы алына һәм ике-өч мәртәбә эшкәртеп чыгарга җитә). Бераздан трихограммалар яфракларга ияргәч, ун атлам саен берәр яфракны кәбестә өстенә куеп чыгасың. Шуннан соң, файдалы бөҗәкләр кәбестәләрдәге корткычлар салган күкәйне ашый башлыйлар. Кәбестәләр исән-сау килеш кала. Ә трихограммаларның зыяны юк. Вакыт узу белән алар үзеннән-үзе юкка чыга».

Элек бу файдалы бөҗәкләрне Татарстан үсемлекләрне саклау станциясендәге биофабрикада җитештерәләр иде. Хәзерге вакытта ул «Россельхозцентр» учреждениесенең Татарстан филиалына карый. Елына биредә якынча 90 миллион чамасы трихограмма үрчетәләр икән. Димәк, республика районнарында үсемлекләрне саклауның биологик ысулына мөрәҗәгать итүчеләр, экологик чиста продукция җитештерүчеләр аз түгел...

ВӘФИЯ АПА КИҢӘШЛӘРЕ



- утырту өчен, гадәттә, үзем колхозда эшләгән чорда ук сынаган сортларны: иртә өлгерә торган «Июньский № 1», «Казачок», уртача өлгерешле «Слава Грибовская», «Подарок» һәм соң өлгерүче «Амагер», «Колобок», соңгы берничә елда – «Валентина»ны сайлыйм;
- күпләп утыртырга уйлаганда, орлыкны Мәскәүдән, килограммы белән сатыла торганны кайтарту отышлырак;
- кәбестә үсентеләре ике яфракта чакта чыккан вак чебеннәрдән котылу өчен, кәбестәләрнең өсләренә су сиптереп, көл сибәргә кирәк – чебеннәр көлгә куна алмый;
- кыш көне суган кабыкларының берсен дә ташламый җыеп барам. Аннан, чиләккә тутырып, өстенә су салып куям һәм шул суны кәбестә яфракларына сибеп чыгам: кәбестә башланганда чыга торган ак күбәләкләр аның исен яратмый. Әмма бу суны кәбестәнең үзәгенә сибәргә ярамый – ул аны черетә;
- кәбестәләр исәя башлагач, өсләренә, сындырып, әрем куям – күбәләк аның исен дә яратмый.
- кәбестә дымлырак, түбәнрәк урында әйбәт үсә.



ҖӘМГЫЯТЬ

■ **Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Согуд Гарәбстанына визиты кысаларында Җиддә шәһәрендә Ислам хезмәттәшлеге оешмасы Генераль секретаре Йосыф бин Әхмәд әл-Осеймин белән очрашты. Бу хакта җирле матбугат: «Король Татарстан Президентын кабул итте», – дип, зурлап язып чыкты.**

■ **Татарстан башлыгы Рөстәм Миңнеханов Казанда Тунис Республикасының эшлекле даирәләре вәкилләре белән очрашты. Татарстан белән Тунис арасындагы мөнәсәбәтләрне тагын да активлаштыру, бизнесхезмәттәшлекнең кирәклеген ассызыклап, Татарстан җитәкчесе, Тунис аркылы Алжир һәм Марокко базарларына чыгу мөмкин, дип белдерде.**

■ **Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Мәскәүдә Россия мәгариф һәм фән министры Ольга Васильева белән очрашты. Алар мәгариф өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган проектлар, Казан федераль университетының алга таба үсеш перспективалары турында фикер алыштылар. Очрашуда республиканың фән һәм мәгариф министры Энгель Фәттахов белән КФУ ректоры Илшат Гафуров катнашты.**

СПОРТ

■ Тимераякта фигуралы шууның парлы төрендә чыгыш ясаучы Россия спортчылары Евгения Тарасова белән Владимир Морозов Чехиядә узган Европа чемпионатында җиңү яулады: Европа чемпионнары дигән исемгә лаек булдылар. Евгения Тарасова – Казан кызы. Фигуралы шууда беренче адымнарын Татарстанда ясый.

■ Татарстан кызлары Марта Мартьянова, Әдилә Габдрахманова, Оксана Демышева һәм Анастасия Семенова фехтование буенча Россия беренчелеге кысаларында юниорлар арасында рапирачылар турнирында җиңде. Нәтиҗәдә, Татарстан кызлары фехтование буенча Россия беренчелегендә алтын медаль яуладылар.

■ Казан «Гимнастика үзәге»ндә нәфис гимнастика буенча Россия беренчелеге узачак. Ярышларда Россиянең барлык федераль округларыннан 150 дән артык гимнаст катнашачак. Катнашучылар федераль округлар буенча команда зачетында, ә финалисткызлар күп төр ярышта шәхси беренчелектә һәм аерым төрләрнең финалларында көч сынашачак.

КОТЛЫЙБЫЗ



■ **Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының музей фонды җитәкчесе, шәһәрнең мәдәни тормышына һәм театр үсешенә зур өлеш керткән Рәмзия Такташны 85 яшь тулу уңаеннан зур юбилее белән котлыйбыз!**

МӘДӘНИЯТ

■ **Мәскәүнең А. Бахрушин исемендәге Дәүләт үзәк театры музеенда «Татар театры тарихы плакатларда һәм афишаларда» дигән күргәзмә ачылды. Анда беренче театр труппалары («Сәйяр», «Нур») афишаларыннан уникаль җыентык, татар эшчеләр, колхозсовхоз театрларының, Камал театры чыгарган афишалар тәкъдим ителде.**

■ **М. Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә П. И. Чайковскийның «Пиковая дама» операсының премьерасы белән Федор Шаляпин исемендәге 35 нче Халыкара опера фестивале ачылды. Фестиваль күптән инде республиканың мәдәни брендына әверелде. Казан тамашачысы алдында Бөекбритания, Вена операларының, Зур театр, Мария театрының йолдызлары җырлады.**



МӘГАРИФ

■ Казанда «Яшь профессионаллар» (WorldSkills) төбәк чемпионаты узды. Ярышларда 18–22 яшьлек көллият, техникум студентлары һәм яшь белгечләр катнашты. Краснодарда узачак Бөтенроссия финалына Татарстан җыелма командасы составы расланды.

■ Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы «2014–2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында татар теленә «Фиксики» («Фиксиләр») мультсериалын тәрҗемә итте.

■ Татарстан Фәннәр академиясендә Тукай энциклопедиясен тәкъдим итү тантанасы узды. Тукай энциклопедиясе киләчәктә рус, инглиз һәм башка телләргә дә тәрҗемә ителәчәк. Шулай ук аның интернет версиясен булдыру да күздә тотыла.

■ Татарстанда «Ата-аналар БДИ тапшыра» Бөтенроссия акциясе узды. Ата-аналар балаларның ничек имтихан тапшыруларын үз мисалларында күрде. Имтихан биремнәрен эшләүдә республиканың барлык районнары да катнашты.

PRESSA.RU



БЕР ӘНИНЕН ӨЧ КЫЗЫ

– ЭТИ БЕЛӘН ӘНИГӘ РӘХМӘТ – ТЕЛНЕ САКЛАДЫЛАР. УЛ БЕЗНЕҢ ӨЧЕН ХӘЗЕР ШУНДЫЙ ЗУР БАЙЛЫК!

Әңгәмәдәшләремнең татарча шундый матур итеп, яратып, тәмләп сөйләүләрен, кызганыч, сезгә ишеттерә алмыйм...

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

Әтиләре Шәфыйкның: «Укыйсым килә!» – диюенә, әниләре Гәүһәр: «Андый теләгең булгач, әйдә, укы», – дип җавап бирә. Өч, дөресрәге, алты балалы (иренең Теләче районындагы Баландыш авылында ятим калган өч энесен дә алар үстерә) яшь хатынга ирен Казанга укырга чыгарып җибәрү җиңел дә булмагандыр, бәлки. Әмма үзе дә Кызыл Мишәдә аталы мулла гаиләсендә үскән, укымышлы нәселдән булган укытучы кеше гыйлем алу юлында ничек киртәгә әйләнсен, ди?! Әтиләре башта педучилище тәмамлый. Дүрт ел урынына – ике елда! Кызыл дипломга! Аннан Казан педагогика институтының физматында белем ала. Бу юлы алты ел урынына дүрт ел дигәндә кабат кызыл дипломлы була. Институт тарихында булмаган хәл: аңа – читтән торып укучы студентка аспирантурага юллама бирәләр! Эшкә исә аны Кемерово шәһәренә җибәрәләр – Себер җирендә Нотфуллиннар шулай төпләнә.

Гөлнур ханым: Без башта Кемеровода татарлар үзебез генә дип уйлап йөрдек. Аннан әти табибка бар-

гач, берәүгә татарча фамилия белән дәшүләрен ишетеп, аны туктаткан. Шахтага эшкә килгән Сабир абый һәм Рабига апа гаиләсе белән шулай таныштык. Алар безгә якын туганнар кебек күренделәр!

Рәйханә ханым: Беребезгә – 8, икенчебезгә – 9, өченчебезгә 10 яшь иде барып төшкәндә. Русча белмибез... Әни, укытучы эшен ташлап, безнең белән дәрес әзерләргә утырды. Мәсьәләләрне башта татарчага тәрҗемә итәбез, эшлибез, аннары кире русчага күчерәбез. Бер елда без русчага тәмам өйрәнеп җиттек. «Кара, болар телне оныта бит», – дип, әти белән әни өйдә яңа кагыйдә керттеләр: русча сүз әйтсәң, штраф – әти маңгайга чиертә. Телне шулай саклап калдылар...

Гөлнур ханым: Безнең өйдә «белмим» дигән сүз яшәмәде. Әмма: «Бу ничек, дип, берәүдән дә сорама, татар булганга надан диярләр, синнән сорасыннар, – дия иде әни. – Ул татар, шуңа күрә акыллы дисеннәр». Өчебезнең дә канына шулай сеңдерделәр.

Гомер буе югары математика кафедрасын җитәкләгән Шәфыйк аганың кызлары, әлбәттә, әтиләре юлын сайлый – Кемерово педагогика институтының математика факультетын тәмамлыйлар. Өлкән кызлары Гөлнур Әхмәтшина – физика фәннәре кандидаты, доцент, Иркутск педагогика университетының физика, математика һәм информатика факультетында 40 ел эшләгән. Уртанчылары Рәйханә Григорьева – программист. Исәпләү машиналары өчен программалар язган. Кемерово хисаплау үзәгендә, статистика идарәсендә, банкта бүлек начальнигы булып эшләгән. Төпчекләре Фәимә Улан-Удэда яши. Башта заводта, аннан республика хисаплау үзәгендә программист вазыйфасын башкара. Мәктәптә дә, институтта да, эш урыннарында да бервакытта да аларга Галя, Рая яки Фая дип дәшмәгәннәр. Кая ул! Бу мәсьәләдә аларга әтиләре үрнәк. Кемерово педагогика институты ректоры, Татарстаннан килгән яшь белгеч белән танышуга: «Исемегезне әйтеп тә булмый. Әйдә, сезгә Александр Николаевич дип әйтик», – ди. Әтиләре шунда: «Я вам не собачка, чтобы мне клички давать», – дип җавап бирә... Тарих кабатлана. Иркутскига аспирантурага укырга кергән Гөлнур Шәфыйк кызына профессоры: «Исемегезне әйтә алмам, сезгә Вера Николаевна дип дәшәрмен», – ди. Әтисе кебек үк булмаса да, Гөлнур ханым да ныгытып әйтә: «Әлифбада булмаган хәреф юк исемемдә», – ди. Шуннан соң институтта кызык хәлләр башлана: моңа кадәр Нелла Владимировна булып йөргән укытучыларның берсе Зәйнәп Асадулловна булып китә, Алла Семеновна дигәне – Гарифә Сабировна...

Туксанынчы еллар җитә. Чит халык арасында яшәгән татарлар да бер-берсен эзләп таба, аралаша, берләшә башлый. Әңгәмәдәшләрем белән сүзебез дә шул якка – сөйләшүебезнең төп темасына борыла. Чөнки өч кыз туганның өчесе дә бүген милли тормыш эчендә кайный. Хәер, бу эшкә башта әниләре тотына әле.

Гөлнур ханым: Кемеровода сөргенгә сөрелеп килгән татарлар күп. Ә аларның күбесе чыгышы белән мулла нәселеннән. Дингә тартылулары гаҗәп түгел. Халык: «Коръән укыйсы иде», дигән теләк белдергәч, почтамт башлыгы булып эшләүче Хәбибуллин дигән татар кешесе картотека буенча әнине эзләп тапты. Без Сабадан күчеп килгәннән бирле «Чаян», «Казан утлары», «Азат хатын» журналлары алдырдык. Ә «Казан утлары» ул чакта гарәп теле дәресләре бирә башлаган иде. 1991 елны Хәбибуллин, әни һәм Рәйханә «якшәмбе мәктәбе» ачып җибәрделәр.

Безнең әни – әйткәнебезчә, мәгърифәтчеләр нәселеннән. Әнинең әнисе Оркыя әби совет мәктәбендә эшләсә дә, биш баласы да Коръән укый белә иде. Әби кичләрен яшереп өйрәткән. Балалар укысын, дип, бабай үзенең актыккы кирза итеген сатып, керосин лампасы алып кайткан.

Татарстанның уңышлары белән бик горурланабыз – үзебезнең дә өлеш бар кебек!

Рәйханә ханым: Кемеровода кечкенә генә мәчет бар иде: элеккеге сәүдәгәрләрнең берсе, йорт сатып алып, шуны гыйбадәт йорты итеп ясаган булган. Динне күтәрү, үстерү өчен әни бик тырышты. Халыкны гарәпчә укырга өйрәтте. Күпләрне намазга бастырды. Никах уку, җеназа тәртипләре белән таныштырды. Әнидә укып чыккан шәкертләр арасында, безнең «Дуслык» оешмасы биргән белешмә белән барып, әңгәмә үткәннән соң, Уфа мәдрәсәсенең 2 нче курсына кабул ителүчеләр булды. Хәзерге имам да әйтә: «Мондагы халык: «Без Гәүһәр апада укыдык, беләбез!» – дип горурлана», – ди. Әйе, хәтерлиләр әле аны...

Иркутскида – Гөлнур, Кемеровода – Рәйханә, Улан-Удэда – Фәимә.

Кемеровоны алар туган як, төп нигез дип саный, шуңа күрә Рәйханәдән башлыйк. Ул бүген Кемерово шәһәрендә татар-башкорт үзәгенең якшәмбе мәктәбендә татар теле укыта. Иң беренче булышчылары – кызы белән оныгы. Әбиләре белән бергә үскәч, балалары татарча аңлый, әлбәттә. Кызы аны бу юлы да менә Казанга: «Бүгенге атаклы татарлар турында докладны үзем әзерлим», – дип озатып калган, әнисе югында ачык дәресне дә үзе үткәргән.

Беренче дәреслекләрне Рәйханә ханым да әнисе кебек башта үзе яза. Аудио-видео материаллар җыя. Дәресенә кырыгышар кеше йөргән еллар булган. Кемдер яңа аралашулар эзләп, гаилә корырга татар кешесе очратмаммы дип килә; икенчеләре балаларын татар итеп үстерергә теләгәнгә дәрескә йөри. Үзен гомер буе Нина дип йөрткән Нурия исемле ханым, мәсәлән, Татарстандагы туганнары белән туган телендә аралашырга хыяллана. Немец милләтеннән булган Евгений Тарасов дигән егеткә исә татар халык җырлары ошый – ул сүзләрен дөрес итеп әйтеп, татарча җырларга тели: «Кара урман», «Сарман», «Әлфия» кебек көйләрне.

PRESSA.RU

«Бер халыкның да җыры моның кадәр матур түгел», – ди. Ә Рәйханә ханымның иң зур хыялы, теләге – аларның барысын да татар теле мохитенә чумдыру. Моңа ирешүнең төрле юлларын эзли ул. Шул юлларның берсе – курчаклар, дөресрәге алар өстендәге милли, тарихи костюмнар. Интернеттан эзләп, өйрәнеп, костюмнарны кызы белән икәү тегәләр. Бу эштә инде чын белгечкә әйләнгәннәр. Сөйләү – бер нәрсә, күрсәтеп бирү – бөтенләй икенче. Әйтик, Сөембикә-ханбикә, Җангали исемле курчаклар өстендәге киемнәр шул чорны гәүдәләндерергә булыша, риваятьләргә яңа төсмер өсти. Сәүдәгәрләр, әби-бабайлар, малайлар-кызлар... Кайсы чабатадан, кайсы читектән, калфаклы, яулыклы, шәлле... Курчаклар коллекциясе шактый бай. Дәрестә алар һәркайчак кул астында, күп сүзләрне курчаклар ярдәмендә күрсәтеп өйрәнәләр: кеше утырды, торды, йөреп китте, уң як, сул як... Скайп аша өлкәнең башка төбәкләрендә яшәүчеләр өчен дә татар теле дәресләре оештыра башлау турында да уйлана Рәйханә ханым. «Өлкәдә татар авыллары бар әле, – ди ул. – Татарлар бирегә дулкын-дулкын булып килгән: Столыпин реформасы вакытында, ачлыктан качып, сөргенгә сөрелеп... Аннан – шахтага эшкә. Калмак татарлары бар – аларның телләре аерыла. Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» китабын укыгач, әби-бабайларның бу якларга килеп төпләнү тарихын җыя башладык. Шуларны туплап, интернетта бит ачарбыз дип торабыз».

Иркутскида халык саны буенча татарлар өченче урында тора.

Гөлнур ханым Иркутскига аспирантурага укырга дип баргач, шунда төпләнеп кала. Иң элек: «Мин бит татарга кияүгә чыктым!» – дип, рус арасында үзен «Володя» дип йөрткән иренең мулла кушкан исемен кире кайтарта. Аннан, илдә үзгәртеп корулар башлангач, шәһәрдә татар мәдәни үзәге ачылганын ишетеп, үзе әйткәндәй, «йөгереп шунда бара». «Ул кадәр татарны минем күргәнем дә юк иде!» – ди. Һәм... милли тормыш эчендә кайный башлый. Чәкчәк, бәлеш бәйрәмнәре, «Ангара таңнары», «Алтын кәләпүш» фестивальләре, Сабантуйлар (бер елны өч кыз өч шәһәрдә өлкә Сабан туен алып баралар!)... Максат исә бер – яшьләр татарлыгы белән горурлансын, телне, гореф-гадәтләрне, динне белсен. Иркутскида «Татар-башкорт мәдәният үзәге»нең үз бүлмәсе бар. Татар теле дәресләре оештырганнар, «Бүләк» фольклор ансамбле эшли. Үзәккә йөрүче яшьләр гаилә коралар. Егермедән арткан! Үз кызы – Софиясе дә ире Рәшит белән шушында танышкан. «Гаиләң булышмаса, үзәктә эшләп булмый», – ди Гөлнур ханым. Кызлары, оныклары – барысы да шушы эш өчен яна.

Утыздан артык курчактан торган коллекция аларда да бар. «Курчаклар өстендәге костюмнар ярдәмендә башка халыкларга татарның тарихын сөйлибез», – ди Гөлнур ханым. Узган ел өлкә китапханәсендә татар курчаклары күргәзмәсе ике ай эшләгән. 52 экскурсия уздырганнар, меңгә якын укучы караган. Гөлнур ханымның үзе әзерләгән чиккән кульъяулыклар күргәзмәсе дә шул ук китапханәдә узган. Аны караганда: «Минем әбием дә татар иде... Ә минем бабам татар!» – дип әйтүчеләр күп булган.

Үзәкнең бар эшен бер язмада гына күрсәтү мөмкинме икән?! Язучыларның иҗаты белән таныштыручы әдәби кичәләр, өлкә буенча шигырь бәйгеләре, дини бәйрәмнәр... Иркутск мәчетенә 115 ел икән. Ишеге бервакытта да ябылмаган!

Иркутскида беренче Сабантуй 25 ел элек узган. «Өчәр мең кеше җыела, – ди Гөлнур ханым. – Халыкны шулай бергә җыю бездә бик авыр. Иркутск өлкәсенең мәйданы унбер Татарстан чаклы. Әйтик, Чун районыннан өлкә Сабан туена дип чыккан кеше башта 2-3 сәгать машина белән бара, аннары 18 сәгать поездда. Шуңа күрә Сабантуйны ике җирдә үткәрәбез. Безнең өлкәнең тагын бер үзенчәлеге бар: Ангара аша күпер Иркутскиның үзендә генә. Турыга 50 чакрым гына булган ара, урап йөри торгач, кайчак 500 чакрымга әйләнә дә куя».

Өлкәдәге татар авылларына 1912-1913 елларда, Столыпин реформасы вакытында нигез салынган. Аларның 100 еллыкларын зурлап үткәргәннәр. Татар авыллары бергә тупланыбрак утыра, бер-берсеннән 10-15 чакрымда гына урнашкан (биредә, гадәттә, авыллар арасы – 30-40 чакрым). Авылларда халык татарча сөйләшә, әмма мәктәпләрдә татарча белем бирү инде беткән. Соңгы башлангыч мәктәпне ябып, укучыларны икенче авылга күчергәннәр. Дөрес, анда татар теле укытучысы бар – атнага бер тапкыр факультатив дәрес алып бара икән әле. (Сүз уңаеннан, Иркутскиның үзендә татар мәктәбе 37 елга кадәр эшләгән. Аннан, «укытучы юк», дип, япканнар.)

Инде Фәимә ханым турында. Ул Улан-Удэда башта заводта, аннан министрлыкта программист булып эшләгән. Хәзер милли үзәктә үз тирәсенә өлкәннәрне туплаган – тегү-чигү белән шөгыльләнәләр. Тагын бер хыялы – татар теле өйрәтү буенча якшәмбе мәктәбе ачу. «Әмма башта үземнең белемнәрне арттырырга кирәк», – дип саный. Шуның өчен «Ана теле» онлайн мәктәбенә укырга кергән. Бу мәктәпне оештыручылар белән гел элемтәдә – программист буларак, аның программасын шомарту, камилләштерү буенча тәкъдимнәрен җиткереп тора.

Өч туган арасында җирле халыкның телен иң яхшы белгәне, иркен аралашканы – Фәимә ханым. Курсларга йөреп, махсус өйрәнгән. Бурятлар үзләре туган телләрен онытып барганда, оныклары белән күбрәк русча аралашканда, Фәимә ханымның бурятча сөйләшергә өйрәнүе әтиләренең теләген чынга ашыру да булган.

Ике ул үстергән Фәимә ханым. Кече килененең бабасы татар икән. Оның та татар исемен йөртәчәк. «Әле шул килене диплом яклый, сеңлебез онык карап калды, Казанга килә алмады», – диде апалары.

...Соңгы көненә кадәр милләткә хезмәт иткән Гәүһәр апаның рухы шаттыр – кызлары аның юлын дәвам итә.



Тулысынча сайтыбызда укыгыз.

ДӨНЬЯ – КУЛАСА...



Ризидә
ГАСЫЙМОВА

блогер: www.syuyumbike.ru

Мин дә ике малай анасы бит! Киләчәктә бер генә дә түгел, ике хатын-кыз мине шулкадәр күралмасын өчен мең борчу-мәшәкать белән үстерәммени мин аларны?!

Үз уйларыма бирелеп бара идем, янәшәмдә утырган ханымның кинәт кычкырып сөйләшә башлавына «уянып» киттем. Телефоннан шалтырата икән.

– Әни-и – ди, – нигә син телефоныңны гел үзең белән йөртмисең? Шалтыратам, шалтыратам, алмыйсың! Куркып беттем! Нәрсә булды соң, дип... Булмады берни дә! Син телефонны алмый, дип, бөтен кешене аякка бастырып бетердем бит менә. Телефонны үзеңнән калдырма инде, әни! Ишетсен колагың, яме!

«Менә бит, әнисе өчен ничек хафалана! Кыз бала, ни әйтсәң дә, кыз бала...» – дип уйлаплар гына бетергән идем, ханым шул арада тагын кемгәдер шалтыратты бит.

– Борчылып торма, – ди, – алды «теге» телефонны! Икенче юлы шул «бестолковый»га бала калдырсаммы!

Әле генә сөенепләр бара идем – кинәт өстемә салкын су койгандай булды. Кайнанасына бала калдырып киткән икән бит бу хатын!

Һәрбер сүзе колакка керә башлады хәзер – кайнанасыннан зарланып иренә дә шалтыратып алды әле ул. Ярый, ире (рәхмәт төшкере!) әнисен яклады: «Без бит әле аннан яңа чыгып киттек, шул арада ни дип шалтыраттың соң?» – дип әйтте, ахрысы. Ире катырак торгачмы, ханым да бераз тынычлана төште, әмма барыбер азаккача үзенекен сөйләде: «Баланы башка аңа калдырырга ярамый!» Калдырмасаң соң! Әллә ялынабызмы? Үзем әчемнән генә аның белән әйткәләшәм, ә үземнең күзләргә яшь тула. Мин дә ике егет әнисе бит, үсеп – буй җитеп киләләр.

– Үзең әйбәт булсаң, киленнәрең дә әйбәт булыр, – диячәксез инде. Әмма хикмәт безнең яхшылыкка-яманлыкка гына бәйле түгелдер шул. Килен белән кайнана арасында, холыкфигыльгә өстәмә тагын табигый каршылык та, мөнәсәбәтләрнең башыннан ук, хәтта бер сәбәпсез үк уяна торган бер-берсен өнәмәү хисе дә ята бит әле ул.

Шул өнәмәүгә тагын бер мисал менә. Бервакыт, көндезге стационарда көндәлек процедураларны йөреп чыкканнан соң, махсус бүлмәдә, йомшак диванда ял итеп утырабыз. Без биредә икәү генә: мин һәм яшь, чибәр бер кыз. Аякларын бөкләп, кәнәфи эченә чумган да, телефоннан (һаман шул телефон инде безнең бөтен тынычлыкны бозучы!) дус кызы белән сөйләшә ул. Кияүгә чыгу мәшәкатьләре белән йөри икән балакай. Булачак ире шулкадәр әйбәт (сүз саен Радигым ди!), ә менә егетнең әнисе... «Туй күлмәген прокаттан гына алмыйсыңмы соң, кызым?» – ди миңа, – дип ярсый-ярсый сөйли кызый телефонга, – Юк, син представляешь?»

Представляю, әлбәттә! Булачак кайнанаңа синең туй күлмәкләрең турында кайгыртып ятмаса да яраган булыр иде дә бит (күлмәк инде ул кибеттән алсаң да, прокаттан алсаң да, киелә), тик Радигын яратып та, әнисен хәзердән үк күралмау шулай ук әйбәт күренеш түгел инде, сеңлем, үзең әйтмешли, понимаешь?

Хәер, дөресен әйтергә кирәк: бу кызый яшендә мин үзем дә күп нәрсәне аңламаганмындыр әле ул. Дистә еллар узгач, үзем дә балалар үстергәннән соң гына: «Иремне дә шушылай – төн йокыларын калдырып, мең мәшәкать белән, яратып, сөеп, кадерләп, зур өметләр баглап үстергәннәр бит», дип уйлый башлаганмындыр. (Ир генәмени әле ул сиңа – һаман без дип, гаилә өчен җан атып яшәүче әтиебез бит ул безнең!) Һәм менә шушындый «кодовый» уйлар, бәлкем, тора-бара безгә теге табигый каршылыкны азмыкүпме җиңәргә этәргеч бирәдер дә, безне сабыррак, киң күңеллерәк, түземлерәк итәдер.

Ә кайнананы нинди уй сабыррак итә ала икән, дим әле мин. Бу хакта уйлый башлауга менә искә төште: бер кайнана килене турында: «Ул бит көн саен минем улыма әзерләп ашата!» – дип сөйләгән иде. Ә нигә? Уйлап карасаң, яраткан улыңның хатын-кыз тәрбиясе күреп яшәве, аннан оныкларның дөньяга аваз салуы – сөенер өчен дә, киленне яратыр өчен дә бик зур сәбәп бит инде ул!

И Ходаем! Без дә шулай уйлый белсәк иде кайнана булгач, әйеме?

Һәм... уйлый белә торган киленнәр насыйп булса икән безгә, дип телим мин!

PRESSA.RU



Әгерҗедә «Сөембикә» журналын укучылар белән очрашу кичәсен Әлфирә Низамова алып барган иде. Җор теле, җылы сүзләре, ихласлыгы белән рәхәт дулкында йөздерде ул. Ә шигырьләре тәмам әсир итте. Үзе турында исә тыйнак кына: «Туган авылымда иҗат итеп яшәүче авыл шагыйрәсе мин», – дип таныштырды. Сөйләшкәндә әйткән фикерләре канатлы сүзләр булып яңгырый: «Иҗат ул – йөрәк эше», «Язасы килеп язабыз», «Бәхетле мин: туган авылымда яшим, туган авылымда иҗат итәм»...
Исәнбай кызы Әлфирәне «Татарстан белән Удмуртия арасында күпер салучы» дип тә, «үзебезнең шагыйрә» дип тә йөртәләр. Әлфирә диюгә, якташлары аның китапларын, җырларын, ул оештырган мәдәни чараларны, «Яңарыш» район газетасында чыккан язмаларын искә төшерә... Шигырьләрен аеруча яраталар!

Әлфирә
НИЗАМОВА

ЧӘЧӘК КҮЗЛӘРЕ БУЛЫП...

* * *

Иртән сездә чык төшәме?
Бездә төшә шигырьләр.
Бездәге чык тамчысының
Үзәгендә шигырь бар!
Безнең якта шигырь көлә,
Чәчәк күзләре булып.
Аланнарда адаштыра,
Болан эзләре булып.
Чәчәкләрне үбә-үбә,
Күбәләк булып оча.
Җаннарга барып сарыла,
Күңелне килеп коча.
Агач башында сездә ни?
Бездә шигырь оялый.
Шунда бала да чыгара,
Беркемнән дә оялмый.
Сездәге кош балалары,
Бәлки, көен көйләтә?
Бездә шигырьне «очарга»
Халык үзе өйрәтә.

Беренче мәхәббәт

Акылдан яздырган,
Ашаудан калдырган,
Уйларны чуалткан,
Ярсыткан, елаткан,
Төннәрен уяткан,
Йөрәккә ут яккан,
Моңайткан, уйлаткан
Беренче мәхәббәт, кайда син?!
Уйнаткан, көлдергән,
Такыялар үрдергән,
Чәчемнән тартмыйча
Янымнан үтмәгән,
Кыюсыз – үпмәгән,
Күктәге йолдызны
Баскычсыз «чүпләгән»
Беренче мәхәббәт, кайда син?!
Хыялдан тау өйдек,
Бәхетле күк идек...
Ул таулар кайда соң?
Син күптән еракта,
Ак күлмәк сандыкта,
Сандыгым саклыйдыр
Кулларың җылысын.
Ә үзең, үзең соң кайда син?!
Исеңә төшәмдер,
Төшеңә керәмдер,
Уйламыйм димә син,
Юк, мин дә уйламыйм!
Тик шигырь эчендә,
Үзәктә – төшендә,
Беркемгә күренми яшисең!
Рәхмәт, беренче мәхәббәт!

Күзләрең яшькелт, диләр

Күзләремне яшел диләр,
Яшелдер лә, ышанам.
Минем хәтта язмышым да
Яшел җәйгә охшаган.

Өерелеп, болыт килә
Кайчак яшен уйнатып.
Яңгырдан соң кояш көлә,
Хисләремне уятып...
Салават күпере төсле
Төрле-төрле көннәрем.
Җәйнең тымызык кичләрен
Хәтерләтә төннәрем.

Иреннәрдә – җиләк тәме,
Шуңадыр кадерлемен.
Җиләк кебек җыеп барам
Җәйләрен гомеремнең.

Күзләремне яшькелт диләр,
Яшькелт икәнен беләм.
Гомер көзләремдә яшим
Яшел җәйләрем белән.

Кайсыгызның җаны кайтты?

Кайсыгызның җаны кайтты,
Ак күбәләк тәрәзәдә.
Чыгар җирен тапмаса да,
Пыялада бәргәләнә.

Кайсыгызның җаны икән,
Бигрәк матур, бигрәк күркәм.
«Күбәләк булып җаннар кайтыр», –
Дия иде миңа әнкәм.

«Оныттылыр, – дия идем, –
Киттеләр дә бер-бер артлы».
Хәлләремне белешергә
Кайсыгызның җаны кайтты?..

Чаллыдан интернет аша бер кочак шигырьләр килеп төште. Хисле, ихлас, һәр юлына ярату сеңгән... Авторы – Рафис Мингалиев. Кызыксынып башладык: кем ул, кайдан? Әлки районы Иске Камка егете икән. Мәктәп елларыннан ук яза. Әлки районы газетасында да, Чаллыга күчеп килгәч, Тукай районыныкында да язмалары, шигырьләре күренә башлый. Рафисның кайбер шигырьләре инде җырга күчкән.



Рафис
МИНГАЛИЕВ

ЯЗМЫШ БЕЛӘН ЯЛГЫШ АРАСЫНДА...

* * *

Кыш. Салкын.
Ә йөрәктә – ялкын!
Тирә-якта хәтта боз эри.
Учак яктым җанда... кышкы учак.
Үзем яктым! Түгел мәҗбүри.
Җылы. Рәхәт.
Тәнгә тула сихәт!
Җаннарыма җылы тарала.
Шундый илаһи бер халәттән
Күркәм нәрсә бармы дөньяда?!
Тик ни гаҗәп: күңел риза түгел!
Тынычланмый – ярсый, ялвара.
Яккан учагымны ятим итеп
Бураннарга таба юл ала...

* * *

Аһ... иртәсе!
Нинди көн соң бүген?
Шатланасы килә, көләсе...
Март аеның якты кояшына,
Күзем кысып, сәлам бирәсе.
Таң җиледәй уйнап, сөйгәнемнең
Чәчләренә кагылып үтәсе.
Кар астыннан яңа шытып чыккан
Умырзая бүләк итәсе.
Иңнәреннән кочып, йомшак кына:
– Бәхетле бул, җаным! – диясе.
Аһ... иртәсе язның, иртәсе!

* * *

Үзем югалудан курыкмыйм мин.
Югалулар – берни түгел лә.
Югалтудан куркам. Югалтулар
Йөрәкләрдә кала гомергә.

Күпме сүзләр калды әйтелмәгән,
Тапланмаган чиста, ак хисләр.
Моңлы бер җыр булып, исләреңә
Төшәләрдер әле ул кичләр?

Син дә парлы, мин дә ялгыз түгел.
Араларда еллар, чакрымнар.
Үткәннәрне үлчәүләргә салсак,
Калкып чыга өскә ялгышлар.

Тәрәз төпләремдә чәчәк ата,
Син яраткан гөлләр-сөмбелләр.
Язмыш белән ялгыш арасында
Өзгәләнеп үтә гомерләр.

* * *

Тыныч кына җиргә ак кар ява
Гаҗәеп бер кышкы иртәдә.
Бер сәбәпсез елмаясы килә,
Җаным тулы сагыш йөрсә дә.

Ак кар ява. Әкрен генә ява,
Бөтерелеп талгын җилләрдә.
Әйтерсең лә, хыялдагы кебек
Күмәм сине ап-ак гөлләргә.

Күңелемне ак төсләргә төреп,
Сагышларым җилгә таратам.
Сине миңа бүләк иткән кышның
Ак карларын өзелеп яратам.

* * *

Мин онытып барам сыман сине...
Төшләремә күптән кермисең.
Куеныма сыенып: «Тыңла әле!
Серем сөйлим сиңа», – димисең.

Синең өчен мин дә яттыр инде...
Күзләреңнән аңлыйм – сөймисең.
Элеккечә, ерактан ук күреп,
Йөгерә-йөгерә каршы килмисең.

Югалтудан сине йөрәк сыкрый:
Мин – каршыңда. Ә син... күрмисең?!
Чәчкәләрем тотып басып калдым.
Син икән бит мине белмисең.

* * *

Беркем көтми безне галәмнәрдә.
Без бит шушы Җирнең баласы.
Җирдә туып, Җирдә гомер кичеп,
Мәңгегә шул Җирдә каласы.

Көтми безне алда ап-ак юллар.
Ул юлларны үзебез ярасы.
Вакыт тузаннарын йота-йота,
Шул юллардан күпме барасы?..

Яшибез без Җирдә бер мәртәбә –
Язмышларның булмый яңасы.
Бу дөньяда җисем булып түгел,
Кеше булып килә каласы...

PRESSA.RU



Солтан
ШӘМСИ

ЧАТНАГАН ЧӘРКӘ

(Хикәя)

Әхәт Казаннан киткән хәрби отряд белән Чечнядан кайтып төште. Казанга кадәр сузылган озын юлда ул, Рәсәйнең таркау тормышын вагон тәрәзәсеннән күзәтеп барып, сөйгәне Камилә турында уйланды. Очрашуның ничек буласын төрлечә күз алдына китерде. Кайвакыт бу очрашу бик интим төс ала да, егет бөтенләй эреп китә, йөрәге ашкынып тибә башлый иде.

Сугыш барган илдә үткән шушы вакыт эчендә Әхәт бик күпне күрде, хәрби хезмәтнең ачысын-төчесен үз җилкәсендә татыды, кырысланды, катыланган күңеле күп нәрсәгә игътибар да итми башлаган иде. Һәр почмактан сиңа автомат көпшәсе карап тормаса да, ул хезмәт иткән ил – ят һәм хәтәр ил иде. Анда тормыш та ят, тормышны аңлау да үзгә. Иң аянычы – кеше гомере анда бер тиен дә тормый, иртәгә исән-сау булуыңа бернинди ышаныч юк. Хәзер менә Әхәт шушы хәтәр дөньядан аерылып, үз Казанына кайтып килә. Анда егетне Камиләсе көтә. Көтә микән соң? Бәлки, Әхәт бу хисләрне үзе үстереп, күпертеп, үз-үзен шуңа ышандырып кайтып килә торгандыр. Асылда, алар арасында берни дә булганы юк бит әле. Әйе, бер сыйныфта укыдылар, соңгы сыйныфта шактый ук якынаеп киттеләр, читтән караганда алар бер-берсенә тиң матур пар иде.

Дөресен генә әйткәндә, Әхәткә Камиләнең уртак хисләр турында сөйләшергә яратмавы ошап бетми, армиягә дә аннан «сөям» сүзен ишетмичә китеп барды. Шуңа да карамастан, Әхәтнең Камиләдән якын кешесе юк. Диңгезчеләр: суднода кок хатын-кыз затыннан

булганда, бер-ике айдан бөтен экипаж аңа гашыйк була икән, һәм теге үзен ирләр арасында королева кебек хис итә башлый, диләр. Әхәт белән дә шундыйрак бер хәл булмады микән – юкса бу кадәр ашкынуны, назга сусауны ничек аңлатырга?

Әхәт армиягә алынган елны Камилә, институтка керергә теләп, имтихан биреп карады, тик артыннан йөрүче танышлары булмагач, үтә алмады. Кичкегә керде дә бер оешмага эшкә урнашты. Тулай торакта Зоя исемле бер кыз белән тора икән.

Әхәт Казанга кайтып, апаларында бер кичне кунды да иртәгәсен кичкырын Камилә янына китте. Күп итеп ашарга-эчәргә алды, ә икенче кулына чәчәк бәйләме тотты.

Тулай торакка керү кыен булмады. «Армиядән кайттым, сеңлем янына киләм», – дигәч, матур букет тоткан солдатны вахтерша хатын тоткарлыксыз кертеп җибәрде.

Менә Әхәт нык дулкынланган хәлдә Камилә торган бүлмә ишеге төбендә басып тора, йөрәге дөп-дөп тибә. Ишекне аңа Камилә түгел, бөтенләй башка кыз ачты.

– Камилә шушында торамы? – дип сорады Әхәт.

– Ә сез кем буласыз?

– Мин – Әхәт. Кичә генә армиядән кайттым, – дип ярып салды егет.

– Узыгыз, тоткарланмаса, Камилә ярты сәгатьтән кайтып җитәр, – дип, кыз солдатны бүлмәгә дәште.

Әхәт бүлмәгә узып, әйберләрен кая куярга белмичә аптырап торганда кыз аңа урын күрсәтте. Кулындагы чәчәкләргә игътибар итеп:

– Әйдәгез вазага утыртыйк, шиңмәсеннәр, – дип, аның кулыннан букетны алды һәм вазага су салыр өчен кухняга чыгып китте.

Дөрес, Әхәтнең букетны Камиләнең үз кулына тапшырасы, биленнән кочып алып, маңгаеннан булса да үбеп аласы килгән иде. Бүлмәдәш кызы егеткә мондый мөмкинлекне калдырмады, вазага утыртылгач, чәчәкләр уртак була инде ул. Моңа егетнең бераз кәефе кырылды.

Ике кешелек бүлмә пөхтә итеп җыелган, күптән түгел ремонт та ясалганга охшый. Ике читтә ике агач карават тора, кием шкафы, стенада китап шүрлекләре, ике тумбочка һәм уртада түгәрәк өстәл. Тулай торак өчен тагын ни кирәк?

Бүлмәдәш кыз, кире кереп, сулы вазага розаларны утыртты да:

– Әйдәгез танышыйк, мин Зоя булам, – дип, егеткә кулын сузды. Аның куллары йомшак һәм нәфис иде, тырнакларын да бик тырышып тәрбияли икән.

Зоя шактый сүзчән кыз булып чыкты. Әхәтнең Чечняда хезмәт итүен белеп алгач, хезмәтенең ничек узуын, андагы хәлләр турында җентекләп сораша башлады. «Утыз яшьләр бардыр, буй-сыны күз төшмәслек түгел», – дип эчтән генә уйлап куйды Әхәт. Тулай торакта яшәп картаеп баручы сазаган кыз.

Ул арада Камилә дә кайтып керде. Әхәт аны күреп алуга урыныннан сикереп торды, кызга якынлашты, аңа чишенергә дә ирек бирмичә, кочагына алды. Ул үсә төшкән, тагын да зифаланган. Камилә моны көтмәгән иде, уңайсызланып кызарып чыкты. Әхәт кочагыннан ычкынгач, тиз-тиз өстен салды, аннан:

– Кайчан кайттың? Бөтенләйгәме? – дип сорады.

– Бөтенләйгә! – Әхәт тә чит кеше алдында үзен ничек тотарга белми иде.

– Нигә хәбәр итмәдең, белеп торган булыр идем, – диде кыз. Ул әле һаман үз халәтенә кайта алмый, сүзне ничек дәвам итәргә белми иде.

Ярый әле Әхәт каушап калмады.

– Кызлар, мин бүген сезнең белән бәйрәм кичәсе оештырмакчы булып килдем. Ашарга-эчәргә җитәрлек, әнә сумкада. Әйдәгез, бер матур итеп утырыйк әле. Все-таки солдат хезмәттән кайтты бит...

– Ура! – дип кычкырып куйды Зоя. – Мондый тәкъдимне хупларга гына кала.

– Син ничек, ризамы? – дип сорады Әхәт Камиләдән.

– Сорап тора тагын... Әлбәттә, риза!

Кызлар, тыз-быз килеп, кухня белән бүлмә арасында йөргәндә, Әхәт тә бер урында гына утырмады. Башта бүлмәне тикшереп чыкты, аннан коридорны бер әйләнде, кухняга да сугылды, анда плита янында торган Камиләнең биленнән кочып, ачык муеннан үбеп алды. Кыскасы, кызлар табын әзерләгән арада биредә тәмам үз кеше булып китте. Әхәтнең бүген Камиләнең ничектер серен ачасы, үзенә карата булган мөнәсәбәтен ачыклыйсы килә иде. Кызый тыштан бик шат күренә, егеткә ягымлы карашлар ташлый, кайтуына сөенгән кебек иде. Эчендә ниләр бардыр, анысын бер үзе генә белә. Ара-тирә килеп торган хатларында да ул күңелендәгесен ачып бетерми, тышкы вакыйгаларны сөйләү белән чикләнә иде. Шушындый көнне дә кыз серен саклап маташса, аның кайдан, нинди җирдән, нинди хәтәр вакыйгалар аша узып, исән-сау килеш кайтуын белә торып та ачылып китмәсә, димәк, Әхәтнең «Камилә... Камилә...» дип өзелеп йөрүләре «буш номер» – юкка хыяллану гына булып чыга.

Әхәт үзе алып килгән аракы-шәрабларны өстәлгә тезеп куйды. Эчү табыны әзерли башлаганда ул, тиздән башына китереп сугачак рәхәт дулкынны күз алдына китереп, эчтән кытыклана ук башлады. Эш шунда: Әхәт армиядән эчәргә өйрәнеп кайтты. Ныклап торып эчә белә торган, тик акылын югалтмыйча эчә белә торган нык егет булып кайтты. Эчәргә аны гел сугыш, хәвеф халәтендә яшәү, даими киеренкелек өйрәтте. Андый шартларда башкача була да алмый иде инде. Сине гел сагалап торган хәвефтән, стресстан, үлем куркынычыннан психиканы башкача ничек сакларга мөмкин иде соң... Шуңа күрә Әхәт әле мәҗлес башланганчы ук күңел күтәренкелеге, ниндидер эйфория кичерде, янында шундый затлар бөтерелеп йөргәндә бигрәк тә.

PRESSA.RU

– Ярар, кызлар, җитәр... Әйдәгез, утырышыйк, – диде ул, ниһаять.

Зоя өстәлгә өч нечкә билле матур чәркәләр китереп куйды.

– Бәллүр чәркәләрдән эчик әле, – диде.

Әхәт, кызлардан сорап, һәркайсының чәркәсенә эчемлек салып чыкты. Зоя акны гына эчә икән. Камилә исә үзенә кызыл шәраб салдырды. Ул әле һаман тәлинкәләр белән маташа иде.

– Беренче сүзне үзең әйт, – диде ул Әхәткә.

Әхәт торып басты, бик тә бәхетле сизә иде ул үзен бу минутта.

– Кызлар, минем өчен бүген икеләтә бәйрәм. Анда, таулар арасында ятканда, мин еш кына уйлый идем: нәрсә калган инде миңа, татар баласына, бу илдә, дип. Бик күпләр юкка һәлак булды, гарип булды. Мин менә сезнең каршыгызда сау-сәламәт килеш басып торам. Икенчедән, минем янәшәмдә сөйгән кешем утыра. Бу да минем өчен зур бәхет һәм сөенеч. Әйдәгез, башка безнең тормышта андый аерылышулар, сынаулар булмасын. Шуның өчен күтәреп куйыйк...

Чәкешеп эчеп куйдылар. Зоя беренче чәркәне төбенә хәтле бушатты, Камилә исә шәрабын бер-ике генә йотып куйды. Әхәт аны мәҗбүриләмәкче иде, кыз баш тартты. Шулай мәҗлес башланды. Табын мул иде. Бер-ике чәркәдән соң Зоя, Камиләдән һич тартынмыйча, Әхәтнең күзләренә керердәй булып, аңа туп-туры карап утыра башлады. Бергә яшәгәч, Камилә белә: Зоя үз тирәсендә берәр егет күренсә, аны ничек тә яулап алырга тырыша, кеше өлешенә керергә бик маһир. Тулай торакта бу яктан аның яманаты да чыккан иде.

Әхәт чәркәләргә сала торды, табын кызганнан-кызды, тик Камилә генә Зоя белән Әхәткә тиңдәш була алмады, ул чират җиткән саен бер йотым белән чикләнде. Бер-ике тапкыр Әхәтнең кабыргасына төртеп:

– Син исереп китә күрмә тагын, – дип кисәтеп тә карады, тик егет:

– Бүген шундый көн, бераз артыкка китсә дә ярый, – дип, үз итеп Камиләне иңеннән кысты.

Шулай да Камиләнең алай читләшеп утыруы егетнең кәефен кыра, ул ничектер компаниядән аерыла, мәҗлеснең көен боза иде шикелле. Ә менә Зоя... Зоя исә Әхәттән һич калышмыйча бара, мәҗлескә җан өрә, кәефне күтәрә иде.

Сәгать ярымлап үткәч, мәҗлес сүлпәнәя төште, шунда Камилә магнитофонны җибәрде, Әхәтне биергә чакырды. Егет инде шактый салмыш булса да, үзен нык тота, чайкалмый, кирәкмәгән сүз сөйләми иде:

– Әхәт, син кем янына килдең? – дип турыдан-туры сорады аннан Камилә.

– Ничек инде? Билгеле, синең янга...

– Бер дә охшамаган.

– Нәрсә охшамаган?

– Үз-үзеңне тотуыңа караганда, бер дә минем янга килгәнгә охшамаган, дим.

Бу сүзләр Әхәтне кинәт айнытып җибәрде, ул үзенең, чыннан да, Камиләгә игътибарын киметүен аңлады.

– Синең яныңа, кадерлем, синең яныңа... Мин бит бу көнне шундый озак көттем. Аңлыйсыңмы?

Кыз дәшмәде.

Әхәт аны үзенә кыса төшеп:

– Әллә үпкәләттемме үзеңне? Гафу ит, – диде.

Зоя бу вакытта бүлмәдән чыгып киткән иде. Ул бу сөйләшүне ишетмәде. Әйләнеп кергәч, Әхәт белән Камилә янына килеп:

– Миңа да батыр солдат белән бер әйләнергә рөхсәттер бит, – дип араларына керде.

Камилә, ирексездән, Әхәтне аңа калдырды, юкса скандалга, тавышка китә иде. Үзе өстәлне караштырырга кереште.

Салмак музыка көенә Зоя егеткә елышып бетеп үк диярлек әйләнә башлады, хәйләкәр елмаеп:

– Сер итеп кенә әйт әле: хезмәттә вакытта берәр чеченканың кулларын тоткалаганың булдымы?

– Сорау провокационный, әлбәттә. Әмма шуны әйтәм – анда закон кырыс, андый егетләрнең башын кисеп кулына тоттыралар.

Зоя хахылдап көлеп җибәрде, кинәт башына бер уй килеп, Әхәтне өстәлгә таба тартты.

– Әйдә, тагын берне җибәрик әле, шундый итеп чәкешик, стеналар калтыранып куйсын.

Ул үзе чәркәләргә аракы салды, берсен Әхәткә тоттырды да чәркәсен каты итеп егетнекенә китереп бәрде. Чәркәләр каты итеп зеңләп куйды, эчемлекнең яртысы өстәлгә түгелде. Карасалар, Әхәтнең чәркәсе буйга чатнап киткән, тик ярылып ук чыкмаган.

– Тост әйтмичә эчсәң, шулай була ул, – диде Әхәт, кәефе кырылып һәм чәркәсен өстәлгә куйды.

Зояның болай кылануын Камилә эчке чиркану белән күзәтеп тора иде.

Төн килде. Әхәт кунарга Камилә янында калды. Караватт ике кешегә кысанрак иде. Тик бу кысанлыкны алар тоймады. Шулай ярты төн пышылдашып, үбешкәләп, кочаклашып яттылар. Салмыш егетнең дәрте тәмам почмакланган, ул исерек баштан чаманы да онытгкалап җибәрә иде. Аларның ыгы-зыгысын Зоя үзенчә юрап ятты. Әхәт артык кызып китсә, Камилә аны:

– Нишләвең бу, Әхәт, акылыңа кил, – дигән сүзләр белән аны тыелырга мәҗбүр итә иде. – Әнә бит, Зоя барысын да тыңлап ята. Җитте, әйдә йокла...

Әхәт һаман үзенекен итә:

– Мин сине шундый сагындым... Бу очрашуны шундый көттем. Ә сиңа барыбер, – дип үпкә белән пышылдый. Әмма кыз нык тора.

Ә Зоя, чыннан да, йокламыйча, боларның кыбырсынуын, пышылдашканын тыңлап, нәрсә булыр икән дип көтеп ята иде. Теләсә, ул яшьләрне үзләрен

генә дә калдыра алган булыр иде. Әнә күрше бүлмәдә бер карават буш тора, Наилә авылга кайтып китте. Тик Зоя анда кереп йокламады. Яшьләрнең кыбырсынуын тамаша кылып ятарга булды.
Әгәр дә Камилә күршеләргә кереп ятуын үзе үтенеп сораса, ул, бәлки, моңа риза да булган булыр иде. Тик кызый бу хакта сүз кузгатмады, артык горур, андый адымга барамы соң?.. Шуңа күрә Зоя, үч итеп, аларның бал мичкәсенә бер кашык дегет булып төшәр өчен юри бүлмәдә калды. Нигә әле тормышны рәтләп аңлап та җиткермәгән шул япь-яшь нәрсәгә шундый бәхет тә, аңа – Зояга юк. Нигә егетләр Зоядан бик тиз суынала да ташлап китәләр. Ул кемнән ким? Кайсы җире җитешмәгән?

Яшьләрнең күзенә йокы кермәде. Менә Әхәт, торып, карават кырыена утырды, тирән итеп көрсенеп куйды. Тәрәзәдән төшкән ай яктысы, ак тасма кебек, бүлмәне урталай бүлгән. Бу якта – алар, теге якта Зоя ята. Әхәттә үз-үзеннән канәгатьсезлек уянды, хәтта ачуы чыкты. Бүлмәдә ят кеше барында болай кыланырга ярамаганны, Камиләнең дәрәҗәсен төшерүен ул аңлый да үзе, тик эчкән аракы белән егетлек үҗәтлеге үзенекен итә бит, каһәр.

Зояга яшь, чибәр һәм горур Камиләне «кызык итәргә» җай чыгып тора бит әле. Карап карыйк, кызый, нишләрсең икән? Һәм ул тәвәккәлләргә булды:

– Әхәт, азапланма шул бала-чага белән. Барыбер кадереңне белми. Кил яныма, тынычландырыр арган җаныңны...

Бүлмәдә тирән тынлык урнашты, өч җан хәтта сулыш алудан да туктаганнар кебек иде. Әхәт аркасы белән тойды: бу сүзләрдән Камилә катып калды. Ә Зоя, тантана кичергәндәй, мыскыллы елмаеп, Әхәт нишләр икән дип көтеп ята бугай. «Ялгышасың, кызый... Сугыш мәхшәре җанын имгәтә төшсә дә, Әхәт алай ук беткән кеше түгел», – дип уйлап куйды егет. Ул бер карарга килеп, тиз-тиз киенә башлады. Әхәт мондый сүзләрдән соң бүлмәдә кала алмавын аңлый иде.


Ул киенеп бетерде дә бүлмә уртасына, ай нуры төшкән якты урынга килеп басты, кулына сумкасын алды, борылып Камиләгә карады.

Шул вакытниндидер көч Камиләне урыныннан торып басарга мәҗбүр итте. Урындык аркасына салган халатын өстенә ябып та тормыйча, бер сүз әйтмичә, Әхәткә томырылды, хискә бирелеп, аны кочаклап алды:

– Иртәгә кил, Әхәт... Мин концертка билет алып куярмын...

Әхәт моңа каршы бер сүз дә әйтмәде, Камиләне йомшак итеп иреннәреннән үпте дә ишеккә юнәлде.

Күктә, җир йөзендәге шушы тамашаларны күзәткәндәй, тулы ай йөзә иде...



Рәсем: Наталья Васильева

PRESSA.RU



БУ ҖЫР МИНЕМ ХАКТА

Бу җыр мине язмышым буе озатып килә кебек. Аның тексты да бик кызык язылды. Һәркемнең үзалдына көйләп йөри торган җырлары була бит? Җыр үзе юк, аның ниндидер өзекләре, юллары, аһәңнәре бар, шулар сиңа тынгылык бирми йөдәтә...

Мин дә яшь чаклардан ук: «Күңелем җырдан тора...» – дип, борын астыннан гына көйләргә ярата идем. Җырлый белмим, әмма җырлыйм, күңел сорый, шул җырны көйләп алсам, күңел тынычлана, ниндидер матур, ихлас халәткә керә... Бу җыр юлының «Күңелем моңнан тора», «Күңелем уттан тора», «Күңелем нурдан тора» дигән тагын башка вариантлары да бар иде.

Шулай күпмедер еллар узды. Бервакыт минем зиһенгә барып җитте: «Әзер шигырь бит бу, үземнең чын асылымны белдерә торган шигырь, нигә аны шигъри әсәр калыбына салып карамаска?..» Әйттем дә эшләп тә куйдым: иҗат газабында янып, җәфаланып утырасы да булмады; бер утыруда, караламасыз-нисез акка төшердем.

Үземә бик ошады яңа гына дөньяга килгән шигырь. Мин инде кайбер юлларны гына көйләмим, бәлки, шигырьнең үзен бөтен килеш көйләп, җырлап йөрим. Көе гади генә – халыкчан көй, сами-

Күңелем җырдан тора

Хисләрең, һай, кайнар дисең,
Җаным гел уттан тора.
Янып-көеп яшәвемне
Таңдагы чыктан сора.

Минем хәлемне күлләрдән,
Урманнан, кырдан сора.
Йөрәгем – тоташ сөюдән,
Күңелем җырдан тора.

Карашларың яшьле дисең,
Җаным гел судан тора.
Яшенле яңгыр шикелле
Бер явар сыман тора.

Минем хәлемне күлләрдән,
Урманнан, кырдан сора.
Йөрәгем – тоташ сөюдән,
Күңелем җырдан тора.

Күңелең сагышлы дисең,
Җаным гел моңнан тора.
Йөрәгем – тоташ сөюдән,
Күңелем җырдан тора.

ми аһәң. Ләкин кайда да булса бастырып чыгарырга уйламыйм. Бастырыр да идем, шигырьдәге бер юл күңелдә шик уятып тора. Чынлап та, «Күңелем судан тора», – дигән юл шагыйранә юл түгел, күбрәк физиологик аксиома кебек яңгырый (кешенең күпчелек өлеше судан тора дип сөйләргә яратабыз бит). Алып та ташлыйсы килми, чөнки уттан соң су булырга тиеш. Шигырьдәге образлар үсеше таләп итә бу логиканы.

Бервакыт «Ватаным Татарстан» газетасына шигырьләремне соратып алдылар. «Сәхифә тулып җитсен өчен тагын берәр шигырь кирәк», – диделәр. Янымда бер шигырь дә юк. Күңелдә генә теге көйләнеп йөри торган шигырь бар. Шуны күчереп яздым да кертеп бирдем. «Күңелем судан тора» дигән юллар хакында бөтенләй дә онытканмын... Басылып чыкты. Шактый гына вакыт узды. Бервакыт Рифат Фәттахов шалтырата: «Филүскә яңа җыр эзли идек, «Ватаным Татарстан»да басылган шигырең күзгә чалынып калды, алырга ярыймы, безгә ул туры килә», – ди.

«Алыгыз», – диюдән башка чара калмады. Зур сәхнәгә аяк басып кына килүче якташым Филүс Каһировның (мин Дүртөйледән, ул Бүздәктән, күршеләр без – *Г. Г.*) иҗатына сөенеп йөргән вакыт иде, мин бу телефон шалтыравын үземә зур бүләк, матур бер язмыш ишарәсе кебек кабул иттем. Әкияткә тиң серле вакыйгалар дәвам итте. Шул ук көннәрдә Фәрит абый Хатипов шалтыратты. Бик дулкынланган. «Бу кадәр җырга ятышып тора торган текстны күргәнем юк иде әле, бер укуда күңелемдә җыр туды, – ди. – Җырда син үзеңне язгансың, мин сине беләм бит», – дип тә әйтә. Аннары тыйнак кына өстәп куя: «Бу җырда мин дә бар хәзер...»

Икенче шалтыратуында ул инде миңа телефон аша көйне тыңлатып карады. Шул мәлдә тормышымда ниндидер бер мөһим вакыйга, тарих башланганын тойдым... Бәхеткә тарыдым...

Җыр баштан ук Филүс Каһиров өчен язылды. Мин дә, текстны алырга рөхсәт биргәндә, Филүс өчен булса – риза, дип кистереп әйттем. Фәрит абый да Филүс аһәңенә туры китереп язган. Бу җырга мин дә, композитор да, продюсер да зур өметләр багладык. Мин аның Филүс башкаруындагы яңгырашын түземсезлек белән көттем. Ишеткәч – шаккаттым. Ул мизгелне хәзер аңлатып та, кабат кичереп тә бирә алмыйм. Яңа туган кебек булдым. Ниндидер моңлы мәкамдәге дога ишеткән кебек, күңелем тетрәнеп тыңлады җырны...

Җыр дөньяга чыккач, үз тормышы белән яши башлагач, шуны аңладым – күп кешеләр кичергән икән мин беренче тыңлагандагы кебек халәтне. Күпләр күз яшьләрен тыя алмыйча сыктап утырган... Еш кына шулай була: радиодан яисә телевидениедән әлеге җыр яңгыраса, өйдә телефон шалтырый башлый – дуслар, туганнар, гел белмәгән кешеләр күңел ярсуларын минем белән уртаклашырга ашыгалар. Ә кайчакта телефонга барып тотынсам: «Тыңладым... Еладым... Рәхмәт», – диләр дә трубканы куялар. Кем икәннәрен дә белми калам...

Иң мөһиме: Филүс үзе яратты бу җырны. Минемчә, ул шушы җырда ачылды да. Концерт программаларын «Күңелем җырдан тора» дип атады, альбомнарын да шушы исем белән чыгарды... Шушындый моңлы җырлар аша ул үзенә нинди җыр, нинди аһәң кирәген аңлады, үзенең җырчы язмышын, сәхнә язмышын билгеләде дип уйлыйм.

Тагын шунысы кызык: Филүс башкаруында бу җыр үзенең серле-сихерле тормышын дәвам итте. Очраклы хәл генәме, әллә җырның, музыканың, сәхнәнең чынлап та шаукымлы энергетикасы бармы, Филүс бу җырны җырлый башлауга, аппаратура эшләүдән туктаган, утлар сүнгән, хәтта клуб үзе яки аның янындагы берәр йорт дөрләп яна башлаган чаклар булган. Бу хакта Филүснең үзенең сөйләгәне булды. Концерт башлангач та, әлеге җырны җырларгамы-юкмы, тагын берәр хәл чыкмасмы, дигән чаклары да булган аның. Җырламаса, халык сорап җырлата икән.

Мин үзем бу җырның көчле энергетикага ия булуын беләм. Тоям. Бик кыен чакларда мин аны тыңлап көч алам, гадәттән тыш шатлыклы, дәртле чакларымда аны тыңлап тынычланам. Бу җырда өч башлангыч – шигырь, көй һәм башкару сәнгатьләре тулысынча – илаһи кимәлдә туры килгән. Бу җырны мин, үземнең «Албастылар» романы, «Татар мифлары» белән бергә, иҗатымның иң югары үре, бренды дип саныйм.

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ

PRESSA.RU



ОЧУЧЫ ӘТИСЕННӘН УЛЫ СОРЫЙ ИКӘН: «ӘТИ, ОЧУЧЫЛАРНЫ БИК ТӘ САБЫР, БЕРНИНДИ ОЧРАКТА ДА КЫЗЫП КИТМИ, ДИЛӘР. ДӨРЕСМЕ?» – «ДӨРЕС». – «АЛАЙ БУЛГАЧ, ХӘЗЕР КӨНДӘЛЕГЕМНЕ АЛЫП КИЛӘМ».

Лилия ГӘРӘЕВА

АНДА, БОЛЫТЛАР АРТЫНДА...









Ул көн бик авыр булды Энҗе өчен. Әлки районының әллә кайдагы бер авылына йогышлы чир чыганагын ачыкларга җибәргәннәр иде аны. Эшемне тиз генә бетерермен дә, тиз генә әйләнеп кайтырмын дигән иде. «Проба гына алам», дип киткән сан-эпидемстанция фельдшеры күзләр дә карады ул көнне, колаклар да... Көне буе эссе кояш астында, тузанлы юлларда дыркылдау «килешкән», кичкә бөтен тәне калтырап, башы чатнарга тотынды. Ә фатирда бергә яшәгән Нинага клубка чыгарга иптәш кирәк. Кыстапмы-кыстый. Синең чирләвеңдә эше юк. Өстенә пальто, аягына калын оекларын киеп, Нина артыннан иярде Энҗе.

Ярый әле клубка чыккан ул. Өйдә калган булса, Әмир белән ничек очрашырлар иде? Никах күкләрдә укыла дисәләр дә, аңа кадәр насыйбыңны табасы бар бит әле. Яшьләр вальс әйләнгәндә борынын пальто якасына яшереп, бөрешеп утырган кызны Әмир оясыннан егылып төшкән сандугач баласына охшаткандыр. Учларыма алып җылытыйм әле, дигәндер. Әмма Энҗенең үз хәле хәл, егет күзләрендә кабынырга әзер сөю чаткыларын күрмәде ул. 30 градус эсседә пальто киеп биеп йөрмәс бит инде?! Ә, юк, егет күзендәге теге очкыннар кабынып, уты инде йөрәккә төшкән дә икән. Бу сандугач баласын үзеннән бер дә калдырмас ул бүтән. Ул аны үзе белән ерак-еракларга алып китәр, ә аңынчы... Ә аңынчы чәчәкле-ширбәтле төп-төгәл бер ай вакытлары бар әле. «Чык миңа кияүгә, – ди Әмир. – Ерак-ерак җирләргә бергә очыйк». Бик чыгар иде Энҗе, әнисе авырып ята... Бу юлы Ерак Көнчыгышка егетнең үзенә генә китәргә туры килер, ахрысы. Әмма җаны ялгыз түгел, йөрәгендә сөйгән кызының вәгъдәсе бар. Озакламас, ярты елдан кайтыр ул, менә шунда инде гөрләтеп туй итәрләр.

Никадәр генә озак тоелмасын, көткән көн барыбер җитә ул. «Бие, сиңа сөенче, киявең кайта!» – почтальон кызның кулыннан аласы шушы өч сүзле телеграмманы ни зарыгып көтте бит инде Энҗе: «25 е кайтам, каршыла!» Бирергәме, бирмәскәме, дигән сыман икеләнеп торганнан соң, әле генә сөенечтән тыпырдаттырган почтальон аңа тагын бер «кош теле» суза: «Хәзер үк кайт, әниең үлем хәлендә». Бәлки әтисе юри генә язгандыр? Ул бит кызының хәрби егеткә кияүгә чыгуына теше-тырнагы белән каршы иде. Бер ишектән керде, икенчесеннән чыкты Энҗе. Әмирнең кайтканын көтеп кенә алды да әнисе янына – Аксубай районына, Яңа Ибрайга «очты». Болай да исәпле ялның ике атнасы аңсыз яткан әнисе янында узды. Утлар йотты инде Әмир, бу юлы да кавыша алмаслар микәнни? «Үлем кичектерелә, никах – юк», диләр бит. Зурдан кубып туйлар итмәсәләр дә, йоласына туры китереп, матур гына бәйрәм ясадылар.

Әмиргә ияреп, Җир шарының читенә китеп бара Энҗе. Газиз әнкәсен башка мәңге күрә алмаячагын белми әле ул. Алда үзен нинди кыенлыклар көткәнен дә белми. Мең мәшәкатьле, мең борчулы булса да, яратып яшәгәч, авырлыкларны күңелле хатирә итеп кенә искә алачак ул. Ә әлегә яшь кәләшен Уссурийск гарнизонының буп-буш бүлмәсенә алып кайта Әмир. Буш булмас иде, бер фатирда яшәгән егетләрнең һәркайсы ялга кайткан җирдән өйләнеп килгәннәр дә, уртак җиһаздан үз өлешләрен алып чыгып киткәннәр. Әмирләргә бер шифоньер белән бер тумбочка утырып калган. Буш бүлмә белән генә түгел, өч табут белән дә каршылый Ерак Көнчыгыш аларны. Бу табутта Әмирнең бергә очкан иптәшләре – күккә соңгы кат күтәрелгән хәрби экипаж... Җирдә йөргәндә дә әҗәл үкчәңә бастырып килә, ә күктә ул тагын да якынрак. Моның шулай икәнен гарнизонга аяк баскан көнне үк аңлый яшь ханым.

Авария

– Бер дә онытмыйм, – дип искә ала Энҗе апа күңеленә гомерлек шом булып кереп калган ул вакыйганы. – Апрель ае иде. Әмир төнлә очасы. Ул чыгып китүгә яңгыр сибәли башлады. «Бүген очмаслар, озакламый кайтыр», – дип, керогазга бер чиләк су утырттым. Улыбыз Марат бәби генә иде әле, аны юындыру өчен суны шулай керогазда җылытам. Маратны йоклатам дип, үзем дә йокыга киткәнмен. Бала елаган тавышка уянып, аны күкрәгемә салдым да, кулымны артка шудырып, Әмирне барлыйсы иттем. Ә анда – коточкыч бушлык һәм җан өшеткеч салкынлык. Беләсезме, ул урыннан шулкадәр салкын бөркелә иде, мин аны искә алсам, әле дә өшеп куям. Йөрәгем жу итте. Димәк, нәрсәдер булган, югыйсә Әмир инде әллә кайчан өйдә булыр иде. Баланың имеп туйганын көчкә көтеп җиткезеп, коридорга чыктым. Күршедәге фатирда Әмир белән бергә оча торган Женя Григорьев яши, шуларның кыңгыравына бастым. Ишекне Женяның хатыны Нина ачты. Мине күргәч, сискәнеп китте. «Женя кайттымы?» – дим. «Юу-ук», – ди Нина һәм, шашынып, чәченә ябышты: «Ой-й, разбился, это мой Женька разбился!» – «Туктале син, Женя икәнен каян беләсең?» Бүген ул өр-яңадан киенеп киткән булган. Ә русларда яңадан киенеп китү начар фал санала икән.

Ул чорда хәрбиләрнең абруе югары иде. Хәрби тормыштан романтика эзләп ялгышучылар да булды.

Ниналарның йокы бүлмәсеннән аэродром күренә. Икәүләп, тәрәзәгә капланабыз. Инде таң беленә. Нидер булган инде, анысы бәхәссез, ләкин ни икәнен генә белмибез. Ниһаять, иртәнге дүрт тулганда еракта ике ут шәйләнде – машина фаралары. Мин тиз генә үзебезгә чыктым. Очыш яхшы үтеп, кәефе шәп чакларда Әмир сызгырып кайта торган иде. Бу юлы сызгыручы юк. Подъездда аяк тавышлары. Мин тын алырга да куркып тыңлыйм, менә алар менеп җитәрләр дә, безгә туктalып та тормыйча үтеп китәрләр кебек... Юк, тукталды... Әмирнең ишек ачканын ишетеп, каршысына атлыйм. Борчылганымны белдермәскә кирәк. Тавышыма – илтифатсызлык, йөземә битарафлык чыгарып, имеш, йөрисең инде кешенең йокысын калдырып, нигә соңга калуларын сорыйм. Андый чакта Әмирнең холкы кызу: «Күрәсең бит, исән!» Бүген ул берни дә аңлатмаячак. Аларның нинди бәлагә очраганнарын мин иртән генә беләчәкмен. Яңгыр ява башлаганда Әмир һәм тагын өч экипаж һавада кала. Самолетларны юеш асфальтка утыртырга туры килә. Звено командирлары Гаврилин оста гына төшеп утыра, ә болар бит әле яшь, тәҗрибәсез. Гаврилин артыннан төшкән самолетны туктата алмыйлар – кырга чыгып китә. Аның артыннан ук төшеп кунган Әмир самолеты да тиешле сызыкта туктамый, туп-туры тегесенең өстенә бара. Ике само-

PRESSA.RU

летта да 20 шәр тонна керосин. Канатлары белән генә бәрелешсәләр дә, дөртләп кабыначак. Тегесенә ярты метр кала, Әмир самолетны туктата. Өченчесенә инде һавада чакта ук кычкыралар: «Тормози! Тормози!» Зыян килгән очкычлар өчен летчиклардан түләтергә кушыла. Дөрес, соңыннан аларның тәҗрибәсезлеген искә алып, бу карарны юкка чыгаралар чыгаруын.

Батырлык

...Энҗе апа алдыма калын гына папка китереп сала. Әмир абый турында истәлекләр сакланган бу папканың бите саен бер хатирә... Еллар сарысы сеңгән газета битләреннән беренче класслы хәрби очучы, капитан Әмир Хәсән улы Галиев елмая. Кулыма «Советский патриот» газетасының 1981 нче елгы санын алам. Таныш исемне эзлим. Менә ул: «Самолет, нащупав фарами полосу, мягко приземлился. Галеев сядет в любых условиях...»

Ирем хәрби очучы диюгә, үземә игътибар артуын сизә идем.

– Әмир татарларны бик ярата, частьларына килеп эләккән татар егетләре булса, үз канаты астына алырга тырыша иде, – дип, шушы мәкаләгә кагылышлы тагын бер истәлеген барлый Энҗе апа. – Кәрим исемле бер егет бар иде. Әмир аны үзенең экипажына алды. Улым белән әтиебезне эштән каршыларга чыккач, күрәм, безгә таба кызу-кызу атлап шушы егет килә: «Әмир Хәсәнович бик шаян кеше икән, – ди бу. – Шторaларны ябып, самолетны «күз йомып» утырта». (Берни дә күрмичә, фәкать приборларга гына карап утыртуны шулай атыйлар.) Менә Әмиргә эләкте ул көнне. «Мине тол, улыбызны ятим итмәкче буласыңмы? Мин иртәгә үк Татарстанга кайтып китәм!» Башкача алай эшләмәскә вәгъдә биргән иде ул шул чакта. Ә менә тормышта аның бу күнегүе кирәк булып чыкты. Төнге очыштан кайтышлый, беркөн аэродромда ут бетә. Запас аэродромга барып җитәргә ягулыгы җитмәсен аңлаган Әмир диспетчердан фаралар ярдәмендә генә төшеп утырырга рөхсәт сорый һәм, 20 миллионлык очкычка да, экипажга да зыян салмый-нитми генә, уңышлы төшеп утыра. Аның бу гамәлен батырлык дип бәяләп, бу мәкалә әнә шул очрактан соң басылган иде.

Төш

– Ачуым килеп, кайтып китәм, дисәм дә, чынлыкта минем кайтып сыеныр урыным юк иде. Ул вакытта әни үлгән, әти башкага өйләнгән. Мин хәтта әниемнең үлгәнен дә вакытында белмәдем. Бер дә онытмыйм әле, 24 февраль көнне төш күрәм. Имеш, хат алганмын. Анда әти кулы белән (сулагай иде ул һәм аның язуы үзгә иде): «Энҗе, кызым, син елама инде, әниеңне кайтарып булмый, ул 24 февральдә 12 туларга 10 минут кала җан бирде», – диелгән. Күңелемә шом керде. Күрше Люба шулай да төшемне яхшыга юраган булды, имеш, үлгән дип күрсәң, гомере озын була. Бераз тынычландым. Әмма... 8 Март көнне Фәридә апамнан хат алам. Конверт тышына безнең адресны гади карандаш белән генә язып куйганнар, ул инде сөртелеп бетә язган. Ерак Көнчыгышка кадәр ничек килеп җиткән ул! Өйдә ручка бетте микәнни дип, көлдем дә әле. Ачсам... нәкъ мин төштә күргән теге хат: сүзе – сүзгә, өтере өтергә туры килә. Без ул көнне дуслар белән 8 Мартны бәйрәм итәсе идек. Бәйрәмне бозмыйк, дип, без бу хакта беркемгә дә әйтми торырга булдык. Анда барасы гына булмаган, мин моның өчен әле дә үземне гафу итә алмыйм, ә без бардык. Гел әниләр турында гына сөйлиләр, җырлыйлар: күңелем түзмәде, өстәлгә капландым да үкси-үкси еладым. Бозмыйк дигән бәйрәмнең барыбер яме китте.

Әнинең үлеменнән соң ак әйбергә карый алмый башладым, өйдә дә берүзем калырга куркам, ә Әмирне гел командировкаларга җибәрәләр. Уйладык та, беразга туганнарым янына кайтырга булдым. Самолетта 13 сәгать очып, алты айлык бала белән Казанга кайтып төштем. Аэропортта энем белән сеңлем каршы алырга тиешләр иде. Басып торалар болар, мине танып, булышырга килмиләр. Югыйсә анда минем кебек балалы хатыннар да күп түгел. Бала күтәреп, сумкаларны сөйрәп, үзем яннарына килеп баскач кына абайладылар. Җирән бөдрә чәчле апалары урынына кара туры чәчле, ябык кына бер хатын кайткач, танымаулары да гаҗәп түгел. Баланы бик авыр таптым мин, бөерләремә авырлык килеп, 35 көн хастаханәдә яттым. Яныма да килүче юк, Әмирне, моның хатыны барыбер өйдә түгел, дип, гел дежурствога куялар. Шул вакытта организмда аксым үзгәреп, чәчләремнең төсе дә, рәвеше дә алмашынды.

Германия

– Табиблар миңа башка бала табарга ярамый, диде. Шулай да Маратка иптәш алып кайтасы килә бит, тәвәккәлләдем. Авырлы икәнемне белсәләр, төшертергә мәҗбүр итәрләр дип, беркемгә дә сиздермәдем. Кызыбыз Лилия Казанда туды. Хәзер инде аның үзенең дә дүрт кызы үсеп килә.

Улыбыз беренче класска да шушында яшәгәндә китте. Үзем эшләрлек эш тапмасам да, монда яшәгән вакытны бушка уздырмаска тырыштым. Беренчедән, тел өйрәндем. Әнием дә немец теле укытучысы иде, тел үзләштерергә сәләтем булган, димәк. Икенчедән, немец хатын-кызларыннан кул эшләренә өйрәндем.

Германиядә Әмирнең бергә очкан иптәшен югалттык. Бик үкенечле булды ул. Хатыны баласы белән туган ягына кайтып киткән иде. «Иртәгә каршы ал», – дип телеграмма да суккан булган. Күрешүне зарыгып көткән кешенең мәет өстенә кайтып төшүен күз алдына китерә аласызмы?

Әмир үзе дә чактан гына әсир төшми кала. Ул бу вакыйга турында беркайчан беркемгә сөйләмәде. Гомумән, эше турында аз сөйли иде ул. Бер көнне әйтә бу: «Мине бит Голландиягә алып чыгып китә яздылар

бүген, – ди. – Чик буйлап очам шулай, кинәт әллә кайдан бер самолет килеп чыгып, минем белән тигезләште. Ул арада икенче яктан икенче самолет. Өчәү рәттән очабыз. Мин аска – болар да аска, мин өскә – болар да өскә. Акрынлап курстан читләштерә, Голландиягә таба кысрыклыйлар. Самолетны кинәт кенә аска томырдым да, текә борылыш ясап, уңга каердым. Тегеләр миннән мондый хәтәр алым көтмәгән иделәр, ахрысы, ничек килеп чыккан булсалар, шулай югалдылар». Әмир сөйли, ә минем йөрәгемдә ут. Ярсуымны фәкать суга гына сөйлим. Хәрби очучы белән яшәүнең бер үзенчәлеге бар – аны безгә, өйләнешеп, гарнизонга аяк баскан көнне үк аңлаттылар: гаиләдә бернинди дә ызгыш-гауга булырга тиеш түгел. Очучы эше болай да авыр, киеренке. Үпкәләремне мин Әмир ялга чыккач кына белдерә идем. Өч тапкыр Советлар Союзы Герое, авиация маршалы Иван Кожедуб әйтә торган иде: «Очучылар – алар аерым халык. Аларга башкача мөгамәлә кирәк».

Бар да вакытлыча

– Мине белгәннәр безнең тормыштан үлеп көнләшәләр иде. Имеш, мин очучы хатыны, рәхәттә, җитеш тормышта яшим. Беркөн дә фатирсыз тилмергәнем юк. Әмма... Хәрби тормышның иң үзәккә үткән ягы – бөтен нәрсәнең вакытлыча булуы. Бүген эшләгән эшең, торган фатирың, баланың классташлары, аралашкан дуслар – бар да вакытлыча. Бер айлыкмы алар, биш еллыкмы – белмисең. Без гомер буе үз фатирыбыз турында хыялландык. «Пенсиягә чыккач, туган якка кайтып фатир алырбыз, матур итеп ремонт ясарбыз», – ди иде Әмир. Дөрес, үзе рәхәтен күрә алмаса да, булды фатирыбыз. Ә аңынчы 12 тапкыр күченергә туры килде. Әйберләрне җыярга, пропискадан төшәргә, эштән расчет алырга өч көн вакыт бирелә. Әмирнең болар артыннан йөрергә вакыты юк. Ике чемоданга үзенең «бирнәсен» төйи дә, ул әзер. Яңа урынга урнашып, өч көннән ул инде эшкә чыгарга тиеш. Ә мин эшкә расчет алырга чабам. Хезмәт кенәгәмдә гел бертөсле генә язулар: «увольняется по переводу мужа-военнослужащего». Шунысы ярый тагын: яңа гарнизонда үз белгечлегем буенча эш булмаса да, стаж өзелми. Аннары бакчадан, поликлиникадан баланың документларын алырга йөгерәм. Пропискадан төшәм, әйберләрне җыям. Бөтен булган мөлкәтеңне йөк машинасына төяп, гарнизонга килеп төшәсең. Йә суыткычыбызга зыян килгән була. Яңасын сатып алыйм дисәң, юк бит әле ул. Йә паласыбыз ертылган... Юкка гына халыкта ике күченү бер янгынга тиң, димиләр бит. Шунысы әйбәт: очучы составка фатирны шунда ук бирәләр. «Галиев фәлән йортта яшәячәк», – дип, килүгә үк озатып куялар. Нинди генә фатирларда яшәргә туры килмәде безгә. Аларга бит җаның теләгәнчә ремонт та ясап булмый – бәлки, бер айдан ук башкасына күчерерләр. Ераграк гарнизонга җибәрсәләр, әйберләрне контейнер белән озатабыз. Ул килеп җиткәнче кунакханәгә урнашмый хәл юк. Ашарга да ашханәгә, йә ресторанга йөреп торасың. Балалар кеше пешергәнне яратмый иде. Аларча булсын, дип, бер кәстрүл сатып алам да, башта ашарга пешерәм, аннары, аны юып, чәй кайнатам.

Йокысыз төннәр

– Җанны талый, төн йокыларын ала торган вакытлар күп булды тормышыбызда. Очучылар елга өч тапкыр парашюттан сикерергә тиеш. Аңа парадка әзерләнгән кебек әзерләнәләр. Язгы-җәйге айларда, чалт аяз матур көнне була ул. Әмир артыннан үзәкләрем өзелеп карап калам: үз аяклары белән чыгып китте, үз аяклары белән кайтып та керсә ярар иде. Борчылуым урынсыз түгел: парашютны 18 яшен яңа тутырган яшь солдатлар тутыра бит. Алар әле бөтенләй бала-чага. Дөрес тутырганмы ул аны, әллә анда бөтенләй дә парашют тыгылмаганмы. Иртәгә сикерәбез дигән көнне Әмир үзе дә йокламый. Аның борчылуы миңа күчә. Әнә шулар какшатты да инде аның сәламәтлеген.

Ул китә, ә мин, аны соңгы кат күргәндәй, тилмереп карап калам...

Пенсиягә чыккач, Чаллыга күченеп кайттык. Үз фатирыбыз булса иде дип, күпме хыялланса да, үз фатирыбызда яшәү насыйп булмады аңа. Бергә 35 ел яшәп калдык. Инсульт булганын вакытында белмәгәнбез. Үзе дә белдертмәде. Очучы бит – нык һәм түзем булырга өйрәнгән. Җиде ел авырды ул. Аннары инде...

Яңа фатирда кабат җыярга язсын дип, икәү бергә сүткән җиһазларны менә быел, аның вафатыннан соң тугыз ел узгач кына кузгаттым. Тугыз ел буе көттем мин аны, командировкага гына киткәндер, менә подъездда аяк тавышлары ишетелер дә, сызгыра-сызгыра кайтып керер кебек тоелды... Аның мәңге кайтмаячагына күңелем тугыз елдан соң гына ышанды.

Үкенечләр... Алар бик күп. Күңелне юата торган шатлыклары да бар. Яшьлегемдә югары белем алырга хыялландым. Балалар кечкенә, үзебез гарнизоннар буйлап күчеп йөргәндә, бу мөмкин түгел иде. Соң булса да, хыялымны тормышка ашырдым, дүрт диплом алдым. Аның икесе Мөхәммәдия мәдрәсәсе белән Ислам университетыныкы. Һәм иң куанычлысы: моны Әмир белеп, минем белән бергә шатланып калды. Минем белән бик горурлана иде ул. Миңа яңа күлмәк алса, аңа балаларча шатлана, гел матурдан киенеп йөрүемне тели иде. Без матур пар булдык. Ул кызу кеше иде, мин аның бу кызулыгын вакытында сүндереп кала белдемме – матур яшәдек. Әмирнең истәлекләре арасында минем өчен аеруча кадерле булган берсе бар – мин хастаханәдә ятканда язган хаты ул. Юк, хат кына түгел, бу аның гомер буе күңелендә йөрткән үкенүләре, хисләре, мәхәббәтен аңлатуы.

Мин беләм, ахирәттә дә бергә булырбыз. Ә аңа кадәр әле бабалары турындагы хатирәләремне оныкларыбызга җиткерәсем бар.

PRESSA.RU



ФОТОГА ТӨШЕРҮ БЕЛӘН КАЙЧАН МАВЫГА БАШЛАДЫМ СОҢ ӘЛЕ МИН? БУ СОРАУГА ТӨГӘЛ ГЕНӘ ҖАВАП БИРӘ АЛМАМ, МӨГАЕН.



Асия МАЛИКОВА

ТАБИГАТЬ – ҮЗЕ БЕР МОГҖИЗА...

Хәзер фотога төшерү белән мавыкмаган кеше юк та бугай. Мин дә, кая барсам да, истәлек өчен дип, бер-ике кадр төшереп кайта идем. Ә менә ирем Әнвәрнең бу шөгыле балачактан килә. Аның әллә кайчан сатып алган фотоаппараты хәзер дә саклана. Журналист булгач, иремә кызыклы сюжетлар кирәк, ул төрле вакыйгаларны төшерергә ярата, ә мине күбрәк табигать күренешләре кызыксындыра.

Фотога төшерү алымнары, кадр кую, композиция буенча беренче сабакларны миңа ирем бирде. Шунысы уңайлы хәзер: фотоларны халыкка күрсәтү өчен аудитория эзләп йөрисе юк. Телисең икән, һәр адымыңны төшереп, социаль челтәрләр аша күрсәтеп бара аласың. Ләкин мин кирәген-кирәкмәгәнен дә интернет киңлекләренә чыгару ягында түгел. Шуңа күрә социаль челтәргә дә әле яңа гына кереп барышым.

Моннан ике ел элек мин, тиешле елларны эшләп, лаеклы ялга чыктым. Картайган көнендә шәһәргә күчмәячәген әллә кайчан кистереп әйтеп куйган әниемне авылда ялгыз калдырып булмый иде. Карт кеше-

нең бу теләген ирем дә, улым да кире какмады. Рәхмәт аларга.

Күп тә үтмәде, гаиләмне, дусишләремне, планнарымны калдырып, мин авылга кайттым. Шулай итеп, үз көенә барган тормышым кинәт үзгәрде, хәтта бераз төссезләнеп тә калды кебек. Бәхеткә, шулай ук әнисен карарга дип, дус кызым Илшат та кайтып төште. Аның белән бер-беребезгә иптәш булып, ярдәмләшеп яшибез хәзер.

Шимбә-ял көннәрендә ирем белән улым кайткач, дөньям түгәрәкләнеп китә. Ә баштарак күңел тынычлана алмый азапланды, Казан гел истән чыкмады. Шулай икеләнеп яшәвемне күреп торган ирем, сиңа дусларың белән аралашырга, иҗат белән шөгыльләнергә кирәк дип, мине социаль челтәргә керергә кыстый башлады. Күпмедер уйланып йөргәннән соң, үзем дә тәвәккәлләдем. Электәге дусларымны табып, алар белән аралаша башладым.

Беренче тапкыр фотоларымны узган елның октябрь ахырында интернетка куярга батырчылык иткәнмен икән. Ул көнне кояш аеруча матур баеды. Кыска гына вакыт эчендә болытлар каплаган күк йөзе янгын чыкканда гына була торган шомлы куе төсләргә керде. Бу кабатланмас мизгелләрне фотога төшерми һич булдыра алмадым. Аннан фотосурәтләремне иремә күрсәтәсем килде. Ул, ике дә уйлап тормыйча, Фейсбукка куярга киңәш итте. Хәзер шул фотоларга карыйм да, көлеп куям. Ашыкканмындыр инде: шундый гаҗәеп күренешне газ торбалары, телеграф чыбыклары белән бергә төшергәнмен бит. Фотога төшерүнең чын иҗат икәнен яңа аңлый гына башладым әле. Моның өчен янында фотоаппарат булу гына җитми, дөньяга күңел күзе белән карарга кирәк икән.

Узган елның 11 ноябрен исегезгә төшерегез әле. Шәһәр-авылларда кайсы егылып, кайсы бәрелеп шактый кеше зыян күргән көн ул. «Начар эшлисез, чара күрмисез» дип, шәһәр-район җитәкчеләренең дә, коммуналь-хуҗалык хезмәткәрләренең дә «кирәген биргәннәрен», матбугат битләреннән укып, соңрак кына белдем. Ә иртән... Иртән торып урамга чыксам, аяк астына боздан келәм җәйгәннәр диярсең! Гадәттә, мондый шугалак-бизәкләр яңа ел алдыннан махсус ясала. Ә монда табигать үзе могҗиза тудырган. Агач-яфраклар, ботаклар күз явын алырлык! Әйтерсең лә без йоклаганда, тылсымчы килеп, бар җиһанны бәллүргә төреп киткән. «Менә бу могҗиза, ичмасам!» – дип, хәйран калып шактый басып торганнан соң, фотоаппаратымны алып чыктым.

Фотоларымны дусларым бик җылы кабул итте. Танышларымның берсе рәсемнәрдәге күренешләр бер урында гына төшерелмәгән дип уйлаган икән, ялгышканын аңлагач ул миңа: «Асенька, а где такая красота?! У меня появилось ощущение что ты путешествуешь и радуешь нас фотографиями. Мне кажется нереальным, чтобы такая разнообразная красота встречалась в одном месте. Или ты волшебница!» – дип язды. Әллә аларның мактау сүзләре шулай үсендереп җибәрде үземне, әллә чыннан да күңел күзем ачылды, йокыдан айнып киткәндәй булдым. Ничә ел бакчабызда үсеп утырган агачларны, беренче тапкыр күргәндәй, кызыксынып күзәтә башладым. Дусларымны яңа фотолар белән шатландырыйм әле дип, түбәгә дә менеп төштем. Аннан безнең тирә-як менә ничек күренә янәсе!

Ирем, минем җүләрлегемне күреп: «Давай без фанатизма!» – дип, җиңелчә генә итәктән дә тартып куйды. (Беләм инде, болай гына әйтә ул. Әзер эшләремне күргәч: «Бу матурлык чыннан да безнең янда идемени?» – дип шаккатачак.) Түбәдән төшергән ул фотоларымның әлегә камиллектән күпкә ерак булганын бик яхшы белсәм дә, мин үземнән канәгать идем. Күккә менеп төштеммени, бик кызык булып китте.

Шул көннән башлап, кош-корт, бөҗәкләр, йорт хайваннары минем якын дусларыма әйләнде. Безнең белән параллель яшәп ятучы җан ияләренең дә тормышы кызык икән бит! Без аңа игътибар гына бирмибез икән. Хәзер, җай чыккан саен, көртләр ерып булса да, су буйларын урап кайтам, кошларның, җәнлекләрнең үз-үзләрен тотышларын өйрәнәм. Чаңгыда йөргәндә тирәюньне фотога төшерәм. Табигать кочагына чыксам, дөньямны онытып йөрим.

Әле күптән түгел чаңгыда йөргәндә, алардан артта калып, борчуга салганмын. Бик уңайсыз булып китте. Фотоаппарат белән чынлап дуслашсаң, шулай була икән. Ул, көнче дус кебек, бар игътибарыңны үзенә генә юнәлдерүне таләп итә. Шулай булса да, аның ярдәмендә туган авылымның матурлыгын күрергә һәм башкаларга күрсәтергә өйрәнәм, табигатьтән көч алам, ул миңа хәтта борчуларымны таратырга, авыр кичерешләремнән арынырга булыша кебек.

...Карны кар дип белгән син акыллы, ак чәчәкләр күрәм мин җүләр...

Кайбер дусларым да, үзем шикелле, хисле кешеләр. Алар минем фотоларымны даими карап баралар. Әле берничә көн элек кенә берсе шалтыратып: «Сиңа ни булды, Фейсбукта фотоларыңны куймый башладың?» – ди. Мин, кешеләрне ялыктырмыйм, дип, бераз туктап торырга уйлаган идем. Дустым шелтә белдергәч, фотоларымны куярга туры килде. «Шул матурлыкны күргәч, күңелләр рәхәтләнеп китә», – ди бит. Шулай дип торгач, ничек каршы киләсең инде, файдасы гына тисен үзенә!

Табигать – тоташ могҗиза, анда бар нәрсә дә камил. Шуңа күрә күңел һәрчак табигать кочагына тартыла да инде. Карагыз әле тирә-юньгә: матур бит дөнья! Тормышның кадерен белеп, матурлыкка сокланып, булганына шөкер итеп яшәргә генә кирәк.

Кайнанам – шагыйрә Саҗидә Сөләйманова әйтмешли: «Яшәү – үзе зур бәхет бит ул».

PRESSA.RU



Фото: Ксения Богданова

ЯЛГЫЗ МИН, БЕРҮЗЕМ...



Люция ФАРШАТОВА

ЯШЕРМИМ, УЛ КӨННЕ МИН ЭЧЕМНӘН ГЕНӘ НИНДИ КАТЫ БӘГЫРЬЛЕЛӘР, ДИП, МӘРВИЯ КАРЧЫКНЫҢ ТУГАННАРЫН СҮГЕП ЙӨРДЕМ. НИНДИ БУЛСА ДА, ТУГАН БИТ УЛ, ЯНӘСЕ.

Уйлана торгач, аларны акларга тырышып, «ачы» теле, кыланышлары белән апалары аларның да йөрәгенә мәңге кичермәслек яра ясагандыр, күрәсең, дигән фикергә килдем. Ни чәчсәң – шуны урырсың, дип юкка гына әйтмиләр шул...

– Синең балаларың бармы? Бардыр, бик бәхетле күренәсең.

Янымa килеп утырган әбигә гаҗәпләнеп карадым да имәнеп киттем:

– Марина Сергеевна, Сез түгелме соң бу?

– Нәрсә, танымаслык булып үзгәргәнменмени?

Йа Хода, кайчандыр бөтен деканатны дер селкетеп торган Марина Сергеевна лабаса бу! Аның «ачы теле»ннән, тәкәбберлегеннән институтның уку-укыту бүлегенә кереп йөрүче бар кеше, хәтта профессорлар да шүрли иде бугай. Без, ул әйтмешли, «бала-чагалар»ны әйткән дә юк инде.

Мине 1980 нче елларның башына алып киткән уйларымнан аның әле дә шактый ук таләпчән тавышы бүлде:

– Мин моннан (без аның белән Казанның Бауман урамындагы «Чәй йорты»нда очраштык – *Л. Ф.*) ерак тормыйм, әйдә әле миңа, рәхәтләнеп сөйләшеп утырырбыз.

– Юк-юк, вакытым тар, башка вакыт, – диярго ашыктым мин.

Дөресен әйткәндә, аның белән бер дә аралашасым килми иде. Беренчедән, чынлап та вакытым юк. Икенчедән, теге еллардагы кыланышлары, һәркемгә

диярлек, бигрәк тә тумышлары белән авылдан булган фән кандидатлары һәм докторларына «авыл гыйбадлары» дип кимсетеп караву, шуны һәр сүзе, күз карашы белән искәртеп торуы кылт итеп искә төште дә тизрәк аның яныннан китәсем килә башлады.

– Ашыкма әле, Алла хакы өчен ташлап китмә мине, сөйләш. Ялгыз мин, аңлыйсыңмы, япа-ялгызым, бөтен Казанында берүзем. Бер аралашыр кешем дә юк.

– Ничек ялгыз? Ә Виктор Иванович? Кызларыгыз?

– Виктор Иванович күптән вафат инде. Кызларның берсе – Америкада, икенчесе Испаниядә яши – ташладылар аналарын.

Аның күз төпләрендә тагын яшь бөртекләре елтырый башлады. Аннары, урысчалатып, дөньяны, сәясәтне, ил җитәкчеләрен, депутатларны, кызларын сүгәргә кереште.

Карале, моңарчы без аның белән гел татарча сөйләшкән икәнбез бит. Ул татарча беләме икәнни? Теге елларда гел урысча гына сөйләшә, берәрсе татарча сүз башласа, «не понимаю, говорите на нормальном языке», дип, мыскыллы елмая торган иде.

– Сез татарча да беләсезмени? – дип сорадым мин, һаман теге чаклардан аерыла алмыйча.

– Белмәскә, татар хатыны ич мин – Самат кызы Мәрвия. Лаеш районыннан. Ну, ничек, киттекме миңа?

Миндә инде ашау кайгысы калмаган иде, котылу өчен генә телефон номерын сорап алып, тизрәк саубуллашу ягын карадым.

– Көтәм, килми калма, рәнҗермен, – дип кычкырып калды ул артымнан.

...Мин институтка эшкә килгәндә (биографиямдә андый борылыш та булып алды) Марина Сергеевна, әй лә Мәрвия Саматовна, 40-45 яшьләр тирәсендәге бик хәтәр бичә иде. Озын буйлы, нечкә билле, чибәр. Бик тә килешле киенә. Бизәнү әйберләре дә кыйммәтле иде аның. Хушбуе да французларныкы.

Аның ире хәрби кеше – Татарстан хәрби комиссариатындамы, Казан танк училищесындамы, зур гына бер чин иде. Хәрбиләргә хас булганча, гаиләләре белән бөтен Советлар Союзын диярлек йөреп чыкканнар, Чехословакиядә дә, Германиядә дә, Ленинградта да яшәгәннәр. Мин аның белән танышканда кызларының берсе – университетта юридик факультетта, икенчесе 18 нче номерлы инглиз телен тирәнтен өйрәтүче дәрәҗәле саналган мәктәптә укый иде.

Марина Сергеевна үзләренең чит илләрдә дә яшәүләре, иренең зур түрә булуы, кызларының үтә акыллы, белемле, зәвыклы икәнлекләре, Горький урамындагы дүрт бүлмәле фатирлары, өр-яңа «Волга» машиналары, шәп йорт җиһазлары – Германиядән алып кайткан гарнитурлары, Чехословакиядә эшләнгән хрусталь люстралары, савыт-сабалары, Идел буендагы дачалары белән дә масая, безгә даими рәвештә, гел шулар турында, әлбәттә инде, сездә боларның берсе дә юк, була да алмый, дигән тон белән сөйли иде. Бу турыда гел ишетеп торудан туеп бетсәк тә, аңа беркем каршы әйтергә базмый иде.

Мин ул институтта биш айга якын гына эшләп алдым. Кайбер хезмәттәшләр белән әле дә элемтәдә торабыз. Ләкин, менә хәзер искә төшереп утырам, күпләрне телгә алсак та, Марина Сергеевнаны бер генә тапкыр да искә төшермәдек бугай. Күрәсең, ул үзенең холык-фигыле белән күпләрнең җанына тоз салган булгандыр. Инде менә шундый очрашу.

Ә беркөнне... аның телефоныма теркәлгән номерын ялгыш җыйганмын. Теге якта җавап биргәч, хәл-әхвәл сорашмау тәрбиясезлек булыр иде, сөйләшеп алдык. Ул шунда ук үзенә кунакка чакырды. Бу юлы журналист кызыксынуы җиңде.

...Бизәнеп-ясанып, искерәк булса да, бик матур өй костюмыннан каршы алды ул мине. (Сокланып та куйдым, шушы яшьтә дә үз-үзен карап йөрткән ханымнар бик сирәк бит ул.) Ә өе шапшак, күптән инде ремонт ясалмаганлыгы да күренеп тора. Йорт җиһазлары да теге еллардан калган. Кайчандыр ефәк тукыма белән обойланган диварлары инде төсен җуеп, ямьсезләнгән.

Беркем белән дә аралашмады бит ул шул холкы аркасында.

– Кызларның берәрсе яшәргә чакырмасмы яки бөтенләйгә кайтмасмы дип ремонт та ясатмыйм, җиһазларны да алыштырмыйм, игътибар итмә, – диде ул минем ни уйлаганымны сизгәндәй. Чакырмыйлар да, кайтмыйлар да, җир битләр алар.

Өлкән кызыбыз Жанна башта Мәскәүдә яшәде, аннары Америка кешесенә кияүгә чыгып, шунда китте дә яшәп калды. Элинасы да аның янына киткән иде, аннан бер негрга кияүгә чыгып, Испаниягә күченделәр. Шул кара пәриеннән бала да тапты. Инде күптән аерылыштылар, тик кайтырга теләми. Мине дә чакырмыйлар. Ә әниләре 15 мең сум пенсиягә яшәп ята монда. Хәер, яшәүмени бу, пенсиянең 6150 сумын фатирга түлим, 2 меңен социаль яклау бүлегеннән килеп йөрүче хатынга. Мин бит өй дә җыештыра, кер дә юа, үтүкли дә алмыйм. Ул хезмәтләр хәзер бар да түләүле. Безнең ил җитәкчеләре әнә шулай картларны талап баый, оятсызлар. Ә даруларга күпме кирәк! Әллә нигә бер мәртәбә әнә шулай «Чәй йорты»на барып, сыйланып кайтам. Хәзер йөрүләре дә авыр, аякларым сызлый, кан басымым югары, шикәр чире дә бар миндә. Мин үлгәч кайтырлар әле юньсезләр, фатирны сатып бүлешергә.

– Яннарына кунакка баргалыйсыздыр бит?

– Элегрәк үзләре кайткалыйлар иде. Аларның кайтуыннан ни файда? Танышлары белән очрашып, күңел ачып йөриләр дә, китеп баралар. Икесенә дә, ичмасам, фатирны ремонтлап калдырыгыз, диваннарны алыштырыгыз, дип карадым, барыбер сатасы бит аны, нигә акча әрәм итәргә, диләр. Минем тизрәк үлгәнне көтәләр, юньсезләр, ә мин үлмим бит әле, яшим. Ә үзем элегрәк берничә мәртәбә барып, икесендә дә яшәп карадым. Тегенә кагылма, монда барма, биредә алай

PRESSA.RU

итмиләр, болай сөйләшмиләр дип акырып кына торалар. Фатирыңны сат та, монда күчеп кил, ди Америкадагысы. Без сине әйбәт пансионатка урнаштырырбыз, ди. Пансионат шул ук картлар йорты бит инде ул.

– Үзләре белән яшәргә чакырмыйлармы?

– Алар янында яшәп буламы?! Жаннасының янкие үзен шулкадәр тәкәббер тота, әйтерсең, без аюлар арасыннан килгәнбез. Әле өйрәтмәкче, тәрбияләмәкче була. Мине – теге елларда ук дистәләрчә илдә сәяхәттә, кунакта булган офицер хатынын! Имеш, без яши, акча тота белмибез. Жаннаны да акча дип гел битәрләп тора. Тегене дөрес алмагансың, моны икенче кибеттән алырга кирәк иде, дип. Әллә мин килгәнне яратмый?

– Ә кече кызыгыз чакырмыймы?

– Негрдан туган малаеның кыяфәтен күрәсем дә, ишетәсем дә килми. Ашауларына кадәр яратмыйм. Фу!!!

Алма агачыннан ерак төшми шул ул.

– Ялгыз да бик авыр ич үзегезгә. Туганнарыгыз бармы соң, йөрешәсезме?

– Казанда да, авылда да сеңелләрем бар барын. Тик алар белән сирәк очрашабыз. Авылдагысы шыр надан, аның белән нәрсә турында сөйләшәсең. Узган ел, фатирыңны сат та, монда кайт, бергә-бергә яшәрбез, ди. Үзеңә аерым йорт сатып алырбыз, әнә күршедә берәүләр сата, ди. Күрдем мин ул йортны. Мунча кебек нәрсә шунда. Ни бәдрәфе, ни ваннасы, ни җылы суы юк.

Мондагысы фатирымны сатып, кечерәккә күчәргә киңәш итә. Шул акчага рәхәтләнеп яшәрсең, ди. Сатты ди, сатмыйни! Әле күптән түгел генә, миңа инсульт булгач, хастаханәгә малае хәл белергә килгән иде. «Әйдә, Мәрвия апа, фатирларны алыштырабыз, шуның хисабына без сине тәрбияләп торырбыз», – ди. Һе, ансат кына фатирлы булмакчылар. Кызларым бар ич минем. Кайтырга уйласалар, кайда яшәрләр?

– Үзең ич, алар инде монда кайтмый, дисең...

Бәхәсләшеп тормадым, китәргә кузгалдым. Барыбер бу киребеткән карчыкка берни дә исбатлый алмас идем. Ул исә, тагын аз гына утыр инде, дип кулыма укябышты, тагын гап-гади карчык кыяфәтенә кайтты. Чәй дә эчмәдек бит әле, дип, аякларын көчкә өстерәп, кухняга кузгалды. Мин, аның кырку холкын белгәнгә, ул чәй әзерләп, чакырганчы дип, залда калдым. Шактый гына утыргач, янына чыксам, ул әле чәй куймаган, калтыранган кулларын угалап, елап утыра иде.

Тиз генә чәй куеп, чәчелеп яткан дарулары арасыннан тынычландыра торганын сайлап, дару эчердем. Шактый шакшы, таралып яткан өстәлен сөртеп, чәй әзерли башлагач, ул: «Минем сиңа чәй эчерергә берниндиди сыем да юк икән бит», – дип каткан булка кисәкләре һәм суыткычтан искерә башлаган май, кибеттән алган кайнатма чыгарды. Ялгыш кына күзем төште: суыткычы буш диярлек иде. Мин исә үзем белән алып килгән күчтәнәчемне залга чыгып алып, ул аны эре генә кыяфәт белән бер читкә алып куйган иде, конфетлар һәм ул яраткан «курабье» печеньесын өстәлгә куйдым.

Ул тагын, һай, онытмагансың икән, рәхмәт сиңа, дип, елап җибәрде. Аннары, тынычлана төшкәч, ашыгакабалана печенье белән чәй эчәргә кереште. Тискәре җавап ишетәсемне белсәм дә, күршеләрең әйбәтләрме, аралашасызмы, дип сорадым. Ул кул гына селтәде.

Саубуллашканда аның йөзенә янә тәкәбберлек иңде, мине дә артистларча озатып калды. Мин тизрәк урамга чыгып, киң итеп сулыш алдым да: «И-и, Ходаем, мондый көннәргә калдыра күрмә», – дип кат-кат кабатладым. Өйгә кайтып җиткәнче күз алдымнан бик авыр кино кадрларыдай очрашу мизгелләре үтте. Ә колагымда шактый вакыт аның: «Килеп йөр, озаклама», – дигән сүзләре яңгырап торды.

Гаеплемен, башка аның янына бармадым да, шалтыратмадым да. Ләкин еш искә төшердем мин аны. Шалтыратып хәлләрен белешим дип талпынсам да, соңгы очрашуны искә төшереп, кире уйлый идем. Аның гел тискәре генә сөйләп торуы, беркем, хәтта балалары, туганнары турында да әйбәт фикердә булмавы, тәкәббер кыяфәт белән озатып калуы күз алдына килә дә телефонны сүндерә идем.

Берәр еллап узгач, тагын ялгыш аның телефон номерын җыйганмын. Трубканы аныкына охшаган тавышлы, ләкин чит хатын-кыз алды. Мәрвия ханымны сорагач:

– Үлде бит ул, менә иртәгә җидесен үткәрергә җыенабез, – диде ханым. – Сез кеме аның, элеккеге хезмәттәшемени, бик әйбәт, ашына килегез, юкса кемне чакырырга да белмибез.

Ханым аның сеңлесе Мәрзия булып чыкты һәм апасының кыланышларыннан зарланырга тотынды. Монысы да шундыйрак, ахры, үлгән кеше турында начар сөйләмиләр инде, дип эчтән генә уйладым да:

– Кызлары кайттымы? – дип сорадым.

– Ю-юк, кая ул. Шалтыраттылар гына. Үзегез җирләгез инде, фатирны саткач, хисаплашырбыз, диделәр.

– Мәрвия апа өендә үлдеме? Җан биргәндә янында кеше булдымы?

– Юк, хастаханәдә. Тагын инсульт булды аңа. Башта айга якын Һиндия апа белән чиратлашып карадык, балалар да дежур торгалады. Хәле әйбәтләнә башлагач, тагын телләшергә тотынды. Тегесе болай түгел, моны дөрес эшләмиләр, ашыгыз тәмле түгел, имеш. Тәмам гарык булып, аны карап торучы (сиделка) ялладык. Аның тәүлегенә 1200 сум аласын белгәч, кычкырыша башлаган да, чираттагы инсульт булган. Үлә алмыйча интегеп бер атна ятты. Рәнҗеткән кешеләренең каргышы, гөнаһлары интектергәндер инде. Ай-һай, җан бирүләре авыр икән.

Ул тагынниләрдер әйтмәкче иде, мин: «Урыннары җәннәттә булсын Мәрвия ханымның», – дип, саубуллашырга ашыктым. Теге яктан: «Нинди оҗмах, ди, аңа», – дигән сүзләр генә ишетелеп калды.



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз.



ШИҺАПОВА Гөлгенә

Казан дәүләт университеты

Кияүдә, ике кыз әнисе

Карьера: «Ватаным Татарстан» газетасы журналисты

Тормыш шигаре: «Булганына мең шөкер!»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Туганнарым арта!

Әбиемнең хәбәрсез югалган абыйсының кызы белән ике ел элек кенә очраштык: әбием 70 елдан соң туганын табып, безне таныштырды, дуслаштырды. Бабамның башка гаиләдә туган балаларының оныкларын да белми идем. Никтер ул туганнар турында моңарчы уйламаганбыз... Ә бабайның оныклары безнең хакта онытмаган! Беркөнне Вконтактедагы сәхифәмә таныш түгел кешедән: «Сүземне ничек башларга да белмим», – дигән хат килеп төште. Бабайның Камәрия исемле кызының кызы Венера икән! Язышып, сөйләшеп сүзләр бетмәде. Тиздән бөтенебез бергә җыелышып күрешергә, туганлык җепләрен ныгытырга дип торабыз.


Җан да тарта, кан да

Мөхәммәд пәйгамбәребезнең туган көне алдыннан Мәскәүнең «Крокус Сити Холл» сәхнәсендә, яшьләргә ислам диненең нигезләрен аңлату өчен «Югалган васыять» дигән театральләштерелгән спектакль куелды. Төп рольләрнең берсен актер Марат Бәшәров башкарды. Соңгы вакытта татар, мөселман дөньясына шактый якынайды ул. Хәтта: «Әгәр андый мөмкинлек туса, чакырсалар, Камал театрына уйнарга да кайтыр идем, алай гына да түгел, күченер идем. Тик минем мишәр акцентым бар шул...» – дигән сүзне дә әйтте.


«Сәләт» Җир шары буйлап атлый

Быел Канадада беренче тапкыр «Сәләт-Монреаль» аланы эшли башлаячак. «Сәләт» аланы Монреаль шәһәрендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән узачак. Анда катнашучы яшьләрне конкурс аша сайлап алачаклар. Сәләтле балаларга, актив яшьләргә аралашу, бер-берсе белән танышу, үзләрен таныту өчен шундый зур мөмкинлек булачак инде бу!

сөендерде









көендерде

сөендерде










көендерде

сөендерде







көендерде

Күңелемдә бушлык калды...

Кәбисә елын инде исән-сау гына чыгабыз дигәндә, әбием бакыйлыкка күчте... Кечкенә чагымнан мине кадерләп үстергән кешем иде ул. Авылга кайткан саен, икәү сандык актара идек без аның белән. Үлемтекләренә кагылган саен: «Соңгы юлга матур итеп озатыгыз», – дия иде. Ә мин сүзне шаяртуга борам: «Әби, мин кайтмыйча үлмә, көтеп тор!» – дим. Көтте ул мине! Мин кайткач, үлем түшәгенә яткан җиреннән торып ук утырды. «Китәм инде, рәхәт яшәгез, мин сиңа риза-бәхил, балам», – диде. Әбием соңгы сулышын алганда янәшәсендә булдым. Мине үз сабыедай яраткан кешемне югалтуның авырлыгын аңлатырга сүзләр таба алмыйм...

Дәвасы табылырга тиеш бит!

Газетада «Кайсыгызның кулы җылы?» дигән рубрика алып барам. Ярдәм өмет итүчеләр гел арта бара... Шөкер, игелекле, мәрхәмәтле кешеләр исә гел табылып тора. (Парадокс: күп вакыт кесәсе калыннар түгел, әби-бабайлар ярдәм кулы суза.) Әмма кайчак ярдәм итәргә өлгермичә калабыз, шунысы авыр... Яман чир кебек гасыр афәтеннән котылу юлы табылсын иде инде! Күптән түгел «Игелекле Казан» форумында катнаштым. Шунда бер Мәскәү кунагы: «Татарстанда яман шешне җиңү өчен барлык мөмкинлекләр бар, үзегезнең авыруларга гына түгел, күрше республикаларныкына да булыша аласыз», – дигән иде.

Татулыкка ни җитә дә бит?!.

Борчуларым да Канада белән бәйле. Әле яңа гына, намаз вакытында кереп, Квебек шәһәре мәчетендә алты мөселманны атып үтерГәннәр иде. Бер сәбәпсезгә! Инде шул мәрхүмнәрнең өчесен үткәргән көнне тагын күңелсезлек. Бу юлы Монреаль шәһәре мәчетенә вандаллар һөҗүм иткән: тәрәзәсен ватканнар, диварларына йомырка белән бәргәннәр. Шөкер, монысында беркем дә зыян күрмәгән. Бернәчә көн элек кенә исә мәчет стеналарына төрле язулар язып калдырган булганнар. Мөселман дөньясына соңгы вакытта булган һөҗүмнәр куркыта, шикләндерә, шомландыра...

PRESSA.RU


Фото интернеттан алынды

СТУДЕНТ ЧАК. ЯШЬЛЕК, ХЫЯЛ, РОМАНТИКА, МӘХӘББӘТ... ТӘҮГЕ ТАПКЫР ГАШЫЙК БУЛУ. ИХЛАС ХИСЛӘР...

Еллар узса да, алар искерми, тутыкмый икән. Әйдәгез, февральнең «Гашыйклар көне»ндә Гөлчәчәк исемле студент кызның көндәлегендә сакланган бәхетле мизгелләрнең шаһиты булыйк әле. Бергә сокланыйк, бергә яныйк-көйик...



Эльмира ЗАКИРОВА

САҒЫНЫП КАЙТЫП КЕРСӘҢ...

Казан, 27 июнь, иртәнге 5. Будильник шалтырыймы, әтәч кычкырамы? Никтер авылдагы әтәчебез уята кебек тоелды. Күзләремне чак ачып, кайдалыгымны чамаларга тырыштым. Тулай торак бүлмәсе. Ачык тәрәзәдән тыкы-тыкы поездлар узганы ишетелеп кала. Кошлар сайрый. Географакта укучы Ира, Раялар берни дә ишетми йоклый. Колак төпләрендә быргы кычкыртып торсаң да, әйләнеп кенә ятачаклар. Зачет-имтиханнар – артта, сессия тәмам! Практика көннәре башлана. Ә миңа торырга кирәк! Бүген экспедициягә китәбез! «Тор, Гөлчәчәк, сине бөек эшләр көтә!» – дим үземә. Алгысуымның сәбәбе ерак юлга чыгу гына микән?

Аһ, әйе... Шул егет... Исемен Радик диделәр... Кичә генә репетициядә таныштык. Миңа ул... Чәчкә дип эндәште! Югыйсә күрде, ишетте бит инде Гөлчәчәк дип дәшүләрен! «Чәчкә, иртәгә поезд ничәдә әле?» – ди. Үзе туптуры итеп күзгә карый. Оялудан кызарып чыктым бугай. Ай, ничек матур уйный баянда! Ул да безнең белән бара! 30 кешедән торган төркемебезне унар-унар итеп өчкә бүлделәр. Башкортстанның төньягындагы авылларда халык авыз иҗаты өйрәнәчәкбез, фольклор җыячакбыз! Берәүләр – Караиделдә, икенчеләр – Тәтешледә, без – Балтачта. 2 нче курс татар филологлары Себергә үк китәргә җыенып йөри әнә.

Анысы диалектологик экспедиция була инде. Әдәбият тарихы, тел белеме, фонетика, топономастика, античка, зарубежкалар... Хушыгыз! Зачеткада сезнең өчен «4»ле, «5»леләр генә елмаеп утыра. Ачык тәрәзәдән кергән талгын җил көндәлек битләрен ачып уйный. Узган семестрда булган вакыйгаларны искә төшертә...

Февраль. Авылны сагынган саен аэропортка барып, үзебезнең районнан очып килгән самолетларны көтеп алулар (берәр таныш йә авылдаш очрамасмы, янәсе!) тукталды. Өйгә хатлар язганда да хәзер конвертта үз адресымны «Мой адрес не дом и не улица, / Мой адрес Советский Союз» дип язмыйм: төрле әбиләргә фатирга урнашып йөрүләрне тулай торак тормышы оныттырды. Казанда укучы классташлар белән Камал театрына бардык. «Диләфрузгә дүрт кияү»! Ринат Таҗетдиновка тәмам гашыйк булып кайттык.

Атнаның һәр чәршәмбесендә Ульянов һәйкәле янында Гүзәл белән сәлам бирешеп узабыз. Ун ел бер партада утырган дус кызым медта укый. Икебез дә ашыгабыз: мин – колонналы бинада иске татар язуы дәресе үтә торган аудиториягә, ул – университет артындагы анатомичкага.

– Шимбә кич кил, Гөлчәчәк! «Кызыл почмак»та – танцылар! – дип үзләренә чакыра Гүзәл.

Март. Их! Тагын йоклап калдык! Лекциядә фамилияңне билгеләми торган кайбер парларны Айсылу белән «тозлыйбыз» кайчак. Имтиханга әзерләнгәндә барыбер укыйбыз ла. Мескен «КПСС тарихы»! Беткән баш беткән, дип, барып тормаска булдык. Ә киного – барабыз менә! Айсылу белән без университетка кергәнче үк таныш идек инде. Икебез дә «Яшь ленинчы»ның яшь хәбәрчеләре. Айсылу Кәримова исемле кызның шигырьләре «Ялкын»да, «Яшь ленинчы»да басыла. Ул керү имтиханында «Безнең яшьлек» дигән темага иншасын да шигырь белән язды!

Тулай торакта югары курс егетләре мине «пионерка Гөлчәчәк» дип йөртәләр икән. Нурия шулай ди. Бантик тагып йөри торган чәчләремне кистергәч, «Кавказская пленница»дагы Нинага охшап калдың», – диделәр. Унынчыда укыганда «Я шагаю по Москве»га класс белән культпоход оештыргач та, Флүн дигән малай шунда уйнаган Галина Польскихка охшаткан иде. Хәзер менә Наталья Варлей белән чагыштыралар! Мәктәптә киноартистлар фотоларын җыю белән мәш килә идек. Мин ул артистлар тулы альбомны Казанга да төяп киттем. Кайбер варенье, каймак банкаларын әни күрмәгәндә «онытып» калдыру бәрабәренә... Менә хәзер минем янда Варлей елмая. Аксинья – Элина Быстрицкая, Наташа Ростова – Людмила Савельева, Ассоль – Анастасия Вертинская, Штирлиц – Тихоновлар да минем белән...

Март ахыры. Спорт сараенда тере киноартистлар белән очраштык! Инна Макарова, Моргунов, Вицин, Никулин... шәп спорт комментаторы Николай Озеров, «Крокодил Гена»ны җырлаучы Ферапонтов та алар белән бергә! Айсылу белән икәүләп бардык. Беренче сеанстан соң мең хәйлә белән икенчесенә дә калдык әле. Автографлар аласы килгәч соң! Николай Озеровка Казан университеты значогын бүләк иттем. Вицин ялт кына үз кыяфәтен ясап, кул куйды. Ә Моргунов... чәнечкеле иде! «Вакыт уздырып йөргәнче, укыгыз ичмаса», – дип шелтәләп ташлады.

Апрель. «Ленин зачетлары» дип куркытып маташканнар иде. Бернәрсәсе дә юк икән лә! Университетның комсомол комитетыннан вәкилләр кереп утырды. Факультетның партоешма әгъзалары керде. Старостабыз Зөбәйдә, профорг Кадрия, комсорг Фирүзә президиум өстәле янына үттеләр. Укуыбыз, җәмгыятькә файдалы эшләрдә катнашуыбыз, сәяси әзерлегебез турында сүз барды. Һәрберебезгә характеристика бирделәр. Миңа чират җиткәч: «Әллүки» берләшмесенә йөри, «Әдәби сүз» газетасын чыгаруда актив катнаша», – дип тезеп киттеләр. Ә Рая: «Ул хыялый, матур кеше. Мин Гөлчәчәкне әдәби образга ошатам», – дип мактап атты. Менә шундый чын күңелдән сөйләшү! Группадашларым бөтенләй башкача карый башлады!

Никтер шул Радик күз алдына килә дә баса.

14 июнь. Фарсы теленнән зачет тапшыргач, укытучыбыз Мостафа Ногман белән фотография салонына кереп, рәсемгә төштек. Ул махсус безнең группа өчен җыр язган. Рөстәм Яхин белән бергәләп! Мостафа абый барыбызга да «автомат» куеп чыкты да, фарсы теле дәресендә яңа җырны җырлап утырдык: Киек казлар оча җылы якка, / Төркемнәре белән гел бергә. / Казлар китә, ә без – якын дуслар / Сагынышып килдек күрешергә...

Бездән бер курс алдарак укучы журналистика төркемендәгеләргә дә укытучыбыз: «Сезгә багышланган җырым», – дигән. Ул яшьлекне, студентларын яратып язган, еллар узгач та менә шулай сагынышып күрешәсебезне күз алдында тоткан булып чыга түгелме? «Мән ту ра хейли дуст дарәм!» («Мин сине бик яратам!») Фарсы теленнән бар белгәннәребез әнә шул бер җөмләгә сыя да бетә! Мостафа абый, мутланырга ярата, матур сүзләр өйрәтә, Иран, Тәһран, дип, телнең бар аһәңен безгә сеңдерергә тырыша. Җырлап-көйләп тора фарсы теле, чистарак ишетелсен өчен, иртәнге 5 ләрдә радиоалгычның ультра кыска дулкыннарын тыңлагыз, дип өйрәтә. Зәңгәр күзле Айсылуга сокланып, «чашме аби рәнг», ягъни «күзләре зәңгәр» дип кабатлый. Дәрескә әзерләнмичә килсәң, таләпчән дә үзе! Шуңа күрә безнең хәйләкәр кызлар вакытны сузар өчен укытучының салпы ягына салам кыстыра башлыйлар:

– Мостафа абый, тулай торакта гел сезнең җырлар гына яңгырап тора! – диләр. Укытучыбызның күзләре очкынланып яна башлый:

– Чынлапмы, чынлапмы? – дип, бала-чага шикелле очына. – Кайсыларын җырлыйлар?

– «Салагыш болыннары», «Арча кичләре», «Туган авылым Чынлы», «Актаныш таңнары», «Бер гүзәлен

PRESSA.RU

сагынам Чишмәнең»... – дип, бер-беребезне бүлә-бүлә санарга тотынабыз.

– Бишенче курс кызлары кухняда аш пешергәндә «Алларын алсаң икән, / Гөлләрен бирсәң икән», – дип җырлыйлар иде, Мостафа абый! – дип ярып сала чая Тәгъзимәбез.

– Ә сез соң беләсезме ул җырны? – дип канатлана чал чәчле абыебыз.

Белмиме соң! Без, дәреснең шундый борылыш аласын алдан ук хәстәрләгән хәйләкәр кызлар, җырлый башлыйбыз:

«Сагынган минутларымда / Елмаеп килсәң икән...»

26 июнь. Имтиханнардан котылу шатлыгыннан, төркемебез белән Казанның җанга якын урыннарында йөрдек кичә. Химкорпустан «Бегемот»ка кадәр фарсы теленә йөгерә торган сукмаклардан ашыкмыйча гына Кремльгә таба менеп киттек. Ерактан күренгән Иделгә, Ослан тауларына, таулар артына иңеп баручы шәфәкъ кызыллыгына карап сокландык. Экспедицияне уйлап, хыялланып алдык. Иртүк юлга чыгасыбыз булганга гына «Ленин бакчасы» тукталышына атладык. Кызыл Позиция урамындагы тулай торагыбыз һаман гөр килә иде.

Мин инде Казанны ярата башладым!

27 июнь. ...Бөтен көченә ачылган радиодан гимн яңгырый башлауга, шкаф өстенә үрелеп, тиз генә борып куйдым да, аяк очларына гына басып ишеккә атладым. Нурия белән кичтән үк килешеп куйган идек: ЦУМнан икебезгә дә пардан алган яшел ситсы күлмәкләрне киябез, иртәнге 6 дан соңга калмый чыгып китәбез. Көзгегә әллә ничә тапкыр карадым: ничек күренәм икән? Бүген Радик та була бит!

...Казан–Свердловск поезды янында җыела да башладык. Җитәкчебез Фәнисә Камиловна үзе дә студентлар кебек: җыйнак гәүдәле, шат күңелле, җитез.

Лира, Зөләйха, Фирүзә, Тимур, Зөфәр, Наил, Нурия, мин – безнең группа әзер. Тик икәү генә юк: Алик һәм Радик. Икесе дә безнең өчен бераз ятрак. Алик бездән бер курс югарырак журналистикада укый. Ул кичке концертларыбызның алып баручысы булачак. Юмористик хикәяләр яза. Сәхнәдән кызык тамашалар сөйләп көлдерә. Әнә үзе дә килеп ята. Ә Радик Мадьяров – педтан, музфак студенты. Шәп баянчы икәнен белдек инде кичә. Җырчы Вафирә Гыйззәтуллинаны Болгариядә дә җырлатып кайткан, ди. «Озак йоклыйм мин», дип, соңга калырга яратуын сиздереп куйган иде инде. Ә-ә-ә, тагын бер әйбер: безнең белән барам дип, кичә психологиядән досрочно «неуд» алды. Дөресрәге, үзебез «2»ле алырга сәбәпче булдык. Тагын... Кулыннан һич кенә дә сигареты төшми инде. Кичәге «2»ле өчен кайгырып тартамы, бүтән сәбәпләре дә бармы – белмәссең. Кара, бу егет әллә нинди серле күренә әле! Аксыл-сары чәчләрен колакларын капларлык итеп мода буенча үстергән, озын буйлы, калын иреннәре яхшы күңелле булуына бер ишарә бугай... Юу-уу-ук, чибәр түгел! Тик... нәрсәдер бар анда. Ул... Дин Ридка охшаган!.. Киноактер ковбой эшләпәсеннән төшкән фотосында гел Радик инде... Аның килүен күргәч, йөрәк... туктап калды кебек. Тиктомалдан кызарып чыктым.

– Җәмәгать! Үзебезнең поезд янында бер чертләтим әле үзегезне!

Бусы – Алик. Кап-кара чәчле, кара күзле, ерык авызлы, кызлар кызыгырлык чибәр. Мыек та җибәргән. Төсе-бите белән генә түгел, холкы, табигате белән үк Дон казакларын хәтерләтә. Теле һич тик тормый. Кызларга комплиментлар яудыра, йә берәр мәзәк сөйләп көлдерә, йә журналист роленә кереп, интервью алган булып йөри. «Сез бу экспедициядән нәрсә көтәсез? Халык авыз иҗатын яңа табышлар белән ничек тулыландырырга уйлыйсыз?» – дип, әллә нинди сораулар уйлап таба. Баянда да уйный, тик Радик сыман ук түгел инде. Ярыйсы гына җырлый. Тик Зөфәргә җитә алмастыр. Зөфәр җырлап та куя! Моңы белән йөрәкләргә үтеп керә! Уйчан, җитди егет. Армиядә дә хезмәт итеп кайткан. Бездән олырак. Группа халкы аны «әткәй» дип йөртә. Тимур исә шәһәр егете. Атаклы фольклорчы галимнең оныгы. Бабасы Тимурның гарәп-фарсы телләрен үзләштереп чыгуын бик тели икән. Шуңа безнең белән укып йөри. Озын буйлы хиппи егет. Гитарада уйнап җырлый, «лезгинка» бии, шәп джентльмен.

Кузгалып китәр алдыннан гына Айсылу белән Тимур вагонга атылып керде. Озатучылары белән хушлашып. Вагон тәрәзәләреннән Кремль, университетның биек физкорпусы, таныш урам-тыкрыклар шәйләнеп калды, Әмәт тавы, үзебез яшәгән тулай торак, тоннель... Моңсу булып китте. Радик, әйтерсең, күңелебездә ниләр барын сизеп торучы телепат: баянда аккордлар биреп алды:

Озатып калырсың безне, Казан, / Баласын очырган кош сыман...

Куеда. Арча, Әгерҗеләрне, Удмуртия җирләрен дә калдырды поездыбыз. Башкортстан буйлап барабыз. Группаның бер төркеме Янаулда төшеп калды, шуннан Караиделгә китәчәкләр. Ә без һаман барабыз. Җыр, шаян сүз тынып тормый. Университетның атаклы татар хорына йөрүче Нурия мине концертта парлап җырларга кыстый. Зиннур Нурмөхәммәтов репертуарындагы «Хәерле юл» җыры безнең альт тавышка туры килә, ди. Вагон тәрәзәләренә бәрә-бәрә яңгыр коя. Ә без җырлыйбыз: Озын юллар кыска тоела, / Матур җырлар җырлап үтсәң. / Ак чәчәкләр белән каршы алырмын, / Сагынып кайтып керсәң...

Радик... елмаеп баянына үрелә. Безне үсендереп, дәвам итегез, дип, ым кага. Чынлап та, озын юл матур җырлар белән сизелмәде дә. Пермь өлкәсенең Куеда станциясе безне куна килгән яңгыры, елак киче белән кунакханәгә озатты. Явымда теләр-теләмәс кенә атладык. «Их, җаным, шулай авыр күтәрәләрмени!» – дип, Радик... кулымнан сумкамны алды!

(Дәвамы бар.)



Асия ЮНЫСОВА


БЕЗ ТОРМЫШТА МӘХӘББӘТКӘ АРТЫГРАК ӘҺӘМИЯТ БИРӘБЕЗ МИКӘН ӘЛЛӘ? ЮГЫЙСӘ БИТ ЯШӘҮНЕҢ МӘХӘББӘТТӘН БАШКА ДА КАНУННАРЫ БАР.

ТӘРӘЗӘЛӘР СЕРЕ

Разия, елаудан туеп тынычланып калган оныгын читлек караватына салды да, берара җыр көйләп, тирбәткәләп утырды. Сабый тиз йоклап китте. Еш кына шулай, әтиәнисе баланың көен таба алмаганда, аны дәү әнисенә тапшыралар да үзләре йокларга яталар. Разия ханым бала багуны читенсенми. Киресенчә, куенына сеңгән, куен җылысыннан изрәгән нарасыйның мыш-мыш сулыш алуыннан үзе генә белгән бер татлы рәхәтлек кичерә ул. Бәби дә шундый ук рәхәтлеккә тала, күрәмсең. Дәү әнидән сирпелгән җылы дулкыннар аны да тынычландыра. Гомер бакый шулай – бәби белән әби бик тиз уртак тел таба. Әбиләргә оныксыз картаерга язмасын.

Разия, бала караваты яныннан торып, тәрәзә янына килде. Төнге күктә болытлар белән качышлы уйнаган Айга озак-озак карап торды. Айга шулай озаклап карап торырга ярата ул. Ай – аның гомерлек сердәше. Беркем белән уртаклашмаган серләрен ул гына белә. Разияның йөрәгендә серләр күп. Хатын-кыз үзе генә белә торган серләр алар. Төнге сәфәргә чыккан Айны озак кына күзәткәннән соң, Разияның күзләре таныш тәрәзәне эзләп тапты. Башка йортлар ышыгында кысылып калган бу тәрәзә аның тормышындагы иң якты учак. Учак! Чөнки ул тәрәзәдә төне буе ут сүнми. Разияның йөрәгендәге кебек. «Менә, җаным, оныгың да йоклап китте, ә син һаман йокламагансың. Йоклый алмыйсыңмы? Башың сызлый торгандыр инде».

Кеше алдында ялгыш исемен әйтеп җибәрүдән куркып, ул аңа



гомер буе гаять итагатьле итеп, «абый» дип кенә эндәште. Әйе, бергә эшләделәр. Эштә күрешеп торгач, аерым яшәүләре авыр булмады. Разияның да ире бар, тик менә балалары гына юк иде. «Абые» белән яшерен мәхәббәте аңа ике малай бүләк итте. «Абые» моңа тыныч карады. Балалар дип егылып китмәде. Ир булган кеше дә малайларының кемгәдер охшаган булуын күрмәде. Югыйсә малайлар үз әтиләреннән «өзелеп төшкән» кебек иделәр. Хезмәттәшләренең бу ханымга хөрмәтләре зур иде, шуңа күрә аның баласызлык проблемасын үзенчә хәл итүен гаепкә алучы булмады. Кеше гаиләсен бозмады лабаса Разия, үз гаиләсен дә саклап калды, фәкать тын гына ярата бирде, тәртипле, акыллы балалар үстерде. Ә күңелдә, мәңге чынга ашмас хыял булып, берәр вакыт бергә булу уе-теләге яшәде. «Абые» да ярата лабаса аны. Кайвакыт балаларга дип, бүләкләр дә алгалый.

Шулай гомер узып бара. Инде хәзер икесе дә пенсиядә. «Абыеның» гомер буе башы сызлады. Контузия касәфәте. Әфган мәхшәрен кичкән кеше иде ул. Аның башы сызлаган төннәрдә тәрәзәдәге ут төне буе яна. Шул уттан Разияның башында да сызлау кабына. Төнне шулай ике йортта сызланып кичәләр. Аерым яшәсәләр дә, бергә!

Берзаман «абыеның» җәмәгате үлеп китте. Бергәлеккә юл ачылды кебек. Инде егетләр дә башлы-күзле. Оныклар үсә. Их, кыйпылчыкларны бербөтенгә туплыйсы иде ул! Разия, тәрәзәгә килеп, теге икенче тәрәзәгә шуларны сөйли. Тагын бер сөйләр әйберсе бар әле аның: «абыеның» баш сызлавын тәки үзенә алды бит ул. Төн йокламый сызланып чыккан чаклары ешайды.

«Абый» булган кеше генә «җаный» булырга ашыкмады. Инде үзе дә тол калган Разия аның ишек шакыганын көтеп йөргән көннәрдә «абый» өйләнеп куйды. Гомер буе яратудан, сызланудан йөдәгән, көтеп арыган йөрәк сыната башлады. Дөресрәге, Разия үзе сынды. Аннары бит ханымның бәхетле сәгате сукканын өметләнеп көтүчеләр тагын да булган. Алар инде хәзер хәлгә кереп сораштырырга да кыенсынмыйлар. Бу хакта сөйләшү серне яшереп йөргәндәгедән кыенрак икән.

Тик гомере буе дәвам иткән мәхәббәт тарихының ахыры ямьле тәмамланмады. Разияның баш миендә яман шеш таптылар. «Абый» кеше, сызлануларын Разияга тапшырганнан соң да, бераз яшәде әле.

PRESSA.RU



ТЕАТРГА – ТРОМСЕГА!


Сөмбел ГАФФАРОВА

КАЗАН ЗӘМҺӘРИРЕННӘН НОРВЕГИЯНЕҢ ТРОМСЕ СУЫГЫНА ЧУМДЫК. ОЧКЫЧ РЕЙСЛАРЫН ТОТКАРЛАРГА ОСТА ӘЧЕ ҖИЛ, КИНӘТТӘН ЯВЫП КИТҮЧӘН КАР СИНЕҢ, ЧЫННАН ДА, ТӨНЬЯК КОТЫПТА БАСЫП ТОРУЫҢА ИНАНДЫРА.





Урамдагы бозга ком да, реагент та сипмиләр. Таясың икән, әнә, аяк киеменә махсус «кыргычлар» ки дә элдерт.

Берничә кафеның ишегалдында өстәл-урындыклар тезелгән. Кафе хуҗалары эскәмияләргә болан тиреләре җәеп куя.



Автор фотолары

Тромсены «Арктика капкасы» дип атыйлар. Котып сәяхәтчеләренең экспедицияләре менә шушыннан башланган икән... Биредә иң төньяк университет, ботаник бакча, католик собор, планетарий һәм башка «иң төньяктагылар» урнашкан (чөнки тагын да төньяктаракта андый нәрсәләр башка юк). Биредә мәдәни тормышның кайнап торуы, университет, күпсанлы ресторан-кафелар булу сәбәпле, җирле халык шәһәрләрен яратып, «Төньяк Париж» дип тә җибәргәли.

«Бу шәһәр безнең Нурлат хәтле генә бит», «Әйе шул, монда алтмыш меңләп кенә кеше яши икән», – дип, янәшәмдәге Фәрит абый белән Люция апа фикер алыша. Әйе, без бирегә Г. Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев һәм аның хатыны, актриса Люция Хәмитова белән бергә килдек. Нәрсәгә булсын тагын? Театр карарга, әлбәттә!

«Һималай маймылы»

Кытайда узган мастер-классларга өч мәртәбә барырга туры килде үземә. Ibsen International дип исемләнгән Норвегия–Кытай воркшобында сигез язучы катнашабыз – Кытай, Норвегия, АКШ, Италия, Көньяк Африка һәм Татарстаннан. (Бу хакта тулырак: http://syuyumbike.ru/yashaesh/puteshestviya/?id=3083)

Кытайда күргәннәрдән илһам алып, һәрберебез ярты ел эчендә миграция темасына пьеса яздык. Норвегиядә шушы воркшопның чираттагы этабы узды да инде – барлык сигез пьесадан өзекләр алып, «Халогаланд» арктик театрында тамашачы хозурына «Һималай маймылы» дип исемләнгән спектакль тәкъдим ителде. Бүгенге көндә спектакль Норвегиянең шәһәрләре буенча гастрольләрдә йөри.

Фәрит Бикчәнтәев әйтүенчә, бу ел ахырында Гуанчжоуда узачак театр фестивалендә катнашуыбыз (пьесам шунда һәм Г. Камал театрында да куелачак дип планлаштырыла) Норвегия театры белән хезмәттәшлек күперләрен сузуның тәүге адымнарның – берсе.

Кызык хәл: миграция темасы, әйтерсең, һавада очып йөри. Әнә бит, Г. Камал театрында да драматург Илдар Юзеевның «Ак калфагым төшердем кулдан» исемле пьесасы буенча спектакльнең репетицияләре бара. Ә ул нәкъ шул темага бит!

Биредә спектакль вакытында йөткерү-төчкерү, кәгазь кыштырдату, телефон җырлавы юк. Әллә Норвегия тамашачысы һәрвакыт сау-сәламәт? Әллә соң инде сумкаларында кыштырдаучан кәгазьләре һәм җырлаучы телефоннары юк?!

Кино! Кино!


Бер атуда – ике куян! Шушы ук көннәрдә Тромседа бик популяр, халык тарафыннан ел саен көтеп алына торган Халыкара кинофестиваль уза. Конкурс программасындагы фильмнар барган кинозаллар шыгрым тулы. Ә безгә – төрле илләрдән килгән язучыларга – әлеге кинофестиваль кысаларында шәхсән үзебезгә якын булган, пьесаларыбызны яхшырак аңларга ярдәм иткән өстәмә фильмнар тәкъдим итү мөмкинлеге бирелде!

Котып янында урнашкан 60 меңлек Тромседа нишләп әле бер татар булмасын, ди, әйеме?!

Татар тарихы белән таныштырырга, үзебез төшергән киноны күрсәтергә теләдем. Шуңа күрә башка язучылар тәкъдим иткән «Великий Гэтсби», «Жизнь Пи» кебек мәшһүр фильмнар арасында авторлары Денис Красильников белән Фәридә Корбангалиева булган «Война непрощенных» фильмы да күрсәтелүен теләдем. (Әлеге документаль фильмда Фәрит Бикчәнтәев алып баручы ролендә!) Залдагы тамашачы Идел–Урал легионерлары, татар халкы турында беренче ишетүләре булганмы? Юктыр, чөнки шушы зур залда миңа бер ханым: «Сез Казаннанмы? Мин дә Казаннан! Хәзер Тромседа яшим», – дип дәште. Кызганыч, якыннан аралышырга мөмкинлек тумады.

Үзәк урам уртасында зур экран һәм эскәмияләр куелган. Көндез фестиваль фильмнарын күрми

PRESSA.RU



Тромсе китапханәсе сихри тарту көченә ия. Тыштан күренгән китап киштәләре, баскычлар, кулларына китап-журналлар тоткан йөрүчеләр арасында буласы килә. Без дә кердек. Ни күрим, воркшопта катнашучы ике Норвег язучыбыз укучылар белән очрашу уздыра икән.





калган шәһәр халкы, кичен, кайнар каһвә эчә-эчә, саф һава сулый-сулый, кино карап утыра. Кышын да балалары пластик шешәдән су «имә». Салкынныдыр инде... Ресторанда да норвеглар боз тутырылган графиннан су эчә! Нишләүләредер...

Ни дисәң дә, кар муллыгына, җил әчесенә карамастан, биредә котып салкыннары түгел. Гольфстрим агымы галиҗәнаплары җылыта.

«Халогаланд» театры

Театр бинасында йөрибез. Кинозалга тартымрак театр залында оркестр чокыры булмавына бик хафаланалар. Аның каруы, сәхнә артындагы бүлмә-остаханәләр – көнләшерлек! Костюмнар да тегелә, һәртөрле декорацияләр дә ясала – сәхнә артына фабрика яшерелгән, диярсең!

Елына ун-унике премьера уйналса да, труппа бары тик унике актердан гыйбарәт. Кирәк чакта башка актерлар белән килешү төзелә. Актерларның айлык хезмәт хакы белән кызыксынмый кала алмадык. Өч-дүрт мең евро икән.

Гримеркаларның тәрәзәләре исә... тауларга, диңгез култыгына, фьордларга – төньякның кырыс һәм җитди холыклы табигатенә карый... Заманыбызның танылган драматургы норвегияле Йон Фоссеның «Җәйнең бер көнендә» спектаклендәгечә, Люция Хәмитова Арктик театр тәрәзәсеннән, үзе уйнаган героиня сыман, фьордларга карый. Күзләре белән нидер эзли. Казанда спектакльне уйнаганда ул хәзер героинясы күргән диңгез-кыяларны күрәчәк, бу аның карашында чагылачак...

Белсәгез, «Җәйнең бер көнендә» спектакле Россиядә беренче мәртәбә Г. Камал театрында куелды. Узган елның ахырында Тромсе театрының директоры Ингер Буресанд һәм Ibsen Internationalның кураторларының берсе Фабрицио Массини (Кытайда яши), татар театрының юбилеена килде һәм шушы спектакльдән соң: «Норвегия язучысы пьесаның атмосферасын, геройларының холкын ни дәрәҗәдә төгәл тасвирлый алган да бөтенләй башка табигатьтә яшәүче, башка һава сулаучы режиссер аларны никадәр төгәл тоеп, күрсәтә белгән бит», – дип сокланганнар иде.

Кош очышы биеклегеннән караш ташлау

Алга китеп булса да, әйтим: кош биеклеге булса да, кошлар күренмәде. Караш ташлау өчен Фьельхейсен канат юлыннан өскә күтәрелдек. Җилгә, карга каршы елмаеп, безнең кебек карга күмелгән шәһәр үзәгенә карап рухландык, бер-беребезне фотога төшердек. (Чынында, «тиз генә рухланып алу» булды ул. Салкын чөнки.)

Тромсе үзәге урнашкан Тромсеа утравы шәһәрнең материктагы өлешенә күпер һәм туннельләр белән тоташкан. Норвегиядә барлыгы егерме мең күпер бар!

Боланнар хакы

Әйтүемчә, Тромсе материкта һәм утрауда урнашкан. Тау үтәли туннельләр дә бихисап, һава юлы да сузылган... Әмма таулар күп булганга күрә Норвегиянең төньяк өлеше илнең тимер юл системасына тоташмаган.

Тәрҗемәчебез Марианна: «Халык хөкүмәттән 1920 еллардан бирле тимер юл сорый – иң унайлы һәм имин транспорт бит. Әмма бу барып чыкмас, ахрысы. Болан үрчетүчеләр моңа каршы», – дип аңлатты. Ул безнең белән хушлашты да, велосипедына атланып, карлы урам буйлап тәгәрәп китте.

Polarmuseet

География дәреслекләреннән генә укып белгән Нансен һәм Амундсен экспедициясендә катнашкан Котып өйрәнүче Ялмар Йохансен Тромседа туган. Алдында Руаль Амундсен сыны торган Котып музеена кереп чыкмыйча мөмкин түгел. Музейдагы экспозицияләр, аучыларның көнкүрешен сурәтләгән манзаралар, тормыш кирәк-яраклары Котыптa яшәүнең никадәр авыр булуына ышандыра.





Тромседа. Г. Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев һәм актриса Люция Хәмитова белән төшкән иң кадерле фотосурәтем.

«Балачагымда кит ите көндәлек ризык булуы истә калган, – дип сөйләде Марианна. – Бик арзан иде ул. Хәзер исә нәкъ киресе, кит ите – кыйммәтле деликатес. Элек балалар мәктәптән туп-туры портка чабалар иде. Анда аларны акчалы эш көткән – өелеп торган тәрәч балыгының телләрен кисеп, бер читкә өеп бару».

Ял икән – ял!

Якшәмбе киченә кадәр вакытым бар. Кайтыр юлга чемоданым җыелган. Тромсеның үзәк урамы буйлап йөрүдән башка бер эшем дә юк.

Ял көне дигәч, биредә чыннан да башка Европа илләрендәге кебек үк чын-чынлап ял итәләр. Һәркеме! Бик сирәк кафе, азык-төлек кибетләре сүлпән генә эшләп тора.
Йә, хуш, хәтергә нык уелып керсен дип, шәһәр буйлап йөрим, сафчиста һавасын сулыйм, кешеләрен күзәтәм.

Хәзер монда берничә сәгатькә генә яктыра да, кабат караңгы төшә. Котып төне. Норвегларны кызганып та куйдым хәтта. Депрессия халәтенә кереп бетәләрдер инде, бичаралар... Аннары аларның төньяк балкыш күренешенә гадәти бер нәрсәгә караган кебек кенә карауларын исемә төшерәм дә, үземне кызганып куям. Кызганыч, балкыш күрү тәтемәде – күк йөзе бер генә көнгә булса да ачылмады.

Караңгылыктан ничек качалар, дисезме? Урам фонарьлары гына коткармас. Кафе, кибет, кинотеатр, фитнес заллары һәм йортларның беренче катларына тәрәзә пәрдәләре эленми икән монда. Биналарның беренче катлары – тоташ ачык тәрәзәләр. Кем чәйләп утыра, кем тренажерда йөгерә, кем кибет эчендә тауар сайлый – шәһәр кайный, хәрәкәт итә. Нәкъ шушы ачыклык, бер-береңне күрү депрессиягә юл куймыйдыр да.

Кибет дигәннән, чемодан тутырып күчтәнәч алып кайтам димә. Безнең өше кешегә хәтәр кыйммәт монда. Мисал өчен, бер сагыз кабының бәясен безнең акчага әйләндерсәң – 160 сум чамасы. «Киндер сюрприз» – 200 сум тирәсе. Сэндвич бәясе – 450 сумга якын.

Норвегиянең сукбайлары да бай, дигән фикергә килдем. Көнозын урамның бер почмагында хәер соранып утыручы абзыйның мобиль телефоннан сөйләшеп утыруы гайре табигый нәрсә түгеллеген абайласам да, бик сәер тоелды... Икенче көнне аның урынында бүтән бер хатын утыра иде... Теге абзыйның ял көне булды микән?.. Шулай икәү генәме соң алар?!

Әйе, Норвеглар кышын да велосипедта йөри, көпчәкләрен кышныкына алыштыралар да – алга!

Норвегиянең язын да күрәсе килә, җәен дә. Тролльләр юлын, Теннеседәге кыя рәсемнәрен, шау яшелгә күмелгән тауларны – болары күрелмичә, ымсындырып калды. Җәйләрен театрлары эшли микән?..



Норвегиягә барып истәлеккә сувенир тролльсез кайткан кеше сирәктер. Икешәрне алырга киңәш итәләр, янәсе тролльнең берьялгызына үтә моңсу булачак...

PRESSA.RU

16+

ХАТЫН-КЫЗ ИХЛАС БУЛСЫН



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

Алмаз МИРГАЯЗОВ, «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең радиолар белән эшләү юнәлеше җитәкчесе; гаилә стажы – 19 ел; балалары – Ислам, Алсу, Аслан.

1 Иң элек хатын-кызның Сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Әгәр ир-ат күңеленә якын булган туташ-ханымнар турында сораганда, «хатын-кызның иң элек күзенә, чәченә, киеменә игътибар итәм» дип җавап бирә икән, бу ир-ат йә үзен алдый, йә сезне... Ир-атлар, табигатьтән килгән инстинкт буенча, иң беренче чиратта, үзенә сау-сәламәт, камил акыллы, матур бала тудыра алырлык хатын-кызны сайлый. Һәм монда бернинди бозыклык күрергә, гаеп-мазар эзләргә кирәкми. Кыскасы, әгәр хатын-кыз ир-атны чынчынлап кызыксындыра икән, ул күбесенчә иң элек аның буй-сынына игътибар итә. Мин дә ир-ат...

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Бөтен хатын-кызларга да хас булган сыйфатларын. Әйтик, үз туксанын туксан итәргә омтылуын, чиктән тыш кайгыртучанлык күрсәтүен, кием сайлаганда «ромашка уйнавын»: алам-алмыйм, ошый-ошамый... «әйттем бит мин сиңа» исемле ватык пластинканы гел кул астында тотуын, кайбер әйтәсе килгән фикерләрен бик еш кына без – ир-атлар берничек тә аңлый алмый торган формаларга салуын, сүзләргә «төрүен» һәм башкалар.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Андый нәрсә турында уйлаганым юк... Уйларга да язмасын!

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Ир-атлар, гомумән, үзләренә һәрдаим игътибар таләп итүчән, бик чәүчәләк затлар. Безне бер генә төрле амплуада булучылар бик тиз ялыктыра, шул ук вакытта мизгел эчендә 28 төрлегә әйләнүчеләр дә күңелне болгата. Безгә гел әйбәт кенә хатын да ярамый, начарын да янда тотасы килми...

Ир кеше өчен хатыны аны көн саен яңа җиңүкazanышларга илһамландыручы, моның өчен көчен дә, сүзен дә, юлын да табучы; гомере буе хатын-кыз игътибарына мохтаҗ ирне өйдә бер минут та игътибарсыз калдырмый торган мохит тудыручы җан дусты, балалары «әнием» дип өзгәләнеп торган иң якын кешесе булырга тиеш.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Җан дусты булырга тиеш дигән сүзне әйттем инде... Дус булмасаң, аның белән ничек яшисең соң инде?

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Мин аңа тәкъдим ясамадым да бугай... Ике ел ярым очрашып йөрү дәвамында бер-беребезне ярты сүздән аңлап, беребез икенчесенең фикерен әйтеп бирерлек дәрәҗәдә бер-беребезгә күнектек – тормышларны бәйләү фикере үзеннән-үзе килеп чыкты.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Юк, мин үзем алай сайламадым. Мин мөмкин булган кадәр аңлаешлы, үтә күренмәле дәрәҗәдә ихлас кеше эзләдем.

Стереотиплар аша «охшатып сайлау» – аңсыз рәвештә булганда – холык зәгыйфьлегенә ишарә, чөнки һәр кешенең үз холкы, аңа гына туры килә торган типажы бар.

Аңлы рәвештә: «Әни кебек булса, әйбәт инде!», йә булмаса: «Әнием бәлешләрен, аның кебек тәмле итеп, бары тик аңа охшаган кеше генә пешерә ала...» яисә: «Үземә ошаган кеше әнигә охшарга тиеш...» – дип сайлану, ир-атта ирекле фикер йөртә белү сәләтенең чикле булуын күрсәтә.

Иң кызыгы шул: андый принцип белән сайлаучыларның күбесенең хатыннары, өйләнешкәч, бөтенләй башка – таныш түгел кешегә охшый башлый! Шуңа күрә, гомерлек яр сайлаганда, минемчә, төп таләп – ихласлык.

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Минем әтием гомере буе әниемнән азрак хезмәт хакы алып эшләде. Беренчедән, мәктәп директорының окладына аз; икенчедән, өстәмә дәресләр укытып, ниндидер акча эшләү закон тарафыннан чикләнгән иде. Шуңа күрә әниемә, атнасына утыз алтышар сәгать дәрес укытып, финанс балансын тотарга туры килде. Әти мәрхүмнең үзен ким-хур хис иткәнен хәтерләмим, киресенчә, нәселебез өчен хөрмәткә лаек кеше булды, аның белән горурланып яшәдек.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Әгәр син соңгы бер айда аның өчен өченче гыйшык объекты түгел икәнсең, моны ихласлык билгесе дип саныйм. Киресенчә булганда – азгынлыкны, тәрбиясезлекне күрсәтә дип тә уйларга мөмкин. Шуңа да бу очракта ачыктан-ачык әйтелгән әлеге хис иратны азрак сискәндерергә, игътибарлырак булырга чакырырга тиеш. Ялгышулар берәүдән дә ерак йөрми.

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Романтика һәм юмор хисе. «Акчасы, кесәсе» диючеләр дә кайсыбер очракларда хаклы булыр. Тик байлыкны, акчаны сайлаган ханым, иртәме-соңмы, беренче сыйфатларга ия булган кемне дә булса очратачак. Менә ул очракта бу гаиләдә фаҗига килеп чыгуы ихтимал да инде.

Хатын-кыз колак белән ярата. Шуңа күрә мәдхия һәм дифирамбларны алар үзләренә игътибар буларак кабул итсә, көлдерә белү сәләтен интеллект дип саный. Миңа калса, ялгышмыйлар.

11 Хатын-кызлардан үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?

– Мин кешеләрдән нәрсәдер көтәргә күнекмәгән. Киресенчә, үзем файдалы булган очракларны хуп күрәм.

12 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Шулай. «Чибәр хатын-кыз синеке генә була алмый...» дигән фикерне күпчелек ир-ат аңында йөртә һәм бу гыйбарәдә хаклык та бар.

Ә көчле хатын-кызга икенче планда яшәргә риза булган көчсез ир-ат кирәк. Юкса ике көчле кешедән торган гаилә озак яши алмый. Шул ук вакытта ике көчсез кеше төзегән гаилә дә тормышка сәләтсез. Хатын-кыз икенче рольне уйнаган гаиләләр тотрыклырак була, ләкин хатыныгыз тормышка яраксыз бер «җебек» икән, моннан да начар вариантның булуы мөмкин түгел.

13 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар, Сезнеңчә, бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?

– Мантыйк – ул берәү генә. Ике мантыйк була алмый: җир – кара, кар – ак. Бер вакыйгага ике караш була ала, тик монда җенеснең бернинди катнашы да юк...

14 Хатын-кыз белән ир-атларның икесе ике Галәмнән икәнлеге билгеле. Күп вакытта аңлашылмаучанлык шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә менә нәкъ шулай эшләгәнен аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Әгәр ир – хатынын, хатыны ирен аңламый икән, бу, минемчә, чын гаилә түгел инде... Яр сайлаганда ихласлыкка игътибар итәргә кирәк дип юкка әйтмәдем. Егет белән кыз булып йөргән вакытта бер-берегңне аңлап та, хәзер ул аңлашу юкка чыккан икән, димәк, ул чакта сез бер-берегезне алдагансыз, булганыгыздан яхшырак булып күренү өчен уйнагансыз.

Һаман да җавап таба алмаган бер сорау бар барын: «Хатыным мине – аңлау өчен шактый катлаулы кешене – ничек аңлады, нәрсә уйлап сайлады икән?»

15 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Очрагына карап. Әгәр мәсьәлә халиткеч дәрәҗәдә мөһим икән, хаклыгыңны исбатларга туры килә. Мәсьәләнең асылы бер кыркым йонга тормаганда, әйдә, ул хаклы булсын!

16 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән...

– Ашау ягына килгәндә, мин талымсыз. Бәлеш бар икән, рәхәтләнеп туйганчы ашыйм, өченче көнге аш кына икән, аңа да риза. Әгәр ашарга бөтенләй бер әйбер дә юк икән, моны кулинар осталыгымны сынап карау өчен шәп форсат дип кабул итәм һәм, интернеттан «урлап», берәр итле ризык пешерәм. Әниләре дә, балалар да «тәмле-тәмле», дип ашаган булалар...

Хатын-кызның вакыты-вакыты белән шулай иркәләнеп ятарга да хакы бар, дип саныйм мин. Ялсыз тарткан «йөк» аны «вата» гына, ә «ватык» хатын кемгә кирәк?

17 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Мин моның белән көрәшмим. Минем хатын, башта үзе әзерләнеп бетә, аннары балаларны әзерли, азакта – мине тизләтә.

18 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?

– Бүләкне хуҗалыкта куллану өчен яраклылык зарурияте белән бәяләмим. Үземә нәрсә бүләк итсәләр дә, риза. Бүләк итмәсәләр дә, дөнья бетми.

Тик хатыным, нинди генә бүләк ясасам да, әллә уйнап, әллә чынлап, бүләкне, серле елмаеп, «дурачо-ок!» дип кабул итә. Әллә ошамый, әллә: «Ник мәшәкатьләнеп акча туздырып йөрисең?» дигән сүзе шунда, аңламассың...

PRESSA.RU



«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА әзерли.



Ватанны саклаучылар көненә үзегезнең иң батыр, иң кыю, иң сөйкемле ир-егетләрегезгә бәйрәм ясап, менә шушы ризыкны әзерләп карагыз әле. Ит белән яшелчәләр генә дип карасагыз, ялгышачаксыз. Шәрык тәмләткечләре белән озак итеп пешергәнгә, бик тәмле һәм хуш исле ул. Безгә аны танылып килүче җырчы, тамада һәм менә дигән фотограф Алсу ФАЗЛЫЕВА пешереп күрсәтә. Алсу матур тавышы, жор теле белән генә түгел, уңган хуҗабикә булуы белән дә сокландыра. Ире Азат (шулай ук җырчы) һәм уллары Аяз белән Ильясны үзгә ризык пешереп сыйларга ярата ул. Рецептларын да үзе уйлап чыгара. Алсу рецепты белән пешергән бәрән ите сезгә дә ошар дип уйлыйбыз.

МАРОККОЧА ПЕШКӘН БӘРӘН ИТЕ



Кирәк:

• 1,5-2 кг бәрән ите (алгы санның калак сөяге тирәсе);
• 1 баш суган;
• 1 баш сарымсак;
• 1 кишер;
• ярты чәй кашыгы төелгән кардамон;
• 1 чеметем генә шафран;
• төелгән кара борыч;
• 1 лавр яфрагы;
• тәменчә тоз;
• ит күмелерлек су.

Гарнир өчен:

• 2-3 бәрәңге;
• 1-2 баллы борыч;
• 1 яшь ташкабак;
• 200 г кузаклы фасоль (туңдырылганы да ярый);
• 200 г брюссель яки брокколи кәбестәсе;
• 150 г гөмбә (яратсагыз).



Эш барышы:

■ Зур кәстрүлгә су салып, кайнатырга куябыз. Шунда ук әрчеми генә урталай бүленгән бер баш сарымсак, эре итеп туралган кишер, әрчелгән бер баш суган, лавр яфрагы һәм юып, суы саркытылган ит салабыз. Су кайнап чыгып, шулпаның күбеген җыеп алганнан соң, төелгән кара борыч, кардамон, шафран, тоз һәм 2-3 аш өч кашыгы үсемлек мае өстибез. Ит шушы шулпада кайнар-кайнамас кына бик озаклап пешсен (2 сәгатьтән дә ким түгел).

■ Сөягеннән аерыла башлаган итне шулпадан алып, өстенә мул итеп ак май сылыйбыз. Башка май түгел, нәкъ менә ак май гына кирәк, югыйсә итнең өсте без теләгәнчә кызармас. Майланган итне табага салып, 150-180 градус кызулыктагы мичтә өсте кызарганчы тотабыз.

■ Ә үзебез ул арада ит пешкән шулпада яшелчәләр пешерик. Шулпаның берникадәр өлешен ит янына бирер өчен алып та калдыра аласыз. Калган шулпага бармаклап туралган кишер белән бәрәңге салабыз, алар пешеп җитәрҗитмәстә фасоль, кәбестә, урталайга гына ярылган гөмбә (гөмбә яратмасагыз, аны салмаска да була) һәм туралган ташкабак салабыз. Нәкъ менә шушы яшелчәләрне генә пешерергә димәгән, без инде ризыгыбыз бәйрәмчәрәк булсын өчен шушыларны сайладык.

■ Туңдырылган яшелчәләрне шулпага салмыйча, төбенә бик аз гына шулпа салынган табада, капкач белән томалап пешереп алырга да була. Болай пешергәндә аларны табынга бирүе дә уңайрак.

■ Борычны исә, шулай ук буйга турап, үсемлек мае салынган табада кыздырып алдык. Кыздыргач, борычның тәме күңелгә ятышлырак була.

■ Зур тәлинкәнең уртасына итне куеп, аның тирәли пешкән яшелчәләрне тезеп чыгабыз. Без аларның һәркайсын аерым-аерым өем иттек. Алай ризыгыбыз матуррак күренә. Өстен аштәмләткеч үләннәр белән бизәп җибәрергә була.

■ Табынга биргәндә, һәркемгә кечкенә касәләргә салып шулпа да чыгарабыз.

■ Ашларыгыз тәмле, бәйрәмнәрегез ямьле, тормышларыгыз имин булсын!



PRESSA.RU

БЕР КИЧТӘ ТЕГЕЛГӘН СВИТШОТ






Бәйрәмдә бүләк бирешү – күркәм гадәт. Мөхәммәд галәйһиссәлам дә, бер-берегезгә бүләк бирешегез, ул араларны җылыта, дип әйтеп калдырган. Тиздән 23 февраль – ир-егетләребез бәйрәме. Яшерен-батырын түгел, без, хатын-кызлар, аларга нәрсә бүләк итәргә белми аптырыйбыз. Бу җәһәттән безнең бер тәкъдимебез бар – әйдәгез, аларга свитшот тегәбез. Ул бик җайлы һәм тиз тегелә. Өлгесен дә сызып азапланасы юк. Көндәлек кию өчен дә, спорт киеме буларак та уңайлы бу свитшотны, «Сөембикә» укучыларына инде таныш Гөлназ ГЫЙБАДУЛЛИНА үткәргән мастер-класска нигезләнеп, тәҗрибәсе булмаган кеше дә тегә ала.

Кирәк:


- калынрак трикотаж тукыма; иңе – 140-150 см, ә буе киемнең ике озынлыгы кадәр;
- тукыма төсенә туры килә торган тегү җебе;
- чукмарбашлы энәләр;
- акбур яки сабын кисәге.



Мастер-класста кулланылган үлчәмнәр 46-48 нче үлчәмле кием өчен. Кайбер саннар һәр размерга да ярашлы, аларын мастер-класс барышында әйтеп китәрбез.

Түбәндәге үлчәмнәр кирәк булыр:

- киемнең озынлыгы (муенның гәүдәгә тоташкан ноктасыннан башлап, күкрәкнең иң биек ноктасы аша алгы яктан үзегез теләгән озынлык. Гадәттә, ир-егетләр киемнең билдән түбән төшеп торганын яратмый, моңа игътибар итегез);
- күкрәк әйләнәсе (күкрәкнең иң биек ноктасы һәм култык төбе аша гәүдә әйләнәсе үлчәнелә);
- җиң уемы (пройма. Арка яктан муен нигезеннән култык төбенә кадәрге ара үлчәнелә);
- җиң озынлыгы (бу очракта муенның җилкәгә тоташкан җиреннән беләзеккә кадәрге ара);
- муен әйләнәсе (муен төбе буйлап үлчәнә);
- беләзек әйләнәсе.



Эш тәртибе:

- Тукыманы урталай бөкләп, өстәлгә тигезләп җәябез (Киемнең өлгесе турыдан-туры тукымага гына сызыла.
- Бөкләнгән сызык буйлап, тукыманың бер очыннан киемнең озынлыгын үлчәп, тамга салабыз. Аны «А» хәрефе белән билгелик. «А»дан соң, тагын шушы ук озынлыкны үлчәп, ул ноктаны «Б» дип тамгалыйк. *(1 нче рәсем.)*
- Хәзер җиң уемын (проймасы) билгеләргә кирәк. Ничек үлчәргә икәнен югарыда әйттек. Безнең очракта ул 22 см. Моңа тагын 3 см киңлек өлеше дә кушыла. (3 см һәр үлчәм өчен дә уртак.) 22+3=25.
- «А» тамгасыннан һәр ике якка да 25 см үлчәп билгелибез (сез инде үз үлчәмегезне кулланасыз). Сул яктагы ноктаны «В», уң яктагысын «Г» дип атыйбыз.
- Күкрәк әйләнәсенең үлчәмен дүрткә бүлеп, шуңа тагын 3 см (һәр размер өчен дә бер) киңлек өлеше кушабыз. Килеп чыккан санны «В» һәм «Г» нокталарыннан өскә таба үлчәп салабыз. Барлыкка килгән нокталарның сулдагысын – «Д», уңдагысын «Е» дип тамгалыйбыз. «Д» ноктасыннан – сулга таба, «Е» ноктасыннан уңга таба да әлеге санны салып, нокталарның берсен «З», икенчесен «Ж» дип билгелибез.

PRESSA.RU








Муен уемын ясау

■ «А» ноктасыннан сул якка – 2 см, уң якка (анысы алгы як була) – 9 см, өскә 8 см билгеләп, ноктлалар куябыз. Шушы 3 ноктаны дугалап тоташтырабыз. Бирелгән саннар һәр размер өчен дә уртак. *(2 нче рәсем.)*

Реглан җин:

■ «Дуга»ның һәр ике ягыннан да астан өскә таба 7 см үлчәп (һәр размер өчен дә бер), ноктлалар төртәбез. Сулдагы ноктаны – «Д», уңдагысын «Е» ноктлалары белән тоташтырабыз. *(3 нче рәсем.)*

■ «Дуга»дан өскә таба җиң озынлыгын үлчәп салабыз һәм аны «И» хәрефе белән билгелибез. Беләзек әйләнәсен икегә бүлеп, шуңа 3 см киңлек өлешен кушып, табылган санны «И» ноктасының ике ягына да үлчәп салабыз һәм аларны «И»[1], «И»[2] дип тамгалыйбыз. *(4 нче рәсем.)*

■ «И»[1] ноктасын – «Д» белән, «И»[2] ноктасын «Е» белән тоташтырабыз. Кайчы рәсеме төшерелгән сызыклар буйлап, өлешләрне кисәбез. *(5, 6 нчы рәсемнәр.)*

■ Җиңнәрне бераз тарайтасы була. Моның өчен: җиңнең иң киң төшеннән («Д» һәм «Е» ноктлалары) эчке якка таба 4 см кереп, аны җиң очы һәм муен уемы белән тоташтырабыз. Шушы сызык буйлап кисеп тарайтабыз. *(7 нче рәсем.)*

■ Кискәннән калган тукымадан ике манжет, муен уемына кайма, аскы якка кереш кисәбез. *(8 нче рәсем.)*

Манжет:

Тукыманың буй юнәлеше буенча киселә. Озынлыгы – беләзек әйләнәсе (әгәр дә трикотаж сузылучан булмаса, 1-2 см киңлек өлеше кушарга кирәк булыр), киңлеге – 12 см. Бөкләгәч, 6 см кала. Аның 1 см – тегү өлеше. Әзер манжетның киңлеге – 5 см. Һәркемнең беләзек үлчәме төрлечә, әмма киңлеге һәр үлчәмгә дә уртак.

Аскы кереш:

Ул да тукыманың буй юнәлеше буйлап киселә. Озынлыгы – күкрәк әйләнәсенә тигез, киңлеге шулай ук 12 см. Әзер керешнең киңлеге – 5 см.

Муен уемына кайма:

Ул тукыманың буй җебенә 45 градуслы почмак белән киселә. Киңлеге – 6 см, озынлыгы – 48 см. Озынлыгының дөреслеген муен уемын үлчәп ачыкларга була. *(9 нчы рәсем.)* Алар тигез булырга тиеш. Әмма кайманы кискәндә һәр ягыннан да 1 см тегү өлеше кушыла.

Тегү:

Алгы як белән арткы якны кырый җөйләр буенча тегеп тоташтырабыз.

■ Җиңнәрне тегәбез. Тегелгән җиңне уң ягына әйләндереп, киемнең эченә тыгабыз һәм җиң тегеләсе урынга чукмарбашлы энәләр белән чәнчеп куябыз. Кырый җөй белән җиңнең җөе туры килергә тиеш. *(10 нчы рәсем.)* Машина җөен култык астыннан сала башлыйбыз.

■ Манжет, кереш һәм кайманың ике очын тегеп тоташтырабыз. Манжетны урталай бөкләп, җиң очына тегеп куябыз. Җөйләрнең бер-берсенә туры килүенә игътибарлы булыгыз. *(11 нче рәсем.)*

■ Машина белән теккәндә, манжет өске якта булсын, аны бераз тартыбрак тегәргә кирәк, ә җиң очы, киресенчә, бераз җыелыбрак барсын, чөнки манжет җиң очыннан озынрак. *(12 нче рәсем.)*

■ Муен уемы да, аскы якка кереш тә нәкъ шушылай тегелә. Муен уемына тегелгән кайманы үтүкләгәндә, пар белән үтүкләп, бераз җыярга, урынына утыртырга да кирәк булачак.

■ Трикотаж тукыманың читләре, гадәттә, сыпылмый, шуңа күрә җөй кырыйларын эшкәртмәсәң дә була. Әмма, оверлогыгыз булып, эшкәртеп чыксагыз, бүләк итәсе киемегезнең эчке ягы пөхтәрәк күренәчәк. Оверлок урынына машинаның зигзаг җөен кулланырга мөмкин.


Кучкар. Уңышлы ай. Вакыйгаларны ашыктырмагыз, йолдызлар ашыкмаска һәм ныклап уйларга киңәш итә. Айның беренче көненнән үк күңелегездә дәрт, илһам тоярсыз. Кеше сүзенә карамагыз, үзегезне генә тыңлагыз.


Үгезбозау. Куаныч китерә торган ай. Көчегез ташкын кебек ургып торачак, аны дөрес файдалансагыз, әллә нинди уңышларга ирешерсез. Иң мөһиме: ялкауланмагыз гына. Язмыш сезгә күңелле сюрпризлар әзерли.


Игезәкләр. Эштән бераз туктап, дөньяны башкача бәяли торган вакыт. Элек чишелеш тапмаган катлаулы мәсьәләләрне тиз генә хәл итү мөмкинлеге туар. Бу айда сезнең алда күп ишекләр ачык булачак, файдаланып калыгыз.


Кысла. Күптәнге хыялыгызны тормышка ашыру җае чыгып тора. Нәрсәгә генә алынсагыз да, уңышлы булачак. Яраткан шөгылегез керем китерә башларга мөмкин.


Арыслан. Моңарчы яшеренеп яткан әллә нинди көчләрегез калкып чыгачак. Ниһаять, лидерлык сыйфатларыгызны тулысынча күрсәтү форсаты туар. Намусыгыз белән килешеп эш итсәгез, уңыш тавының түбәсендә булачаксыз.


Сөмбелә. Теләкләрегезне чын итәр вакыт. Тормыштан ямь табарсыз, күңел күтәренкелеге кичерерсез. Үзегезне борчып торган уйлардан, бимазалап йөдәткән низаглардан арынырсыз.


Бизмән. Игътибар үзәгендә булырсыз, абруегыз артыр. Тормышыгызда күңелле үзгәрешләр көтелә. Күңел көрлеге һәр эштә зур ярдәмче булачак.


Чаян. Көч-куәтегез ташып торыр. Нинди генә эшкә алынсагыз да, уңарсыз. Тәнкыйтьләүчеләргә, көнләшүчеләргә игътибар да итмәгез, алар сезгә зыян сала алмас. Эшен алыштырырга теләүчеләр өчен яхшы форсат чыгып тора.


Укчы. Күңелле вакыйгалар бөтереп алыр, тормышыгызга яхшы үзгәрешләр килеп керер. Әллә ни зур үзгәрешләр булмаса да, алар яңа эшләргә илһамландырачак. Фикерләрегезнең дөреслегенә башкаларны инандыру сәләтегез бар икән бит.


Кәҗәмөгез. Киеренкелектән котылып, тынычланып калырсыз. Ыгы-зыгылардан, тормыш мәшәкатьләреннән бераз гына арынып тору мөмкинлеге булыр. Тирә-юньдәгеләрне тәнкыйтьләүдән тыелыгыз, югыйсә дустыгызның дошманга әйләнүе бар.


Сукояр. Дөреслек өчен көрәшергә туры килмәгәе. Белегез: хаклык сезнең якта. Бу айга планлаштырылган эшләрегезне уңышлы төгәлләрсез, нәтиҗәләре куандырырлык булачак. Якыннарыгызга игътибарлы булыгыз, хәтерләрен калдыруыгыз ихтимал.


Балык. Йолдызлар сезгә ерак сәфәр вәгъдә итә. Бәлки, ул эш сәфәре, бәлки, ял сәяхәте булыр. Берәр дустыгыз яки туганыгыз белән килешеп китү мөмкинлеге килеп чыгар.

Февраль дә кабынган йолдызлар

Татарстан



Ильтани Һилалова (Илялова) (8.02.1932) – **театр сәнгате белгече, тәнкыйтьче. Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе**.

Екатеринбургта туа. Әтисе Исхак Һилалов – театр режиссеры, әнисе Һаҗәр – актриса. 1935 елда алар Ташкентка күченә, Ильтани Ташкент театр сәнгате институтына укырга керә. 1958–1961 елларда ГИТИСта аспирантурада укый. 1963 елда Казанга күченеп килә һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына (ТӘҺТИ) кече фәнни хезмәткәр булып урнаша. 1964–1968 елларда Татарстан Мәдәният министрлыгында сәнгать бүлеге җитәкчесе була. 1968 елдан ул кабат ТӘҺТИда – татар театры сәнгате буенча фәнни эш алып бара. Казан театр училищесында, Казан мәдәният һәм сәнгать университетында татар, рус һәм чит ил театрлары тарихыннан лекцияләр укый. 1980 елдан – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Россия



Татьяна Догилева (27.02.1957) – **Россиянең халык артисты**.

Мәскәү өлкәсендәге Ново-Михайловское авылында туа. Әти-әнисе гади эшчеләр була. 14 яшеннән Үзәк телевидение карамагында эшләп килүче яшь актер студиясенә йөри. 1974 елда ГИТИСка укырга керә. 1978–1985 елларда Мәскәүнең «Ленком» театрында, 1985–2012 елларда М. Н. Ермолова исемендәге театрда эшли. Студент чагыннан ук кинода төрле эпизод рольләрдә уйный. Беренче төп роле – «Безбилетная пассажирка» фильмындагы Нина роле. «Блондинка за углом» фильмында сатучы кыз Надежда ролен башкарып, совет чорында халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләүче «эт каешы»на әйләнгән хатын-кыз образын ача.


Чит илләр



Шакира (2.02.1977) – **җырчы, җырлар авторы, хореограф, модель**.

Колумбиянең Барранкилья шәһәрендә туа. Гарәп милләтеннән булган әтисе язучылык белән шөгыльләнә, алтын кибетләре тота. Шакира китаплар арасында, бай тормышта үсә, 3 яшеннән рәхәтләнеп укый. 8 яшендә беренче җырын яза. Ләкин тавышы артык каты, дип, мәктәп хорына аны алмыйлар. Шулай да бу аңа җырчы буларак танылырга комачауламый, 14 яшендә аның беренче альбомы дөнья күреп, Колумбиядә шактый популярлык казана. Җырчы бер-бер артлы альбомнар яздыра башлый. «Где воры?» дип аталганы шулкадәр уңыш казана ки, сатуга чыккан көнендә үк аның 300 мең данәсе сатыла.

PRESSA.RU





«СӨЙЛӘШӘ ТОРГАН СУРӘТ...»

«Рәсем ясау – сүзсез бер шигырьдер, ә шигырь сөйләшә торган сурәт», дигән борынгы грек фәлсәфәчесе Плутарх, сәнгатьне шәрехләп. Бу сүзләр нәкъ менә Хәмит Латыйпов иҗатын күздә тотып әйтелгән кебек. Чөнки аны да рәссам буларак ачыйм дигән кеше, һичшиксез, нәкъ менә ул үзе генә тойган төсләргә манылган шигырьләрен укып сурәт күзалларга; ә шагыйрь буларак күңел халәтен тирәнрәк тою өчен – «канатлы сурәтләр»ен, агачта энә төртер урын калдырмыйча, челтәр кебек «үрелгән» панноларын, Галәм гаме салынган сыннарын, җирнең үзеннән яралган керамикасын күрергә тиештер. Аның кебек берьюлы икешәр иҗат берлегендә торучылар да (Татарстан Язучылар берлеге һәм Россия Рәссамнар берлеге) юк түгел. Әмма, күр инде, бу ике иҗат берберсен шуның кадәр аңлый, яклый-саклый, тулыландыра дип, нәкъ шушы очрактагы кебек сокланган чакларыбыз еш буламы икән? Аның шигырьләре дә, Хәмит ага үзе әйтмешли, бары рәсемнәреннән саркып тамган фикерләр, сагышлар, бизәкләр генә... Кулына беркайчан да кылкаләм тотып карамаган шагыйрь:

Сукмакларга сары яфрак сибеп,
Көз урманны моңга күмдергән.
Рәссам бага урман күзләренә...
Урман күзе, димәк, тиздән үзе
Кешеләргә багар киндердән, – дип язар идеме икән?

Хәмит Латыйповның икенче китабы булган «Гамәли гамь» (Татарстан китап нәшрияты, 2006) дип аталган шигъри альбомында да рәссамчылык, корымчылык, шагыйрьлек, бер-беренә үрелеп, бербөтен итеп бирелә. Үзе генә белгән бик күп серләре белән уртаклашырга әзер булган уемчы буларак та ачар иде әле аны күпләр. Тик менә мәктәп яшендәге балаларга агачтан уеп эшләүнең һөнәри үзенчәлекләрен ярып салган китабы ничә еллар инде дөнья күрергә чират көтеп ята. Олыдан кубып, эшче һөнәрләре спартакиадасы уздырырга җыенып йөргән; халык һөнәрчеләрен саклау турындагы программалар кабул ителгән бер мәлдә теләсә кайсы нәшрият мондый кулланма-әсбап чыгаруны заман белән бер сулышта бару дип кабул итәр иде сыман. Юк икән.

...«Үксез бала моңлы була», диюләре шушыдыр. Хәмит аганың да күңеле тулы моң бит. Тормыш дигәннәре, гомумән дә, башыннан сыйпамаган аның. Җиде ай дигәндә әнисеннән ятим калса, ярты җанын яу кырында калдырып, әсирлек михнәтләрен татып кайткан инвалид әтисе дә сугыш яраларыннан мантый алмый: 13 яшьлек улын тома ятим калдырып, дөнья куя. Җиде кат тире чыкканчы бил бөксә дә, кыйналса-орылса да, тез чүкмәс, баш бирмәс бер горур зат итә аны бу үксезлеге. Һәм бүгенгәчә шундый булып кала бирә ул.

Саклаучы-яклаучыларны да иҗатында үзе тудыра ул. Ничек кенә төрләндерми рәссам аларны. Бер караганда, «Бәхет кошы», икенчесендә – «Сакчы кошлар», өченчесендә – «Әкияти кош», «Серле кош», «Гаҗәеп кош», «Сәмруг кош»... һәм, ниһаять, фәрештә! Мондый образларны рәссам иҗатының буеннан-буена күзәтергә була. Ана образы белән дә шул ук хәл. Халкыбызның меңьеллык мифологиясе, фольклоры белән сугарып, ниндидер үзенчәлекле тылсымга, гамьгә төреп бирә белә ул аларны.

Расиха ФАИЗОВА











ХӘМИТ ЛАТЫЙПОВ

PRESSA.RU

КАЗАН 15 АПРЕЛЬ



ТАТАР МУЗЫКАЛЬ ТЕЛЕВИЗИОН ПРЕМИЯСЕ

TMTV

КРК ПИРАМИДА
17.00

www.tmtv-online.ru
#tmtvonline
#премиятмтв

Генераль партнер



Партнерлар








РЕКЛАМА

Белешмәләр өчен тел.: 297 43 77 6+











ЗАКАЗ БИЛЕТОВ: 240-84-84
CONCERT.RU ЕВРОСЕТЬ

